ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№10 (322) – ОКТЯБРЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Без үтәсе юл

Җиңел акчаның алдау көче

Татар Дөм-Дөме

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ: ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Ксения Сёмина,
Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: күренекле татар дин әһеле,
мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани.
Фото ТР Милли музее архивыннан.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-2817
Басарга кул куелды: 25.10.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Сату бүлеге белгече: Гүзәл Подольская

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ВАКЛАНМАСКА ӨЙРӘНИК...

Кайчак кәефне бик вак кына нәрсәләр дә бозарга мөмкин. Мәсәлән, кибеттәге бәяләр. Бәя язылган ярлык сиңа игътибарыңны җәлеп иткән әйбернең 126 сум торуы турында сөйли. Кассир товарны махсус җайланма аша уздыра да, дисплейда көтмәгәндә бөтенләй башка сан пәйда була: 126 түгел, ә 139 сум. Вак-төяк кебек, әмма барыбер кәефне кыра. Мөнәсәбәтләрне ачыкларга туры килә. «Нигә бер төрле язылган да, икенче төрле бәя алына?» – дип вакланырга, кассирның: «Мин бәяләрне куймыйм, алар өчен җавап та бирмим, урынбасар белән сөйләшергә кирәк, ул дүшәмбе генә була...» – дигән акланyуын тыңларга...

Ә ул арада ишектә икенче бер сатып алучы пәйда була да шул ук әйберне сайлап ала – 126 гына сум лабаса! Сатучы ялганын яңадан кабатлый. Менә без инде икәү булдык, алданучылар, диюем. Хәзер «бер гаебе юк» кассирга икәүләп бәйләнәбез, әмма ул позициясендә нык тора. Кинәт кенә аңа ярдәмгә бер әбекәй килә: безгә карап, гаепләп баш чайкый да, төенчеген сүтеп, андагы тимер акчаларын саный башлый – мә, алыгыз, гауга куптармыйча гына, 13 тиенегезне, янәсе, үзем бирәм. Үзләре шундый кыйммәтле, яхшы кием-салымнан басып торалар, фәкыйрь кешеләр түгел икәне шунда ук күзгә ташлана – ә буш урында тавыш куптаралар, янәсе. Вак-төяк акча өчен...

Һәм чыннан да оят булып китә. Үзең өчен дә, пәлтәң өчен дә. Бу әбекәйләрнең булыр-булмас пенсияләре өчен – бигрәк тә. Менә без, алданган икәү, инде үзебезне гауга кубаручылар гына да түгел, ә чын җинаятьчеләр итеп тоябыз. Кызарып, ишеккә таба юнәләбез. Кассирны да, товарны да, әбекәйне дә калдырып. Вакланып тормыйча. Урамда исә, бер-беребездән күзләребезне яшереп, икебез ике якка юл тотабыз.

Шундый сәер нәрсәләр төшкә керсә дә керер икән.

СЕЗНЕҢ АПТЫРАШТА КАЛГАН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Александр Гремитских «Куйбышев ГЭС төзелеше», 1952 ел

ОКТЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. **Иртәгәге көн бурычлары.** Республиканың киләсе елны һәм тагын да ераграк вакытны күз уңында тоткан үсеш юнәлешләре

10. **Киң, матур һәм тигез.** Казаннан Чаллыга кадәр сузылган «Идел» магистрале ниндигә әйләнде

18. **Туры юл кая илтә.** Министр Татарстанда юл төзелеше стратегиясе турында

24. **Мәктәп тормышы.** Бүгенге абитуриент нинди ул?

28. **Татар тормышы.** Васил Шәйхразыев белән әңгәмә

32. **Финанс пирамидалары.** Җиңел акчаның алдау көче

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

38. **Экология.** Чөгә балыклары кайчан безнең елгаларга кайтыр

42. **Редакция кухнясы.** Чын осталар тавыкны ничек әзерли

46. **Станиславский системасы буенча туризм.** «Татарстан» тәкъдим иткән эксклюзив маршрут

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

56. **Бәхетлеләр язмышы.** Урыннарда комсомол белән кемнәр җитәкчелек иткән

58. **Удар комсомол төзелешләре.** Татарстанның кайсы шәһәрендә Советлар Союзының барлык романтиклары җыелган

64. **Истәлеккә – фото.** Комсомол туйлары ничек узган

68. **Татар мәгърифәтчеләре.** Мәрҗани татар тормышын ничек үзгәрткән

74. **Тарихи сәхифәләр.** Кем ул Идегәй

80. **Китап киштәсе.** Пелевин ни белән шаккатырды

84. **Татар авыллары.** Бер машиналык акчаны ничек эшләргә

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

18.09

Әхмәт Садыйк Доган, Төркия Республикасының генераль консулы, – «БИЗНЕС Online» редакциясендә укучылар белән интернет-конференция барышында:

– Мин Казанның Төркия һәм Россия арасындагы глобаль хезмәттәшлектә күпер булуы принцибына таянып, һәрвакыт Татарстан белән хезмәттәшлек итәбез, дип ассызыклыйм. Үзара мөнәсәбәтләргә дә беркайчан бу Татарстан белән мөнәсәбәтләр, дип кенә карамыйбыз. Бу яктан Россия белән Төркия арасында аңлашу һәм килешү бар.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

10.10

Марат Атнашев, СКОЛКОВО Мәскәү идарә итү мәктәбе ректоры, – «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына интервьюсында:

– Татарстан – озак вакыт хезмәттәшлек иткән иң эшлекле партнёрларыбызның берсе. Без бик күп төрле форматларда хезмәттәшлек итәбез, кадрлар потенциалын үстерү һәм проектлар идарәсе буенча уртак программаларны тормышка ашырабыз. Шәһәрләр белән идарә итүдә, проектлар менеджментында, цифрлаштыруда һәм инновацияләрдә яңа инструментларны сынаучы буларак, Татарстан федераль кырда әйдәп баручыларның берсе, һәм безгә бу төбәк белән эшләү бик кызыклы.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

9.10

Алексей Гуськов, Россиянең халык артисты, – Казанда тамашачылары белән иҗади очрашуда:

– Без туганнан алып соңгы көнебезгә кадәр бәхетне уйлап чыгарабыз. Сулыш алган арада тыныбызны тикшереп, санап утыру түгел бу – аны галимнәр дә санап чыгара ала. Бу нәкъ менә исәпләр бернәрсәне дә хәл итә алмаган очраклардагы илаһи бер тын кысылу. Бу – хәтер, аннан башка берни дә юк. Һәм бу хәтер никадәр зуррак булса, кеше шулкадәр озаграк яшәвен дәвам итә.

Фото: Александр Ефремов

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Киләчәктә без **НИНДИ** адымнар ясарга тиеш

М-7 «Идел» трассасында ТР Президентының **НИНДИ** хыялы тормышка ашты

Авылларда **НИ ӨЧЕН** юллар салырга кирәк

Татар халкын үстерү стратегиясе безгә **НӘРСӘ** бирер

Кешеләр **НИ ӨЧЕН** җиңел акчаларга кызыга

БЕЗ ҮТӘСЕ ЮЛ

ТР Президентының Татарстан Дәүләт Советына еллык Юлламасы – без киләчәктә атлыйсы адымнар диган сүз ул. «Татмедиа» АҖнә биргән эксклюзив интервьюсында Рөстәм Миңнеханов республика өчен әлеге документның мөһимлеген әнә шулай гади һәм тирән итеп аңлатты. Һәм шундый төгәллек тә кертте: «Бу Хөкүмәткә, хакимият һәм муниципалитет органнарына сигнал бирүче, алар өчен киләсе елга өстенлекле эш юнәлешләрен билгеләүче җитди вакыйга».

Киләчәктә без икътисадта, авыл хуҗалыгында, дәүләт һәм муниципаль идарәдә нинди адымнар ясарга тиеш булабыз? Әлеге сорауларга җавап бирер өчен, «Татарстан» еллык Юлламага анализ ясады. ТР Президенты Дәүләт Советына Юллама белән 24 сентябрь көнне мөрәҗәгать итте.

Автор:
Әскәр Сабиров

ТИРӘНТЕН ЦИФРЛАШУГА КУРС

«Татарстан – РФндә социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсе буенча лидерларның берсе, әмма икътисад үсеше темплары безне канәгатьләндерми», – дип белдерде Президент үзенең Дәүләт Советына Юлламасында. Җәлеп ителергә тиешле резервлар арасында ул «эре инвестицион проектларны эшләтеп җибәрүне һәм гамәлгә ашыруны, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм эшлеклелек активлыгы дәрәҗәсен күтәрүне, товар базарларына чыгуны, шул рәвешле колачны киңәйтүне» атады.

Икътисадый үсешнең традицион рецептлары турында искә төшереп, Президент яңа масштаблы бурычларны да билгеләде. «Бу очракта безнең барлык процессларны тирәнтен цифрлаштыруга нигезләнгән яңа технологик корылышка күчәргә әзерлегебез төп факторга әверелә». Цифрлаштыру, дип аңлатты Президент, «предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, хакимият органнарының җитештерү һәм оештыру процессларын үтәли цифрлаштыру, тиешле дәүләт хезмәтләрен электрон төрдә күрсәтү, мәгариф системасына цифрлы грамоталылыкны кертү, цифрлы аналитика һәм модельләштерү ке-

бек практик нәтиҗәләргә юнәлгән булырга тиеш».

Безнең стратегик үсеш нокталары шул ук вакытта үзгәрешсез кала. Төп – нефть-газ-химия комплексы, ул безнең икътисадның ышанычлы фундаменты. Бу очракта соңгы биш елда комплекс предприятиеләрендә күзәтелгән тенденцияне, атап әйткәндә, көчле алгарышлы, югары технологияле, инновацияле проектларны гамәлгә ашыруга кертелгән инвестицияләрнең тотрыклы үсешен саклап калу мөһим, дип басым ясала Юлламада.

Әлбәттә, илебезгә карата берөзлексез санкцияләр кертү шартларында куелган максатларга ирешү җиңел булмаячак. Димәк, уйланылган, яхшылап үлчәнгән, үзгәреп торучы шартлар исәпкә алынган гамәлләр стратегиясен булдыру аеруча мөһим. Нефть-газ-химия комплексын үстерүнең яңа программасы таләп ителә, дип аңлата Президент, якындагы биш елга максат һәм бурычларны билгеләүдән ераграк перспективаны күз уңында тотып эшләүгә күчәргә кирәк булуын ассызыклап. Ман-

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

Фото «А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән суднолар төзү заводы» АҖ сайтыннан алынды

тыйк аңлашыла: Юлламада билгеләнгән «үсеш юлында сыйфатлы ыргылышны формалаштыруның тармак идеологиясе» юл картасын озакка исәпләнгән фаразларны, валюта курсының, бәяләрнең ихтимал булган тирбәлешләрен һәм хәтта Көнбатыш илләре тарафыннан күтәрелгән сәяси «сюрприз»ларны исәпкә алып формалаштырырга мөмкинлек бирә. Бу вакытта безнең төп өстенлекләр – нефть-газ химиясе өчен нефтьне иң кыйммәтле чимал буларак куллану проектлары үзгәрешсез кала.

Шуңа бәйле рәвештә тармакны әлеге кыйммәтле чимал белән тәэмин итүчеләр каршына амбициоз бурычлар куела. «Татнефть» компаниясенә Россия нефть сәнәгатенең технологик лидерларының берсе сыйфатында позицияләрне ныгытырга кирәк. Үтә үзле нефтьне табуны арттыра бару, гамәлдәге нефть чыганакларының нефтьне бирүен арттыру, нефть чыгару коэффициенты буенча иң яхшы дөнья тәҗрибәләре күрсәткечләренә ирешү – сайланган юлда иң мөһим ориентирлар.

Быелгы Юлламаның кыйммәте шунда: якындагы елга куелган бурычлардан тыш, анда аерым тармаклар өчен дә, кайбер әйдәп баручы предприятиеләр өчен дә перспектив бурычлар билгеләнгән. Аерым алганда, уңышлы үсеш кичерүче энергетика комплексы өчен республиканың цифрлы энергетикасының генерациясе, энергия тапшыруны һәм сатуны күз уңында тоткан бердәм структурасын формалаштыру бурычы куелган. «Республиканың динамик үсеше тиешле дәрәҗәдә энергия белән тәэмин итүне таләп итә».

Әгәр без предприятиеләрнең, тармакларның һәм тулаем икътисадның алгарышлы үсешенә исәп тотабыз икән, бу чакта планлаштыруда да алгарышлы адымнарсыз булмый. Болай эшләмәгәндә шактый имин эшләп килүче предприятие дә базарда вазгыятьнең кискен үзгәрешләре аркасында проблемаларга юлыгырга мөмкин. Ихтимал, нәкъ менә шуңа Юлламада эшләренең уңышлы баруында шикләнергә туры килмәгән предприятиеләр каршына да принципиаль яктан яңа бурычлар куела. Мәсәлән, бүгенге көндә илдәге һәр өченче (!) хәрби корабльне җитештерүче А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән суднолар төзү заводына шул исәптән республиканың туристик потенциалын үстерү максатында граждан судноларын төзүне киңәйтү бурычы билгеләнә.

Һәм тагын бер мөһим момент. Икътисад үсеше темпларын арттыруны күз уңында тоткан курс булган куәтләрне максималь дәрәҗәдә куллануны таләп итә. Шуңа күрә элек тәнкыйтькә эләкмәгәннәргә карата да таләпләр үзгәрә. Мисалга, безнең үсеп килүче IT-шәһәр. Президент сүзләренә караганда, Иннополис «иң яңа мәгълүмати технологияләр һәм продуктлар туа һәм икътисадка кертелә торган урынга әйләнергә», ягъни үзенең исемен акларга тиеш. Әлегә исә Иннополисның потенциалы тулысынча эшкә җигелмәгән, дип билгеләп үтә республика башлыгы.

СТРАТЕГИЯНЕ БАЗАР ТАЛӘП ИТӘ

Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре безне күптәннән инде тармакта хәлләрнең шактый имин торуына ышанырга күндерделәр. Президент та асылда шуны билгеләп үтте һәм «республика агросәнәгать комплексы продукциянең төп төрләре белән халыкны тулысынча тәэмин итүче күп булмаган төбәкләр арасына керә, өстәвенә җитештерелгән продукциянең шактый күләме республикабыздан читкә дә озатыла» дип басым ясады.

Шуңа да карамастан, авыл хуҗалыгы тармагына алга таба үсеш юнәлешен җитди рәвештә коррекцияләргә кирәк. Һәм сүз савым, артым күләмнәрен арттыру, гектардан алынган центнерларны күтәрү кебек гадәти нәрсәләр турында гына бармый. Беренчедән, авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген үстерергә, икенчедән, авыл хуҗалыгы продукциясен тирәнтен эшкәртүгә юнәлеш алырга, өченчедән, авыл хуҗалыгы җирләрен тулысынча куллану һәм саклауны тәэмин итәргә кирәк.

Юлламада яңгыраган әлеге бурычларны базар шартлары таләп итә. Икътисадның аграр секторында эшнең нәтиҗәлелеген күтәрүнең кирәклеге турында сөйләгәндә, Президентның «туфрак гектарына акчалата керем» кебек категорияләр белән эш итүе очраклы хәл түгел. Һәм үзенең чыгышында уңышлы мисалларны куллана. Лениногорск, Чүпрәле һәм Апас районнарында сөрүлекнең бер гектарыннан Кукмара һәм Балтач районнарына караганда ике мәртәбәгә азрак ке-

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

Фото: Рәфкать Билданов

Рөстәм Миңнеханов:
– Республика агросәнәгать комплексы продукциянең төп төрләре белән халыкны тулысынча тәэмин итүче күп булмаган төбәкләр арасына керә, өстәвенә җитештерелгән продукциянең шактый күләме республикабыздан читкә дә озатыла.

рем алынган. Бу бит сөрүлек мәйданнарының якынча тигез булуы шартларында! Яки тагын бер факт: Кукмарадагы Вахитов исемендәге хуҗалыкта сыерларның баш саны ике тапкырга ким булуга карамастан, Әгерҗе районында тулаем җитештерелгән күләмдәге сөт савыла!

Хәтерләсәгез, узган ел хәтта рекордлы уңышның да базар шартларында иминлекне гарантияләмәвен ачык күрсәтте. Икмәккә бәяләрнең төшүе асылда аны җитештерүгә киткән чыгымнары көндәшләренә караганда зуррак булган хуҗалыкларны керемсез калдырды. Шуңа күрә бүген авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү – бик кискен мәсьәлә. Һәм сүз чыгымнарны киметә барып, күбрәк икмәк яисә яшелчә игү турында гына бармый. Фаразлар, базарга анализ, интуиция һәм, ниһаять, сөрүлекнең гектарына лаеклы керем вәгъдә итәрлек товар җитештерү таләп ителә. Үстерелгәннәрне сата белергә, өстәвенә нәкъ менә бәяләрнең иң кулай торган вакытында товарны озата да белергә кирәк.

Юлламада билгеләнгән тагын бер мөһим бурычны хәл итү авыл хезмәтчәннәренә җитештерелгән продукциядән тагын да күбрәк керем алырга ярдәм итәчәк. Президент сүзләренә караганда, «АСК тармакларын алга таба үстерү продукцияне тирәнтен эшкәртүгә юнәлдерелгән булырга тиеш». Авыл хуҗалыгы продукциясенең шактый зур өлеше Татарстаннан читтә эшкәртелүенә бәйле вазгыять безне бүген канәгатьләндерә алмый. Аның нәтиҗәләре – алынмый калган файда гына түгел, бәлки тармакта килеп чыгарга мөмкин булган критик вазгыять тә, әйтик, узган җәйдә сөтне сатып алу бәяләренең бик түбән тәгәрәве кебек хәлләр.

Гомумән алганда, агросәнәгать сферасында чын-чынлап революцион үзгәрешләр көтелә, аларны, мөгаен, нефть тармагында гади чималны сатудан аны эшкәртүгә күчү белән чагыштырып булыр иде. Артык кыю чагыштырумы? Ничек карыйсың бит! Сөт, икмәк продуктларын, макарон эшләнмәләрен һәм башкаларны җитештерүчеләрнең керемнәре боларның барысы өчен тир түгеп «чимал» үстергәннәрнең керемнәре белән чагыштырырлык түгел. Ә сүз бит, әйтергә кирәк, әле беренчел эшкәртүдән алынган продукция турында гына бара... Бер сүз белән әйткәндә, аграр сферада барысы да якынча нефть эшкәртү һәм нефть химиясе өлкәләрендәге кебек. Аерма бары тик шунда: соңгылары өчен чимал бетә ала, ә җирнең уңдырышлылыгы яңа тиешле мөнәсәбәт күрсәтелгәндә – чиксез.

Моңа бәйле рәвештә республикада авыл хуҗалыгына караган югары продуктив җирләрнең кыскаруы өчен хакимиятнең борчылуы аңлашыла. Бары тик соңгы дүрт елда гына да, дип искәртеп үтте Президент, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең мәйданы 6,5 мең гектарга кимегән, шуларның 5 мең гектарга якыны торак пунктлар җирләренә күчерелгән. Шул ук вакытта билгеләнеше үзгәртелгән кишәрлекләрнең күпчелеге озак вакытлар үзләштерелми кала бирә. Димәк, авыл хуҗалыгы әйләнешеннән уңдырышлы җирләрне чыгаруны туктатырга, кулланылмый

ятканнарын хуҗалык әйләнешенә кушарга кирәк. Әлеге бурычны үтәр өчен Президент булган барлык механизмнарны кулланырга чакырды, шул исәптән хәтта җирләрне кире авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге категориягә кайтаруга һәм аны тартып алуга кадәр. Әлеге очракта максат иң кырыс чараларны да аклый: җир эшләргә тиеш!

Килешәсездер, Президент киң җәмәгатьчелек тарафыннан актив, ә менә ведомство коридорларында тыенкырак тикшерелгән проблеманы да урап узмады. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне шәһәргә якын районнардагы торак пунктлар җирләренә әйләндерү могҗизалы рәвештә, мизгел эчендә җирнең бәясен күтәрә, кайвакыт йөзәр мәртәбәгә. Кызыксынган затлар өчен ымсындыргыч түгелмени?

«Коррупция» сүзе әлеге проблема контекстында яңгырамады, аның каравы, Президент авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр белән теләсә кайсы шикле гамәлләргә чик куярга тиешле конкрет чараларны атады. Республика хөкүмәтенә вазгыятьне аерым контрольгә алырга күрсәтмә бирелде. «Ведомствоара эш итүләр өлешендә һәр ведомствоның, һәм шулай ук муниципалитетларның вазыйфаларын төгәл билгеләп, тәртип урнаштырырга» кирәк. Җир ресурслары белән идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү инструментларының берсе шәһәр төзелеше эшчәнлеге өчен мәгълүмат системасын эшләү һәм гамәлгә кертү булырга тиеш, ул җирләрне торак пункт чикләренә кертүдә тәртип урнаштырырга һәм әлеге өлкәдә закон бозуларны ачыкларга ярдәм итәчәк.

«Аграр» сегментка анализны тәгәлләп, Юлламада билгеләнгән тагын бер төп моментны атарга кирәк. Тармак каршында нинди генә максатлар куелса да, аңа һәрвакыт дәүләт ярдәме күрсәтеләчәк. Күп кенә республика программалары шуңа юнәлдерелгән, дип билгеләп үтте Президент. «Авыл хуҗалыгы – икътисадның бер тармагы гына түгел, бәлки тормыш рәвеше дә. Аның телне, мәдәниятне һәм традицияләрне саклауга керткән өлеше гаять зур», – дип аңлатып китте республика башлыгы.

ИДАРӘ СИСТЕМАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ ТУРЫНДА

Юлламада Президентның дәүләт һәм муниципаль идарә системасын камилләштерү зарурлыгы турында белдерәчәгең, мөгаен, бик азлар гына гоманлый алгандыр. Вазгыять начараеп киткән очракларда идарә аппаратына реформа ясауларына һәм аның кыскартылуына без инде нигектер күнеккән. Бүген бездә икътисадта һәм социаль сферада эшләр начар бармый. Тышкы тәэсирләр сынавына түзгән идарә механизмының эшкә сәләтлелегенә күрсәткеч түгелмени бу?

Икенче яктан караганда, бүген яхшы булган нәрсәләр иртәгә бөтенләй искерергә мөмкин. Татарстанда ераккарак карап эш итәргә карар кылганнар, күрәсең. Президент шуны аңлатып үтте: безнең алга таба үсешебез дәүләт идарәсе системасының нәтиҗәлелегенә турыдан-туры бәйле. Шул ук вакытта беркем дә ашыгырга, штатларны механик рәвештә кыскартырга җыенмый кебек. Иң беренче эш итеп, «дәүләт идарәсе органнарына беркетелгән вәкаләтләргә анализ ясауны, һәм шулай ук алар каршында төрле учреждениеләрнең оештырылуын нигезләүне төгәлләргә кирәк».

Ләкин җитди аналитик эшнең зур өлеше башкарылганга охшаган. Һәрхәлдә, көч куелырга тиешле кайбер конкрет нокталар инде билгеләнгән. Атап әйткәндә, дәүләт һәм тармак программалары системасын тәртипкә китерергә кирәк – «чараларны бер-берсенә бәйләү һәм аларның кабатланышын булдырмау максатында». Тагын бер бурыч – мәгълүмат системалары интеграциясе дәрәҗәсен күтәрү. Әлегә бу бөтенләй түбән дәрәҗәдә: «федераль мәгълүмат системалары арасында да, үзебезнекеләр арасында да мәгълүмат шлюзлары юк».

«Хөкүмәт структурасы да тулаем алганда үзгәртүләргә мохтаҗ», дип басым ясады Президент, безгә төрледән-төрле фаразлар кылырга киң мөмкинлекләр калдырып. Аның каравы, җирле үзидарә системасына (әлеге модель республикада 10 елдан артык гамәлдә, дип искә төшерде Рөстәм Миңнеханов) кагылышлы үзгәрешләр төгәлрәк билгеләнде. Күрәсең, муниципаль вәкаләтләр бирелгән учреждениеләр өлешеннән баш тартырга туры киләчәк. Аргументлар: кайбер муниципаль берәмлекләрдә мондый структуралар артык күбәеп киткән, шуның аркасында бюджет чыгымнары да арткан.

Җирле үзидарә системасының оештырылу структурасында да үзгәрешләр көтелә. Бирелдә курс бердәйләштерүгә – унификациягә таба алынганга охшаган. Юлламада болай диелә: әлеге структураны формалаштыруга бердәм системалы таләпләр кертергә кирәк. Республика башлыгы ТР Президенты Аппаратына Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы белән бергә Җирле үзидарә органнары структурасы стандартын эшләргә күрсәтмә бирде. Мантыйк аңлашыла: стандарт эшләнә – урыннарда чыгымлы үзэшчәнлек белән шөгыльләнү өчен сәбәпләр калмый.

Идарә системасы эшен бүгенге заман таләпләренә җавап бирә алмый торган персонал оештырганда бернинди, хәтта иң алдынгы идарә схемасының да тиешле нәтиҗәлелекне бирмәячәге аңлашыла. Шуңа күрә бурычларның берсе – кадрлар эшен камилләштерү. «Беренче чиратта, бу иң алдынгы тәҗрибәләрне һәм заманча тенденцияләрне исәпкә алып, кадрлар резервы һәм белгечләрне яңадан әзерләү системасын үстерүгә кагыла», – дип төгәллек кертте Президент.

Идарә сферасында гына түгел, башка өлкәләрдә дә иң изге ниятләрне сызып ташларга сәләтле күренеш белән көрәш мәсьәләсенә килгәндә, Рөстәм Миңнеханов тарафыннан формалаштырылган гамәлләр планын төгәллекнең һәм кыскалыкның үрнәгә дип атарга буладыр. Коррупциягә каршы сәясәтне үткәрүне хакимият алга таба көчәйтә барачак, дип белдерде җитәкче. «Беркемдә дә иллюзияләр калырга тиеш түгел!» ■

Республика программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре*

ТАТАРСТАН: ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ

Татарстанда 150 мең гаилә яңа фатирга күченде.

30 миллиард сумнан артыграк акча сәламәтлек саклау учреждениеләрен модернизацияләүгә юнәлдерелә. Моңа ФАПлар, табиб амбулаторияләре, ашыгыч медицина ярдәме станцияләре төзү дә керә.

Татарстанлыларның яртысы диярлек капиталь ремонт программасы буенча торак шартларын яхшыртты.

Бу елда Татарстандагы барлык 197 дәваханәне ремонтлау һәм заманча җиһазлау буенча илдә тиңе булмаган программа тормышка ашырыла.

21 мең укучы өчен – **52 яңа мәктәп**, 30 меңнән артык сабый өчен **207 балалар бакчасы** төзелде.

781 мәктәп, 267 балалар бакчасы төзекләндерелде.

Өч яшьтән зуррак булган барлык сабыйлар бакчада урын белән тәэмин ителде.

Алга таба ясле урыннарын арттыру планлаштырыла. Тагын алты мең урынга исәпләнгән **29 балалар бакчасы** салу планлаштырыла, яртысы – ясле яшендәге сабыйлар өчен.

Меңгә якын универсаль спорт мәйданчыгы, 71 спорт залы, 62 бассейн, 17 яңа боз сарае, 27 чаңгы базасы төзелде.

Республикада физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны **ике тапкырга диярлек күбәйде һәм 43%тан артып китте.**

* Республика программаларын комплекслы гамәлгә ашыру Татарстанда 10 ел элек башланып киткән иде.

«Барлык гамәлләребезнең үзәгендә – кеше, аның бөтен мәшәкатьләре һәм омтылышлары безнең өчен әһәмиятле. Тормыш сыйфаты – Татарстанның 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеше стратегиясе нигезендә».

(Татарстан Президентының ТР Дәүләт Советына Юлламасыннан)

270 яңа мәдәни-күңел ачу учреждениесе төзелде, 139ы капиталь төзекләндерелде. Алар арасында – Казан циркы.

Быел юл сферасына **25,5 миллиард сум** акча юнәлдерелә.

91 мәдәни мирас объекты реставрацияләнде, шул исәптән – 14 музей да.

Сәламәтлек саклау сферасы өчен якын елларда халыкның гомер озынлыгын арттыруга юнәлдерелгән бурычлар өстенлекле булачак. Тагын **2 беренчел кан тамырлары үзәген төзү,** гамәлдәге **18 үзәкне яңадан җиһазлау, Республика онкология диспансерын реконструкцияләү, аның ике филиалын** (Яр Чаллыда һәм Әлмәттә) **төзү, шулай ук Балалар онкогематология үзәген салу** планлаштырыла.

Җәмәгать урыннарын үстерү программасы буенча **250дән артык объект** тәртипкә китерелде. Яңартылган парклар, скверлар, яр буйлары яраткан ял итү һәм күңел ачу урыннарына әйләнде. Җәмәгать урыннарын үстерү программасы дәвам итә. Быел тагын **58 объект яңартылачак.**

Сәламәтлекне саклауда төп роль авыруны кисәтү чараларына һәм диспансерлаштыруга бирелергә тиеш. Ел саен әлеге максатларга республика **2 миллиард сумга якын** акча бүлеп бирә.

2010 елдан республикада **5 мең км автомобиль юлы, 124 күпер** салынды, меңнән артык шәһәр ишегалдындагы юллар тәртипкә китерелде, **62 мең авыл кешесе яшәгән 426 торак пункт** каты өслекле керү юлы белән тәэмин ителде.

Киләсе елдан башлап Татарстанда **шәһәр яны балаларны савыктыру лагерьларын яңарту** программасын гамәлгә ашыру башланып китә.



«Казан ЭКСПО»ның яңа мәйданы – күргәзмәләр, эре форумнар үткәрү өчен бөтен шартлар тудырылган урын. Аның гомуми мәйданы 75 мең квадрат метрдан артыграк. 6 меңнән артык катнашучыны җыйган әлеге юл күргәзмәсе киләсе җәйдә узачак WorldSkills дөнья чемпионаты алдыннан «Казан Экспо» өчен «беренче карлыгач» булды.

РОССИЯ ЮЛЛАРЫ:
СЫЙФАТКА ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫККА ТАБА

Автор:
Алсу Троицкая

Юл хуҗалыгы хезмәткәрләре көне алдыннан «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә махсуслаштырылган «Дорога 2018» халыкара күргәзмәсе булып узды.

9 ел эчендә беренче тапкыр Мәскәүдән төбәккә күчкән коммуникация мәйданы Казанда Россия автоюллары җәмәгатьчелегенең төп катнашучыларын – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы, Россия автомобиль юллары, төбәкләрнең башкарма хакимият органнары вәкилләрен, яңа технологияләр, материаллар һәм җиһазлар җитештерүчеләрне, фән, бизнес вәкилләрен һәм төп экспертларны берләштерде.

«Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» проектын тикшерү форумның әһәмиятле вакыйгаларыннан берсенә әверелде. Искә төшереп үтик, бу милли проект федераль һәм төбәк юлларын тәртипкә китерүгә һәм гомумән илдә транспорт инфраструктурасын үстерүгә юнәлтелгән иде.

Фотолар: Александр Ефремов, «Дорога 2018» халыкара күргәзмәсенең рәсми сайтыннан

Конгресс-холлда күргәзмәнең пленар утырышын ачкан чакта РФ Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин катнашучыларга Владимир Путинның сәламләү сүзләрен җиткерде. РФ Президенты ярдәмчесе әлеге чараның масштабы һәм форматы аның турында тармакның иң эре вакыйгаларыннан берсе буларак сөйләргә мөмкинлек бирүен әйтеп:

– Безнең очрашу – хезмәттәшлекне активлаштыру һәм илебезнең юл хуҗалыгын чагылдырган барлык яклар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне ныгыту мөмкинлеге, – дип белдерде.

Ул шулай ук расланган «2024 елга кадәрге чорда магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтүнең комплекслы планы» кысаларында Россиядә 800 км дан артыграк озынлыкта автоюллар төзелергә һәм модернизацияләнергә тиешлеген дә искә төшерде. Ә 2019 елдан РФнда «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» милли проекты гамәлгә кертеләчәк.

Күргәзмәнең пленар утырышында чыгыш ясап, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов болай дип белдерде:

– «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проектын тормышка ашыру» программасы гамәлгә кертелгәннән бирле, республикада 338 км дан артыграк озынлыктагы юлларга ремонт ясалды, ЮТһ очраклары еш күзәтелгән 163 участокта куркынычсызлыкны арттыру чаралары үткәрелде, 74 юл чатына светофорлар куелды... Башкарылган эшләр нәтиҗәсендә нормативка туры килгән юллар өлеше 81 процентны тәшкил итте, ЮТһ концентрациясе урыннары, 2016 ел белән чагыштырганда, 73 процентка кимеде. Проект чаралары республиканың җәмәгать урыннарын үстерү, ишегалды территорияләрен ремонтлау программалары белән яраштырылган һәм «Уңайлы шәһәр мохите» өстенлекле федераль проектын тормышка ашыруга юнәлтелгән.

Ул шулай ук, Татарстанда 17 октябрьдә М-7 юлының Казан–Яр Чаллы трассасындагы 31 км дан артыграк участогы ачылуны мисалга китереп, республика территориясе аша уза торган федераль трассаларны яхшыртуның әһәмиятен дә билгеләп үтте:

– Әлеге трассада куркынычсызлыкны күтәрү чаралары комплексын үткәрү ЮТһнең санын – 8,5 процентка, зыян күрүчеләрнең санын 16 процентка киметергә мөмкинлек бирде, – дип ассызыклады ТР Президенты.

Җитештерүчеләр берничә мәйданга заманча юл төзелеше техникасын чыгардылар.

«ИДЕЛ» АЛГА ОМТЫЛА

Илнең төп трассаларының берсе булган М-7нең якынча мең километры Татарстан территориясе буенча уза. Юлның әлеге өлеше Идел-Нократ төбәгенең автомобиль юллары Федераль идарәсе карамагында. Идарә башлыгы Илдар Минһаҗев «Татарстан» журналына республикада иң эре транспорт артериясенең ничек яңартылуы турында сөйләде.

– Илдар Галәветдинович, республика юл-транспорт комплексы тармагында төп вакыйгаларның берсе – «Идел» М-7 трассасының Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары территориясе аша үтүче өч участогын реконструкцияләүне тәмамлау булды, аларның гомуми озынлыгы – 31 километр. Проект биш ел дәвамында алып барылды, аның бәясе 7,7 миллиард сумга төште. Ни өчен нәкъ менә әлеге участоклар сайланды?

– Сүзне шуннан башларга кирәк: бу – безнең Идарәнең Татарстанда юл трассасын үстерү буенча күп еллар дәвамында алып барылган эшчәнлегенең дәвамы. «Росавтодор»ның структур бүлекчәсе буларак, үзебезнең җаваплылык зонасы кысаларында без РФ Хөкүмәтенең 2018 елга федераль юлларның 85 процентын норматив халәткә китерү турындагы карарын тормышка ашыруда катнашабыз. Татарстанда без моңа якынлашып киләбез. Әмма яңа инфраструктур объектлар барлыкка килүе һәм шуңа бәйле рәвештә хәрәкатнең көчәюе нәтиҗәсендә юлларны реконструкцияләү мәҗбүрияте туган зоналар бар.

Без сүз алып барган өч участок та аларга карата куелган таләпләргә җавап бирми иде. М-7 юлының реконструкцияләү зонасына кергән 888нче километры өлешендә автомагистраль дүрт полосадан ике полосага кала, тарая иде. Юл һәлакәтләре куркынычы артты. Реконструкция барышында ике өстәмә полоса барлыкка килде. Куркыныч урын юкка чыкты. Белгечләрнең исәпләүләренә караганда, трассаның транспорт үткәрү сәләте ике мәртәбәгә артып, тәүлегенә 40 мең автомобильне тәшкил итәчәк.

– Республика өчен проектның потенциаль өстенлекләре нәрсәдә?

– Юлны куллануга тапшырганнан соң, Казаннан Чаллыга кадәрле 200 километрдан артыкка сузылган юл тулысынча дүрт полосалыга әверелде. Магистральне киңәйтү пассажирлар йөртү һәм йөк ташуның интенсивлыгын үстерү мөмкинлеген арттыра, бу, үз чиратында, Татарстанның һәм күрше төбәкләрнең сәнәгый, логистик һәм туристик куәтен гамәлгә ашырырга булышачак.

– Сез реконструкция нәтиҗәсендә юл һәлакәтләре куркынычы булган урыннар юкка чыкты, дидегез. Ә тулаем республика буенча алганда мондый участоклар белән ниндирәк вазгыять күзәтелә?

– Инде әйткәнемчә, юл һәлакәтләре янаган участокларны юкка чыгару – федераль әһәмияттәге юлларны норматив халәткә китерү планының бер өлеше. 2017 ел нәтиҗәләре буенча юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе күзәтелгән 15 участок билгеләнде. Без аларны юкка чыгару юнәлешендә планлы рәвештә эшләдек, ә 888 нче километр бу исемлектәге соңгы пункт иде. Моннан тыш, хәрәкәт иминлеген арттыру максатында быел М-7 юлы буйлап 16 километрга сузылган бүлү полосасында ике яклы барьерлы киртәләр урнаштырылды. Авария куркынычы янаган юл чатларында: Яр Чаллыга борылганда (1054 км), Алексеевское бистәсе

Фото: Александр Ефремов

янындагы Биләр борылышында (92 км), Чүпрәле борылышында (132 км) – светофорлар урнаштырылды. Шулай ук ике яклап 57 «Җәяүле кичүе» билгесе куелды. Тизлек режимын саклауны контрольгә алу максатында быел 5 видеокамера урнаштырырга ниятлибез – «Казан» аэропортына җиткәндә, М-7 трассасында (Ижевск һәм Пермьгә кергәндә), А-295 автоюлында (Яшел Үзәнне һәм Волжскины урап узу урынында), А-151 трассасында (Чүпрәле борылышында).

– Транзит хәрәкәтенә бәйле автомобиль бөкеләреннән котылу мәсьәләсен никадәр актуаль дип саныйсыз?

– Юл челтәрен оптимальләштерү буенча планнар эшләү – безнең даими функцияләребезнең берсе. Хәзерге вакытта, мәсәлән, безнең җитди игътибар үзәгендә Яр Чаллы шәһәре тора – М-7 юлының 20 километрга якын өлеше шәһәр урамюл челтәренә керә. Көчле хәрәкәт һәм ЮТҺ концентрациясе зур булган Орловка бозкрасы өчен транспорт чишелешен проектлау планлаштырыла. Соколка торак пункты тирәсендә Чулман елгасы аша күпер кичүе проектлауны да күз уңында тотабыз. Барлык бу проектларны «Росавтодор» «Транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына кертергә планлаштыра. Аларны гамәлгә ашыру әлеге программа кысаларында федераль бюджеттан акчаларның бүленү-бүленмәвенә бәйле булачак.

– Эш инде алып барыла яисә якын араларда башланачак иң эре объектлар турында сөйләсәгез иде.

– Без инде Иннополис районында М-7 автомобиль юлының ун километрга сузылган өлешен (км 761+500 – км 771+246) реконструкцияләүгә керештек. Эшләр тәмамлангач, трассаның бу өлеше IБ категориясе нормативларына туры киләчәк. Мәскәү, Иннополис, Казан һәм Ульяновск юнәлешләрендәге транспорт агымын бүлү өчен, объектта «тукранбаш яфрагы» тибындагы юл чишелеше төзеләчәк. Проект кысаларында белгечләр Прорва һәм Сулица елгалары аша булган күперләрнең үтү өлешен киңәйтәчәкләр, Татар Борнашы авылы янында җир өсте җәяүлеләр кичүе салыначак.

Автоюлның ике участогы буенча (735 нче км дан 752 нче км га кадәр һәм Зөя елгасы аша күпердә, 757 нче км да) документация эшләнде. Федераль адреслы инвестицион программага кертүләрен көтәбез. «Казан» Халыкара аэропортына килүче автомобиль юлын реконструкцияләү проектлаштыруга әзерлек стадиясендә. Реконструкцияләү кысаларында Казан – Оренбург автомобиль юлында транспорт чишелешен яңарту, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгенә керү өчен борылыш эстакадасын төзү күздә тотыла.

– Ремонт һәм реконструкцияләү вакытында нинди технологияләр кулланыла?

– Ремонт эшләрен проектлаганда без материалларны юлны эксплуатацияләү шартларынна карап сайлый алабыз. Хәзер ремонт якынча милли стандартлар нигезендә алып барыла. Стандартлар иң яңа технологияләрне һәм материалларны куллануны күз уңында тота. Без юл өслекләрен эшләгәндә салкын регенерацияләү ысулын, вак ташмастика асфальт катнашмаларын, 3Д-системасын һәм башкаларны кулланабыз. Мәсәлән, М-7 автоюлында Зөя елгасы аша күперне ремонтлаганда без тибрәлеш авырлыкларына тотрыклы булган инновацияле материал – ASPHALT эретеп коелган гранитлы композиция кулландык. Казан – Буа – Ульяновск автоюлының 8 километрлы участогында тагын да ныграк каркас салырга һәм тәгәрмәч эзләре барлыкка килүен булдырмаска булышучы асфальт-бетон катнашмаларын проектлауның яңа методына таянып эшләдек.

– Аерым участоклардагы эш төре һәм тәмамланганда аларның сыйфаты нәрсәгә бәйле?

– Кайбер участокларда юл өслегенең югары катын гына алыштыру яки искергән катын төзәтү дә җитә. Кулланучылар нәтиҗәсен шуна ук сизәчәк. Мондый ремонтка гарантия 2-4 елга бирелә. Кайбер участокларда капиталь төзекләндерү таләп ителә – гамәлдәге юл өслеген тулысынча алыштыру яисә ныгыту, юл профилен төзәтү сорала. Капремонт үткәрелгән юллар өчен ремонт ясау арасы 24 елны тәшкил итә. Ягъни ваграк җитешсезлекләр булган бөтен урыннарда без капиталь эшләр башкара алмыйбыз. Ремонт төрен сайлау нигезләнгән булырга тиеш. Аның никадәр сыйфатлы башкарылуы проектлаучыларның һәм подрядчыларның квалификациясенә бәйле. Аларның ялгышырга хаклары юк. Безнең очракта бу һәрвакыт без 100 процентка ышана торган куәтле, тәҗрибәле, ышанычлы оешмалар.

Татарстан Республикасы Президентының иманы камил: илнең транспорт инфраструктурасы, шул исәптән республиканыкы да дөньяда иң яхшылардан булачак. М-7 «Идел» автоюлының 856 нчыдан 888 нче км га кадәрле участогын ачу тантанасы.

ЕВРОПАДАГЫ КЕБЕК. ТИК ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК...

Татарстанда реконструкциядән соң М-7 «Идел» федераль юлының гомуми озынлыгы 31 км дан артыграк булган (856 нчыдан 888 нче километрга кадәр) Казаннан Яр Чаллыга кадәрге өч участогын тантаналы рәвештә ачтылар. Ачылу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу трассаны реконструкцияләү күптән түгел республика халкы өчен Чулман аша күпер кебек үк хыял иде, дип билгеләп үтте. Ә бу проект буенча эшләр чынлыкта хәтта тагын да катлаулырак булып чыкты...

Автор:
Алсу Троицкая

Хыялга тормышка ашу насыйп булды. Бүген монда М-7 «Идел» трассасының республика башкаласы белән аның төп сәнәгать үзәге арасындагы участогы аша узучы машина йөртүчеләр инде инана ала. Юл төзүчеләрнең дүрт еллык эш нәтиҗәсендә дүрт хәрәкәт полосасы булган 1Б техник категорияле юл барлыкка килде.

– Мин бу юлда беренче тапкыр 2004 елда булдым. Хәтеремдә, ул чакта республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев: «Әллә без Татарстан халкының хыялын кайчан да булса чынлап тормышка ашыра алырбызмы икән?» – дип сораган иде, – дип сөйләде РФ Президенты ярдәмчесе Игорь Левитин юлны ачу тантанасында. – Менә, күрәсез, хыял тормышка ашты. Бу юл гына түгел, бу – тормыш, чөнки монда тәүлекләр буена юлда булган машина йөртүче ял итсен, машинасына заправка ясасын, юлын куркынычсыз уза алсын өчен, барысы да эшләнгән, һәм бу бик мөһим.

РФ Президенты ярдәмчесе бу транзит автоюлның республика өчен генә түгел – бөтен ил өчен әһәмиятле булуын ассызыклады. Проектны тормышка ашырган өчен юл төзүчеләргә рәхмәт белдереп, ул аларны эшсез калмаячакларына ышандырды:

– 2024 елга кадәр транспорт инфраструктурасын үстерү программасы расланган. Һәм андагы проектларның берсе – югары тизлекле Мәскәү

Юлның реконструкция ясалган участогын беренче булып Татарстан КАМАЗлары сынады...

Александр Ефремов фотолары



– Казан юлын төзү. Шуңа күрә сезгә эш күп булачак...

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов барлык юл төзүчеләргә сыйфатлы эшләре өчен рәхмәт белдерде. Мондый стандарттагы юллар турында элек хәтта хыялланмаган да идек, дип әйтте. Ә инде Америкага яки Европага барган чакта аларның нинди булырга тиешлеген аңлый идек. Хәзер андый юлларны, хәтта яхшыракларын да, үзебез төзибез:

– Бу безнең республиканың иң төп трассасы. Без монда бик күп аварияләр булганлыгын хәтерлибез, әмма инде бүген вазгыять күпкә яхшырды. Иң мөһиме – М-7 трассасы участокларындагы бөтен эш үз төзүчеләребез тарафыннан тормышка ашырылды.

Журналистлар белән аралашканда, ул шулай ук Татарстанда юл төзелеше буенча шактый проектлар булуын, һәм аларның тормышка ашырылачагын ассызыклады:

– Бездә тагын берничә әһәмиятле трасса бар. Кытайга таба, М-5, М-7, Түбән Каманы һәм Яр Чаллыны әйләнеп узу һәм чыгу юллары. Безнең бөтен заявкаларыбыз эш тәртибендә карала. Планнар зур, һәм алар тормышка ашырылачак.

Федераль юл агентлыгы (Росавтодор) җитәкчесе Андрей Костюк шулай ук Татарстан юл төзүчеләренең эш нәтиҗәсен югары бәяләде:

– Бу – профессиональлекнең иң югары дәрәҗәсе. РФ субъектлары арасында Татарстан хаклы рәвештә юллар челтәрен саклау һәм үстерү буенча әйдәп баручыларның берсе булып тора. Федераль юл агентлыгында булган иң яхшы эшләнмәләр республикада актив кулланыла. Сез үзегез дә күреп торасыз – нәтиҗә ачык.

ФАКТЛАР ГЫНА:

Автомобиль юлы киселешләрендә һәм кушылган урыннарында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында 12 кушылу ноктасы һәм 5 сул борылыш (бәҗра) төзелгән, бу конфликт нокталарын юкка чыгара һәм машина йөртүчеләргә торак пунктларга аварияләрсез керү мөмкинлеген тудыра.

Кара-каршы хәрәкәт агымнары 27 км озынлыктагы металл барьер белән киртәләнгән. Моннан тыш, реконструкция проекты үз эченә 2000нән артык сигнал баганасын, 500дән артык юл билгесен урнаштыруны, 867 нче километрдагы транспорт чишелешендә һәм 14 автобус тукталышында 5 км дан озынрак электр яктырткычлары линиясен көйләүне дә үз эченә алган иде.

Автомобиль юлы параметрларын 1Б техник категориясенә җиткерү һәм аны көйләү М-7 трассасының дүрт хәрәкәт полосасы икегә генә калган 878 нче километрында аварияләр концентрациясен юкка чыгарырга мөмкинлек бирде. Хәзер инде автомобиль йөртүчеләргә бу юлны каршылыксыз, күпкә уңайлырак һәм куркынычсыз узу тәэмин ителгән. Гомумән алганда, белгечләр бәяләвенчә, трассаның уздыру мөмкинлеге ике тапкырга артып, тәүлегенә 40 мең автомобильне тәшкил итәчәк.

Участокларны реконструкцияләү эшләренә старт 2014 елда бирелгән иде. Объектның гомуми бәясе 7,7 миллиард сум тәшкил итте.

М-7 «Идел» трассасы илебездә – Россия башкаласын, Үзәк һәм Идел буе федераль округларын һәм Урал буен бәйләп торучы әһәмиятле транспорт магистральләренең берсе. Автоюлның техник категориясен күтәрүнең яңа этабы – М-7 трассасында Казанның шәһәр-спутнигы – Иннополис районында 10 километр озынлыктагы юлны киңәйтү булачак. Эшләр быел ук башланып китте инде.

ЯҢА ОФЫКЛАРГА ЮЛ

Октябрь аенда «Каздорстрой» ААҖ белгечләре илебез юл-транспорт комплексы өлкәсендәге мөһим проектны – М-7 «Идел» федераль автоюлының Татарстан территориясендәге әһәмиятле участокларының берсен реконструкцияләүне төгәлләде. Әмма бу вакыйгага кадәр күпсанлы шундый ук мөһим эшләр башкарылды.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов:
«Тормыш безнең алдыбызга автомобиль юлларының сыйфатына һәм ышанычлылыгына карата заманча таләпләрне тәэмин итү, автомагистральләрнең хезмәт итү срогын озайту белән бәйле яңа бурычлар куя. Бүгенге көндә «Каздорстрой» маркасы югары профессиональлекне, яңа технологияләрне, киң күләмле транспорт комплексларын чагылдыра. Алар яңа заман таләпләре куйган барлык бурычларны да хәл итәргә сәләтле».

Проектларның аеруча әһәмиятлесе – Казанны һәм ул елларда «КАМАЗ» автогиганты төзелә торган Яр Чаллыны бәйләүче магистральне төзү иде. Бөтен эшләрне – полотно җәюдән башлап, юл билгеләрен урнаштыруга кадәр – «Каздорстрой» тресты* хезмәткәрләре башкара. Төзелешкә параллель рәвештә предприятие яңа объектлар торгыза, шул исәптән Татарстанда ул чакта иң куәтлеләрдән булган асфальт-бетон заводын һәм беркадәр кечерәк саналган җитештерү базасын, эшчеләр шәһәрчекләрен дә. Ике төзелеш агымы – Казаннан һәм Мамадыштан – бер-берсенә кара-каршы хәрәкәт итә.

Тарихи моментларның берсе 1980 елның 14 ноябренә туры килә: 856 нчы төзелеш идарәсенең Кавиз Хөснетдинов бригадасы һәм 913 нче төзелеш идарәсеннән Кузьма Плотников бригадасы киләчәктә илнең үзәге белән Уралдагы һәм Себердәге сәнәгать периферияләре арасындагы эре транспорт артериясендә ныклы звено булачак яңа М-7 «Идел» трассасы магистраленең соңгы метрларына асфальт җәеп бетерәләр. «Каздорстрой» тресты, субподряд оешмалары белән бергә, автомагистральне куллану һәм аңа хезмәт күрсәтү өчен кайбер махсус корылмалар да торгыза, болар – пассажирлар өчен һәм автозаправка станцияләре, юл-ремонт пунктлары комплекслары, техник хезмәт күрсәтү станцияләре. 22 нче Рязань Күпер тресты автомагистраль юлында Нократ аша һәм тагын кечерәк 11 күпер төзеп куя. Ул Татарстанда беренче техник категорияле автоюллар (1Б) һәм үз заманының иң прогрессив һәм сыйфатлы автомагистральләренең берсен төзү өчен нигезгә әверелә. Үсеп торган транспорт агымы белән бергә республика икътисады да яңа биеклеккә омтыла.

Вакыт бара, М-7 юлының Татарстан территориясендәге өлешенә транспорт йөкләнеше интенсив рәвештә үсә, юл өслеге туза. 2014 елда Татарстан территориясендә магистральнең берничә участогын киң күләмдә реконструкцияләү турында карар кабул ителә. Генераль подрядчы итеп «Каздорстрой» Ачык акционерлык җәмгыяте билгеләнә. Ул вакытка аңа инде күп еллар дәвамында Равил Гарипов җитәкчелек итә, һәм аның идарә итүгә стратегик мөнәсәбәте оешмага планлы рәвештә техник базасын модернизацияләргә, төзелешләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләмен туктаусыз үстерергә һәм юл төзелеше өлкәсендә

* «Каздорстрой» тресты 1993 елда ачык акционерлык җәмгыяте дип үзгәртелә.

Александр Ефремов фотолары

Реклама

«Каздорстрой» ААҖнең асфальт-бетон заводы (Казан).

Равил Гарипов, «Каздорстрой» ААҖнең директорлар советы рәисе.

Белеме буенча – икътисадчы. Икътисад фәннәре кандидаты. Компаниядәге стажы юл төзү тармагындагы кебек үк – 40 елдан артык. 2011 елдан – «Каздорстрой» ААҖнең директорлар советы рәисе. Күп санлы бүләкләре һәм мактаулы исемнәре бар, алар арасында – Татарстан Республикасының Мактау грамотасы, «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» мактаулы исеме, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, «Россиянең мактаулы юл хезмәткәре» билгесе, РФ Транспорт министрлыгының, РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының, Татарстан Республикасы Президентының һәм Казан шәһәре мэрының рәхмәт хатлары, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе» мактаулы исеме, «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының мактаулы гражданины» исеме.

аеруча мөһим республика проектларын тормышка ашыруда уңышлы катнашырга мөмкинлек бирә.

Эшләрнең аеруча зур күләмен магистральнең 861 нчедән 878 нче километрга кадәрге участогында башкарырга кирәк була (Татарстанның Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары территориясе). 12 километрдан озынрак юлда киң күләмле реконструкция үткәрү 3 елга исәпләнә. Проектның гомуми бәясе 3 млрд сумга якын сумманы тәшкил итә.

«Каздорстрой» ААҖнең 300дән артык белгече – инженерлар, техниклар, эшчеләр, хәрәкәттәге состав механизаторлары – объектта даими рәвештә эштә була.

Биш елдан артыграк вакыт дәвамында реконструкция зонасындагы юл чынлыкта өр-яңадан төзелә. Уң һәм сул полосалар киң яшел полосалар белән бүленә, барьерлы киртәләр, юл билгеләре, сигнал баганалары белән җиһазландырыла. Магистраль тирәли автопавильоннар, автоном яктырткычлар, чүп контейнерлары, биотуалетлар, юл билгеләре, сигнал баганалары, юл буферлары һәм каршылык киртәләре урнаштырыла. Реконструкциядә инновацион материаллар һәм технологияләр кулланыла. Мәсәлән, асфальт-бетон җәемнең өске катламы БНД 60/90 га 15 /маркалы/ вак таш-мастикалы асфальт-бетоннан эшләнгән, ул урынында ныклыкның һәм ашалуга бирешмәүнең иң яхшы күрсәткечләрен тәэмин итә.

Төзелеш тәмамланганнан соң 1Б категориясе бирелгән яңартылган участокның төп сыйфатламаларыннан берсе булып аның күпме машина уздыра алу мөмкинлеге торырга тиеш. Ул тәүлегенә 40 меңгә кадәр машина узуын тәшкил итәчәк, ә 2031 елга тәүлегенә 25 меңлек автомобиль агымы фаразлана. Моннан тыш, реконструкция юлда тизлек режимы күтәрелүне һәм транспортны эксплуатацияләү чыгымнарын киметүне тәэмин итәчәк, гомумән алганда, бу автомобильләр белән йөк ташуның рентабельлелеген күтәрергә һәм магистраль ярдәмендә хезмәт күрсәтелә торган территорияләр үсеше өчен өстәмә сәбәпләр булдыруга китерәчәк.

Кулланууга тапшырылган объект юлларның сыйфаты һәм куркынычсызлыгы буенча барлык таләпләргә җавап бирә, ә хәрәкәтнең уңайлылыгы ягыннан Европа дәрәҗәсендәге трассалардан калышмый. Әмма «Каздорстрой» ААҖ өчен бу участок, бөтен әһәмиятлелеген исәпкә алганда да – оешма алдына төзелеш һәм реконструкция буенча куелган бурычларның бер өлеше генә, ул аларны М-7 Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Алабуга – Уфа федераль автомобиль юлында тормышка ашыра. Соңгы биш ел эчендә генә дә компания эшләгән участокларның озынлыгы 70 километрдан артып киткән.

М-7 «Идел» трассасында «Каздорстрой» ААҖ төзегән кунакханә комплексы (878 нче км).



БӘХЕТЛЕ ЮЛ НӘРСӘДӘН ТӨЗЕЛӘ?

Татарстанда Идел һәм Чулман аша яңа күперләр пәйда булырмы? Ерак авылларга юл салу нигә кирәк? Безнең кайсы магистральне үрнәк дип санап була? Мәскәүдән Казанга тиз йөрешле юлны кайчан сала башлаячаклар? «Татарстан» журналының әлеге һәм башка сорауларына ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин җавап бирде.

– Ленар Ринатович, быел Татарстан картасында заманча дәрәҗәдәге нинди магистральләр, юллар пәйда булды? Якындагы елларда нинди юллар салыначак? Иң кызыклы перспективалы проектлар белән таныштырсагыз иде.

– Быел М-7 «Идел» федераль автомобиль юлының Казаннан Чаллыга кадәр өлешендә яңарту эшләре тәмамлана. Хәтерләсәгез, Татарстанның әлеге иң киеренке транспорт магистрален этаплап яңарту 2008 елдан бирле бара. Реконструкцияләү нәтиҗәсендә республиканың ике эре икътисадый үзәге – Казан һәм Яр Чаллы агломерацияләре – IБ техник категорияле дүрт полосалы трасса белән тоташачак.

Республикада 2018 елдан 2025 елга кадәрге чорда гамәлгә кертелергә тиешле аеруча әһәмиятле проект – Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан – Уфа М-7 «Идел» автотрассасының Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрен әйләнеп үтә торган өлешен һәм Соколка авылы янында Чулман аша күпер төзү. Әлеге әйләнеч юл чынлыкта М-7 «Идел» федераль автомобиль юлының яңа юнәлеше булып тора. Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына ярашлы рәвештә, объект РФ территориаль планлаштыру схемасына кертелгән, ул Федераль юл агентлыгы гамәлгә кертә торган проектлар арасында җентекләп өйрәнелә.

Мәскәү, Түбән Новгород һәм Казанны тиз йөрешле трасса белән дә тоташтыру планлаштырылуын сез инде, һичшиксез, ишеткәнсездер. Аны проектлау эше башланды инде, ул «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе белән берлектә алып барыла. Шулай ук Казан – Оренбург – Акболак – Казахстан Республикасы чиге Р-239 автомобиль юлының кайбер участокларын, «Казан» Халыкара аэропортына керү юлын реконструкцияләү дә күздә тотыла. Аэропортыбызның пассажирлар үткәрү сәләте ел саен уртача өчтән бер тапкырга арта, алда безне WorldSkills чемпионаты, «Казан ЭКСПО»дагы башка зур халыкара чаралар көтә, һәм һава аланына керү юлының бүгенге халәте инде канәгатьләндерми. Биредә юлны I–II категория дәрәҗәсенә җиткерү, дүрт полосалы итү планлаштырыла. Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына ярашлы рәвештә, аэропортка керү юлын яңарту Россия Федерациясе территориаль планлаштыру схемасына кертелгән.

Моннан тыш, әле формалашып килә торган Европа – Көнбатыш Кытай халыкара транспорт маршруты составындагы Шәле (М-7) – Баулы (М-5) тиз йөрешле автомагистрален төзү дә дәвам итә. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә проект буенча капиталь чыгымнарның гомуми күләме 35 миллиард сумнан артып китә.

– Идел, Чулман, Казансу аша яңа күперләр планлаштырыламы? Кайчан һәм кайда?

– Тагын бер кат кабатлыйм инде, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрен урап үтә торган юл төзелеше проектында Соколка авылы янында Чулман елгасы аша күпер салу планлаштырыла. Мәскәү – Түбән Новгород – Казан тиз йөрешле автомобиль юлын салу кысаларында Идел елгасы аша яңа күпер кору күздә тотыла.

– Заманча юллар – заманча технологияләр, яңа материаллар да ул... Хәзер тармакта нинди новацияләр пәйда булды һәм файдаланыла? Үзебездә, Татарстанда, уйлап табылган яңалыклар бармы?

– Чыннан да, бүген файдалануга кертелгән һәм төзелә торган автомобиль магистральләренең саны белән генә юл челтәренә бәя биреп булмый. Ул заманча таләпләргә җавап бирергә, елның теләсә кайсы фасылында автотранспорт хәрәкәтенең уңайлылыгын тәэмин итәргә тиеш. Шул ук вакытта юлларны карап тоту чыгымнарын да киметү зарур. Автомобиль юлларының Европадагы кебек сыйфатлы булуын һәм озакка чыдавын тәэмин итә торган яңа инновацион технологияләр һәм материалларны кулланышка кертү дә – төп бурычларның берсе. Шунлыктан юл салучылар профильле фәнни-тикшеренү институтлары белән актив хезмәттәшлек итә, алар уйлап тапкан яңалыкларны сыный.

Ремонтара срокларны тәэмин итү һәм башкарыла торган эшләрнең сыйфатын күтәрү максатларында ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан Республикасы автомобиль юлларында яңа материаллар, технологияләр кертү турында нигезләмә эшләде һәм аны кулланышка кертү планын раслады. Ул уңышлы тормышка ашырыла. Композит материаллар, шул исәптән арматура, юл катламының ныклыгын арттыруны тәэмин итә торган инерт материаллар һәм туфракларны ныгытучы төрле компонентлар, юллардагы тимер-бетон конструкцияләрне ремонтлау өчен төрле составлар... – бүген болар барысы да актив файдаланыла. Ә юл хезмәткәрләре җирле инерт материалларны мөмкин кадәр күбрәк куллансын өчен, һәр муниципаль районның үзе-

Фото ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды.

Фото: Александр Ефремов

– Теләсә кайсы территориядә автомобиль юллары салуның һәрвакыт аның үсешенә этәргеч булуын аңлау мөһим.

нең юл катламының типлаштырылган конструкциясе эшләнгән. Алар хәрәкәт аз булган авыл юлларын салуда кулланыла һәм соңгыларының тиешле ныклыгын, озакка чыдавын тәэмин итә.

– Ни өчендер бездә зур шәһәрләрдәге юллар кечкенә калалардагыга караганда һәрвакыт яхшырак. Федераль магистральләр исә төбәкара трассаларга караганда яхшырак һ.б. Мондый вазгыять үзгәрә аламы?

– Әлеге фикер дөрес түгел, дип саныйм. Татарстан Республикасы Юл эшләре программасы кысаларында федераль трассаларда, төбәк әһәмиятендәге магистральләрдә һәм җирле юлларда бар эшне бер үк подрядчы оешмалар башкара, сыйфатны контрольдә тоту бөтен юллар өчен дә бертөрле. Моннан тыш, җирле юлларны яхшырту өчен Татарстанда торак пунктларның юл-урам челтәрен ремонтлау буенча программалар гамәлгә кертелә. Быел, мәсәлән, асфальтбетон катламы 364 урамда – муниципаль юл фондлары акчасына, тагын 334 урамда республика программасы буенча ремонтланды. Каты өслекле 440 урам юлы нормага китерелде. Моннан тыш, республика шәһәрләрендә 579 йорт территориясе һәм квартал эчендәге юл ремонтланды.

– Ерак авылларга юллар да заман таләпләренә ярашлы рәвештә салынамы? Әллә җирле бюджетларның мөмкинлегенә бәйлеме? Кулдагы бармаклар санынча гына кеше яшәгән авылларга яңа юллар салу кирәкме икән соң?

– Теләсә кайсы территориядә автомобиль юллары салуның һәрвакыт аның үсешенә этәргеч булуын аңлау мөһим. Бүген 3076 авыл торак пунктыннан 559 ында гына каты өслекле юл юк. Болар нигездә халык саны аз булган торак пунктлар. Авыл юлларында хәрәкәт кызу түгел, шунлыктан аларга юкарак катлам җәяргә, җирле материалларны кулланырга була. Юл хәрәкәте иминлегенә зыян китермичә генә төзелешнең бәясен арзанайту буенча бездә «Татарстан Республикасында авыл автомобиль юлларын проектлаштыру» стандарты эшләнде һәм кертелде. Әлеге стандарт тәүлегенә йөздән кимрәк машина уза торган юлларга кагыла. Ул мөмкин кадәр күбрәк җирле төзелеш материалларын файдаланып бишенче техник категория нормативлары буенча юкарак катламлы юллар салуны күздә тота.

Әле телгә алынган стандарт буенча өстәмә VA, VБ һәм VB категорияләре кертелде. Әлеге юлларның билгеләнеше – кечкенә торак пунктларны территориаль юллар белән тоташтыру, фермер хуҗалыкларына яки авыл хуҗалыгы комплексларына кадәр

юл салу. Безнең стандарт гамәлгә кертелгәннән бирле Татарстанның 111 авыл торак пункты төбәк әһәмиятендәге юллар белән тоташтырылды. Моның өчен 250 километрга якын юл салырга туры килде. Статистика буенча, мондый юлларда 2011 елдан бирле бер генә авария дә булмаган.

Сүз уңаенда, хәзер машина аз йөри торган юлларны проектлаштыру һәм салу стандарты инде Россия Федерациясе дәрәҗәсендә расланды һәм гамәлгә кертелде. Быел без барлыгы 87,8 километр озынлыктагы юл белән 28 торак пунктны тоташтырабыз, шул исәптән 20 торак пунктны – федераль бюджет хисабына. Ике мең ярымнан артыграк татарстанлы өчен юл хәрәкәте шартлары яхшырачак.

Торак пунктларга керү юлларын салу республика бюджеты хисабына (юл эшләре программасы буенча), шулай ук «Авыл территорияләрен 2014–2017 елларда һәм 2020 елга кадәрге чорда тотрыклы үстерү» Федераль максатчан программасын гамәлгә кертү кысаларында федераль бюджеттан бүленгән субсидияләр хисабына башкарыла.

– Шулай да була: яңа юл төзелә, бер-ике елдан исә бөтенләй сафтан чыга. Юлны ничек яхшы сыйфатлы итеп салырга һәм аннан ничек дөрес файдаланырга?

– Республикада юл эшләренең сыйфатын яхшыртуның күп баскычлы системасы гамәлдә. Ул җитештерү процессында катнашкан якларның тырышлыгын берләштерү һәм көйләү мөмкинлеген бирә. Подрядчы оешма юл эшләрен техник регламентлар, контрактлар һәм проект документациясенә ярашлы рәвештә башкара, һәр этап мәҗбүри контрольдә тотыла. Заказчы шулай ук юл эшләрен даими күзәтә, аларны башкару сыйфатын тикшерә. Заказчы техник күзәтчелекне даими рәвештә җитештерү урынында булган кураторлар штаты һәм эш сыйфатын тикшерүче үз лабораториясе ярдәмендә гамәлгә ашыра. Үз чиратларында, Дәүләт төзелеш күзәтчелеге хезмәткәрләре дә төзелеш һәм реконструкцияләү объектларын тикшерә, техник контроль үткәрә. Проект оешмаларының бурычы – инженерлар белән бергә авторлык күзәтчелеген тәэмин итү.

Тагын бер мөһим нәрсә бар. Подрядчы оешма башкарылган эшкә гарантия бирә. Объекттан гарантия чорында файдаланганда подрядчы гаебе белән хилафлыклар килеп чыкса, подрядчы аларны үз хисабына төзәтергә тиеш. Бу очракта гарантия срогы кимчелекләр бетерелгәнчегә кадәр озайтыла.

– Бездә үрнәк юллар бармы? Булса, кайда алар? Мондый юллар шәһәр, квартал эчләрендә, авылларда бармы? Мәсәлән, кайда?

– Федераль әһәмияттәге М-7 «Идел» автомобиль юлының Казаннан Чаллыга кадәрге өлеше реконструкцияләүдән соң 1Б категориясе нормативларына тәңгәл киләчәк. М-7 «Идел» федераль автомобиль юлының машиналар үткәрү сәләте артачак, юл хәрәкәтендә катнашучыларның иминлеге һәм уңайлылык дәрәҗәсе турында кайгырту яхшырачак.

Сафа Гәрәев
әзерләде

БЕЛЕМ АРТКАН САЕН, **ЭШ СЫЙФАТЫ ЯХШЫРА**

«Казан федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе 2018 елга дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү тармагында Идел буе федераль округында лидерга әйләнүне планлаштыра», – үзгәртеп корылган ДМИЮМ стратегиясе моннан дүрт ел элек шундыйрак иде. Һәм күпчелек күрсәткечләр буенча әлеге максатка ирешелгән. Бүген мәктәптә дисталәгән исемдәге программа эшли, тыңлаучылар саны 25 меңнән арткан. Элегрәк дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең аерым категорияләре генә укытылса, бүген бу республика җитәкчелеге хуплавында бөтен бер система хасил итә, шул исәптән анда идарә буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләре һәм территориаль иҗтимагый үзидарә рәисләре өчен программалар да бар. Бер сүз белән әйткәндә, Татарстанның тотрыклы бүгенгесе һәм динамик үсештәге киләчәге өчен җаваплы һәркем белем бирү апгрейдына кертелгән.



Автор:
Ксения Сёмина

ПИРСКА АКЧА КАЙДАН ТАБАРГА?

Утыз кешелек төркем республика чынбарлыгына туры килә торган биш авыл җирлегенә бүленгән. Хәзер аларның һәркайсында уйлап чыгарылган ниндидер бер торак пунктны су белән тәэмин итү үзәкләштерелгән системасын төзүнең күпмегә төшәсен исәплиләр. Болар барысы да – «Авыл җирлеге башлыклары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре» программасының бер өлеше.

– Бездә тагын ике буа бар, әмма алар янына керү юллары һәм пирслар юк, – ди бер төркем вәкиле, янгын сүндерү өчен су ресурсларын санаганда. Һәм сорауны теориядән гамәли яссылыкка күчерә. – Ә бит безнең авыл җирлегендә дә буа бар, тик пирслар төзелмәгән. Прокуратура пирслар салырга боерды, тик безнең акчабыз юк...

– Нәрсә эшләргә җыенасыз? – ди модератор.

– Киләсе ел бюджетына кертергә ниятлибез...

Бюджетны ничек итеп мөмкин кадәр нәтиҗәле формалаштыру турында исә башлыкларга шул ук программаның киләсе практик дәресендә аңлатачаклар. КФУның ДМИЮМндә әлеге программа дүртенче ел рәттән уздырыла. Аның модульләре аудитория таләпләренә бәйле рәвештә үзгәрә, әмма интерактивлык курсның төп асылы булып кала бирә – барлык дәресләрдә нәкъ менә шул карала торган темага кагылышлы министрлык, дәүләт учреждениеләре һәм структуралары вәкилләре катнаша.

– Мин инде бу программа буенча икенче тапкыр укыйм, күп модульләр үзгәргән. Әмма биредә һәрвакыт законнардагы үзгәрешләр турында мәгълүмат бирәләр, – ди Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башлыгы Фәридә Әгъләмҗева. – Эшне юридик яктан дөрес оештырырга өйрәтәләр. Бу яхшы да, чөнки көндәлек эш барышында барлык яңалыкларны да күреп алу мөмкин түгел.

ГРАМОТАЛЫ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

Людмила Иванова һәрвакыт үзен дөрес әдәби телдә сөйләшәм дип уйлаган. Әмма «Грамоталылык» тренингы аңа үзенең көндәлек эшендә – «Яшел Үзән» территориаль иҗтимагый үзидарәсе белән җитәкчелек итүдә рус теленең кагыйдә һәм нормаларын өйрәнү-куллануның яңа мөмкинлекләрен табарга булышкан.

– Бу бик көтелмәгән хәл булды. Лектор безне таң калдырды! – дип тәэсирләре белән бүлешә Людмила Николаевна. Икенче бер дәрестә исә ТКХ тармагына кагылышлы бик күп файдалы мәгълүмат алуына сөенгән.

– ТИҮ – халыкка төзекләндерү тармагындагы проблемаларны хәл итәргә булыша торган инструмент ул. Еш кына мондый берләшмәләрне пенсионерлар җитәкли – буш вакытлары күп булганга, алар бу эшчәнлек белән актив шөгыльләнергә әзер, тик кайвакыт күнекмәләре генә җитеп бетми, – ди «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең юридик идарәсе баш белгече Александр Уласов. – Быел программа икенче тапкыр уздырылды. Киләчәктә барлык ТИҮ рәисләре дә анда укып чыгар, дип өметләнәбез. Республикада алар якынча 370 кешегә җыела.

ДИАЛОГ КЫРЫ БУЛАРАК СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘР

Слайдта – кәсәбәләре үсешенә барыннан да бигрәк нәрсә комачаулавы турында эшкуарларны сораштыру нәтиҗәләре. Беренче урында – законнарның камил булмавы, икенчесендә – эш инфраструктурасының зәгыйфьлеге, өченче урында – дәүләт ярдәмен алудагы кыенлыклар...

– Хәзер исә, зинһар өчен, сезнең муниципалитетларда бизнес һәм хакимият арасында каршылыклар килеп чыгу сәбәпләрен языгыз, –

Фото КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбеннән алынды

дип Татарстанның берничә район башкарма комитеты җитәкчеләреннән торган аудиториягә мөрәҗәгать итә Татарстан Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил урынбасары Венера Камалова. «Территория белән нәтиҗәле идарә итү» программасы кысаларында ул кече һәм урта бизнес белән үзара хезмәттәшлеккә багышланган дәрес алып бара. Флип-чартлар тутырылганнан соң, һәр пунктны тикшерү башлана.

– Моны ике яклы очрашу, дип тә әйтеп була. Безгә шуны аңлау мөһим иде: безнең тыңлаучыларыбыз фикеренчә, ни өчен бизнесның аларга дәгъвалары бар. Шул ук вакытта без яхшы аңлыйбыз: башкарма комитет җитәкчеләре гаять зур җаваплылыкка ия, һәм аларның әлеге җаваплылык кысаларында күргән чаралары шул ук эшкуарлар арасында да еш кына популяр түгел, – ди Венера Камалова. – Һәм нәкъ менә алар, нинди дә булса проблема турында, бу системалы очрак, дип әйтерлек кешеләр. Хәтта чишелешен дә тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Безгә бусы да кирәк.

– Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил урынбасары белән очрашуда мин үзем җавап таба алмаган берничә сорауны бирдем. Тулысынча программага килгәндә исә, безгә мондый чаралар башка ил һәм төбәкләрнең тәҗрибәсе белән танышу һәм аны үзебездә куллану өчен бик кирәк, – ди Татарстанның Буа районы башкарма комитеты җитәкчесе Ранис Камәретдинов. – Программаларны кластерлап оештыру идеясе дә миңа бик ошый – кейслар гамәлдәге, республикабыз районнарында хәл ителмәгән проблемалар нигезендә формалашсын иде.

ҮСЕШ НОКТАСЫНА ЭЛӘГҮ

– Без 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында закон проекты әзерләдек. Һәм сез – кин җәмәгатьчелекнең аны күргән беренче вәкилләре, – ди, республика муниципаль районнары башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарларыннан торган аудиториягә мөрәҗәгать итеп, ТР икътисад министры урынбасары Олег Пелевин. Һәм яңа вариантта Стратегиянең Россия Президенты Владимир Путинның май указларына тулысынча яраклаштырылуын аңлата. Территорияләрне үстерүне стратегик планлаштыруга багышланган дәрес шулай башланып китә.

– Тулаем алганда, эчтәлеге ягыннан да, материалны төшендерү ягыннан да бу бик мәгълүмати, кызыклы курс. Аның өстенлекләреннән берсе – таныш әйберләргә башкача карау мөмкинлеге бирүендә. Безнең күпчелегебез республиканың төп үсеш районнарыннан түгел, – дип сөйли Татарстанның Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ольга Баженова. – Әмма без үзебез өчен кирәкле нәрсәләрне күреп алдык, аларны үстереп, без Казан, Яр Чаллы, Әлмәт белән ярыша алачакбыз. Программа озакка сузыла, бу вакыт эчендә без танышабыз, башка районнар турында күбрәк беләбез, үзара хезмәттәшлек нокта득ларын табабыз. Ә бу кондәшлеккә сәләтле булу мөмкинлекләреннән берсе.

ЧИНОВНИКМЫ? КЕШЕ!

Югары мәктәптә иң беренче булып башланган Дәүләт хезмәткәрләре өчен белем бирү программасы хәзер иң кирәкле һәм таләп ителгәннәрдән берсе. Республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, белгечләре һәм экспертлары ел саен аның тыңлаучыларына әйләнә. Программаның күп кейслары беренче карашка гади тоелган әйберләр турында: эш хатлары язу, килгән кешеләр белән аралашу, коллегалар белән хезмәттәшлек итү осталыгы. Әмма дәүләт хезмәтенең катгый регламентлы, үзендә мәшгульләргә таләпчән тармагында әлеге күнекмәләрне яхшы белү һәм һәрвакыт хәтердә тоту зарур. Гражданнарның чиновникны нәтиҗәле белгеч кенә түгел, үзен тыңлаячак, аңлаячак һәм булышачак кеше итеп тә күрәсе килә.

– «Стресска бирешмәү» тренингында мин үземнең күп коммуникацияләремне, эш тәҗрибәмне исемә төшердем һәм бу турыда башка тыңлаучыларга сөйләдем. Мондый тренинглар үткәрү киләчәктә гражданнарның ТРның «Халык контроле» Дәүләт мәгълүмат системасына (ДМС) мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә файдалану өчен уку процессының нәтиҗәле механизмы булып тора. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен тикшергәндә халык белән кире элемтә, һәркем белән шәхсән эшләүгә омтылу кирәк, чөнки кешене тыңлап, аның проблемасына төшенгәч кенә, аны хәл итү өчен хакимият органнары белән бергә чара күрергә мөмкин, – ди Татарстан Республикасында Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил аппаратының «Халык контроле» ДМС файдаланучылар эшен координацияләү бүлеге башлыгы Рөстәм Низамиев. – Бу – нәтиҗәле эшләүгә бер адым. Мәсәлән, безгә инвалид баланың әнисе подъездда күтәрелмәле пандус ясауда булышуыбызны үтенеп мөрәҗәгать итте. Без ул йортка бардык, барыбыз бергә карап, ничек яхшырак булачагын хәл иттек. Һәм идарәче компания әлеге подъездда «уңайлы мохит» тудырганда, әлеге ананың бөтен теләкләре исәпкә алынды.

БЕЛЕМНӘН – ЭШКӘ

Җирле үзидарә органнары эшен нәтиҗәлерәк итү, аларның дәүләт хакимияте органнары башкарма комитетлары белән үзара хезмәттәшлеген ныгыту өчен, республикада тәҗрибә мәйданчыклары булдырылган, аларда 2018 елның 10 аенда 43 муниципаль хезмәткәр стажировка үткән.

МӘКТӘП БАЛЛАРЫ **АРТЫНДА...**

Быел да илебез интернет киңлегендә абитуриентларның «через-чюр», «оррестовать», «символ Олимпиады – 80 – Чебурашка» һәм башка «шедеврлары» актив тикшерелде. «Татарстан» республика вузлары өчен укырга керүчеләрнең түбән әзерлекле булулары темасы никадәргә актуаль булуын ачыкларга тырышып карады. Һәм көтелмәгәнрәк нәтиҗәләргә килде.

Автор:
Олеся
Бондаревская

– Абитуриентларның әзерлек дәрәҗәсе елдан-ел үсә бара. Быел БДИ буенча безгә тапшырылган документлардагы уртача күрсәткеч 2 баллга диярлек артты, – дип сүзен башлады А.Н.Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты-КАИ (КМТТУ-КАИ) Кабул итү комиссиясе секретаре Роман Моисеев. – Элегрәк без беренче курсның ике атнасында мәктәпне тәмамлаучыларның математика һәм физика буенча белем дәрәҗәләрен вузда укырлык дәрәҗәгә җиткерә, техник юнәлешләр буенча интенсивлар оештыра идек. Хәзер бу кирәкми – беренче курслар хәтта өстәмә дисциплиналарны да яхшы үзләштерәләр. Аларны үзләре үк сайлыйлар.

Фото: Салават Камалетдинов, «Татар-информ» МА

БУ НИ ДИЮЕҢ, НАТАША?

КМТТУ-КАИ абитуриентларының яртысыннан артыгы (500 кешегә якын) – Татарстаннан, өчтән бергә якыны (300 ләп кеше) – Казаннан. Физика, математика һәм рус теле – гомуми конкурс нигезендә КМТТУ-КАИга керүчеләрнең әлеге предметлар буенча БДИның суммар баллы 200дән артып китә. Кайбер абруйлы белгечлекләр буенча 230–240 балл таләп ителә.

– Беренче сентябрь көнне мин линейкага бардым – кемнәрне кабул иткәнлегебезне белү кызык булды. Беләсезме, кайбер төркемнәрдә студентлар кайсы юнәлештә бергәләп эшләргә кирәклеге турында сөйләшәләр иде. Бу бик уңай күренеш, – ди Роман Моисеев.

Гуманитар вузларда әлеге вазгыять алай ук оптимистик фикерләр уятмый.

– Чыннан да, «бюджетка» керү баллы үсә, конкурс югарырак була бара. Ләкин ни кызганыч, БДИ буенча югары балл абитуриентның уйлый белү сәләте турында сөйләми. Әйе, ул фактологиягә ия. Әмма югары классларда аның укуы тулысынча БДИга әзерләнүгә корылганга күрә, аңа фактларны чагыштыру һәм капма-каршы куюны кебек алымнар авырлык белән генә бирелә, ә инде төп теманы тагын да тирәнрәк өйрәнү өчен читтәш темалар белән танышырга ул ияләшмәгән, – дип сөйли Казан федераль университетының археология һәм этнология кафедрасы доценты Вадим Козлов. – Барысы да интернетка, социаль челтәрләргә таянып эшләү фонында бара. Дөрес итеп яза белү юкка чыга, тел нормалары онытылып бара, һәр уңайдан сленг куллану ешая. Әлбәттә, бу күптәннән бара торган глобаль, объектив процесс. Ләкин барлык факторларны кушканнан соң, ахыр чиктә без бик ярлы лексик палитрага ия белгечне алабыз. Югыйсә югары мәктәптә профессиональ терминологияне кулланып фикерне тыңлаучыга җиткерә белү – максат түгел, ә гапгади инструмент.

– Абитуриентларыбыз киләчәк профессияләренә турыдан-туры бәйлелектәге предметлар буенча балларга кагылышлы иң югары таләпләргә җавап бирәләр. Алар мәктәптә үк журналистика өлкәсенә караган проектлар өстендә эшләүләрен дәлилләүче портфолиоларын күрсәтәләр. Әмма инде башка предметлар – тарих, җәмгыять белеме, география буенча белемнәре сорау тудыра. Ә бит вуз программасы белгечнең комплексны, ныклы әзерлек алуына исәп тота. Һәм инде әлеге бушлыкларны тутырырга мәҗбүр булган очракта, мөгаллимнәргә дә, студентларга да эш арта, – дип сөйли Казан федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе директоры Леонид Толчинский. – Моңа бәйле рәвештә гуманитар мәктәп предметлары буенча белемнәрне тикшерү формасы һәм бигрәк тә гуманитар вузга керү өчен карала торган критерий буларак БДИга мин скептикларча карыйм. Әйе, изложениедә вузга укырга керүче Наташа Ростова биегән бал турындагы өзекне энәсеннән җебенә кадәр сөйли ала (гәрчә бүгенге көндә монысы да инде бик яхшы булса да). Ләкин миңа аның әлеге өзекне, язучының телен, Толстой салган мәгънәләрне аңлый белүе мөһим. Абитуриент боларны үз позициясеннән чыгып аңлаешлы итеп сөйли алырмы?

– Фикер йөртү, анализ ясау, материалны аңлау идеалда мәктәп циклына кергән барлык предметлар нигезендә формалаша. Совет чорының соңгы елларыннан һәм хәтта 90 нчы еллардан башлап, бездә әлеге күнекмәләрне тикшерүнең объектив үлчәгечләре юк, – дип җавап бирде Югары икътисад мәктәбе МТУ гуманитар фәннәр факультетының филология мәктәбе доценты, филология фәннәре кандидаты Михаил Павловец, минем бүгенге чыгарылыш укучыларының аналитика һәм фикерләү сәләтләре түбәнәяме дигән соравыма. – Әлеге тоемлау, ми-

немчә, берничә сәбәп аркасында субъектив рәвештә барлыкка килә дә. Беренчесе – яшь арта барган саен, «без үскәндә су да юешрәк, үләннәр дә яшелрәк иде» дигән фикернең ныгый баруы. Икенчесе – югары белем ала алу мөмкинлегенең үсә баруы. Югары конкурс сакланган һәм сайлап алу гадел барган уку йортларында абитуриентларның сыйфаты кимүе турында күпкә сирәгрәк сөйлиләр. Өченчесе – үсеп килүче буынның гомуми инфантильлеге. Гомер озынлыгы, матди, психологик иминлек арта, шуның нәтиҗәсендә «озынайтылган балачак» феномены барлыкка килә: яшьләр мөстәкыйль тормышларын соңрак башлый, соңгарак калып гаилә төзи. Һәм интеллектуаль яктан да, психологик яктан да югары белем алу өчен соңрак өлгерәләр. Аларның ашыгыр җире юк.

НЫКЛЫККА ИМТИХАН

«Без «көпчәкләр һәм шөрепләр» түгел, без – Фиксиклар», – абруйлы Казан мәктәпләренең берсендә укучы 9 нчы сыйныфлар Ленинның әдәбиятның партия хәрәкәтендәге роле турындагы цитатага әнә шундый фикер белән җавап биргәннәр. Фиксиклар (инглиз теленнән to fix – көйләү, төзәтү) – мультиклардагы яңа заманның Карандаш белән Самоделкиннары. Алар һәрдаим яңадан-яңа бурычларның чишелешләрен эзлиләр.

– Программаны планлы рәвештә үзләштерү өчен 9 нчы сыйныфта биш дәрес филология (безнең мәктәптә – ул 2 дәрес рус теле, 3 дәрес – рус әдәбияты) җитәрлек кебек тоела. Программа, сүз уңаеннан, тест рәвешендәге имтиханнарга максатчан әзерләнүне күз уңында тотмый, ләкин без моның өчен вакытның бер өлешен сарыф итәргә мәҗбүрбез. Шулай итеп биш сәгатьтән Төп дәүләт имтиханына әзерлеккә, даими үткәрелеп торган мониторингларга, һәр тема буенча зур булмаса да, мәҗбүри тикшерү эшләренә киткән вакыт алып ташлана. Һәм тагын шунысын исәпкә алырга кирәк: өйрәнү өчен кертелгән әсәрләр исемлеге бүгенге мәктәп программасында, элеккегесе белән чагыштырганда, шактыйга озынрак. Уку елы ахырына тугызынчы сыйныф укучысы колач җитмәслекне колачларга һәм изложение, сочинение һәм тест тапшырырга тиеш. Быел исә телдән имтихан да өстәлергә мөмкин. 11 нче сыйныфта ситуация әз генә яхшырак, – дип сөйли Ольга Соловцова, Казандагы 131 нче лицейның рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

Өлкән сыйныф укучылары чыннан да күпмедер күләмдә «Фиксикларны» хәтерләтә: алары да, болары да төрле ситуатив проблемаларны юкка чыгару белән мәшгуль, алар турыдан-туры уку һәм күпләгән максатчан күрсәткечләр (билгеләр, баллар, рейтинглар) арасында берөзлексез баланс эзләргә мәҗбүр. Ата-аналар – әлеге ялыктыргыч марафонда җанатарлар: аларның иң тынгысызлары балаларының уку графикларын төрле фәннәрдән репетиторларның дәресләре белән тутыралар. Болар барысы да БДИ буенча югары баллар хакына эшләнә.

– Без югары белемнең барлык балаларга кирәклеге яисә мәктәпне тәмамлауга ук алынырга тиешлеге турында, ихтимал, бик сирәк сөйлибездер. Россиядә бу – совет традицияләренең кайтавазы. Ул заманнарда диплом уңышлы киләчәкне, абруйлы профессияле булуны тәэмин иткән, зыялылар мохитенә керергә булышкан, –

Фото: Александр Эшкинин, «Татар-информ» МА

ди «Менеджмент академиясе»нең компетенцияләр үзәге (Яр Чаллы) директоры, Талантлар университетының «Остазлар олимпиадасы» (Казан) координаторы Ольга Репина. – Бүген дә башка тигез шартлар булганда эш бирүче югары белемле белгечне өстен күрәчәк. Ләкин инде белем дәрәҗәсеннән бигрәк, вузны тәмамлау факты үзе бәяләнә. Бу эшкә дәгъва итүченең бары тик нормаларны саклый белүен, белемнәрне системалы рәвештә үзләштерә алуын аңлата. Бүген диплом белән уңыш арасында катгый бәйләнеш күзәтелми.

БӘХЕТЛЕЛӘР СӘГАТЬКӘ КҮЗ САЛМЫЙ

Февральдә узган «Мәгариф үсеше тенденцияләре» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә Россия мәгариф академиясенең Мәгариф социалогиясе институты директоры Владимир Собкин Ленинград өлкәсендә 3,5 мең ата-ана арсында уздырылган сораштырулар нәтиҗәләре белән таныштырды. Аларга, атап әйткәндә, укытучының төрле сыйфатларына – материал белән эш йөртә, укыту формаларын һәм методикаларын куллана, предмет белән кызыксындыра белүенә, укучының индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу осталыгына һәм башкаларга бәя бирергә тәкъдим ителгән. Түбәндәге тенденция күзәтелгән: сыйныф өлкәнәя барган саен, ата-ананың укытучыны тәнкыйтьләве дә арта бара.

– Без ата-ананың укытучылардан канәгать калуы ачыктан-ачык кими баруы турында сөйлибез. Уку-укыту эшчәнлеге барышында бала мәнфәгатьләренең исәпкә ала алынмавы аркасында, әйтик. Бу мәктәптәге вазгыятькә җитди диагноз һәм сигнал, – дип аңлатты әлеге трендны Владимир Собкин. – Гомумән әлеге эшчәнлек укучыга никадәр кызыклы?

– Мәскәү һәм Петербургның алдынгы мәктәпләре балаларны беренче сыйныфтан ук фикерләргә, предметны тикшерергә өйрәтә торган программалар сайлыйлар, математика булсынмы ул предмет, рус телеме. Мондый программаларның берсе – Даниил Эльконин һәм Василий Давыдов методикасы. Без чыннан да бүгенге көндә БДИның әһәмиятен артыграк бәялибез, ләкин аның структурасы да конструктив якка үзгәреш кичерә бит, – ди Ольга Репина. – Мәсәлән, бүген «С» өлешендә бирелгән биремнәр материалны тирәнтен белүне таләп итә. Мин – БДИ яклы һәм аңа укучы белән ата-ана позициясеннән карыйм. Бердәм дәүләт имтиханы чыгарылыш укучысына вузга керүнең унбиш мөмкинлеген бирә, ә элеккеге форма бары тик берне генә бирә иде.

Ләкин шул ук вакытта, дип билгеләп үтә спикер, педагоглар башлангыч мәктәп укучысы ата-анасына репетитор белән шөгыльләнүне тәкъдим итәләр икән, бу хәлне катастрофа дип бәяләргә мөмкин. Димәк, йә белем бирү нәтиҗәләре таләпләрен, йә мәктәп эше принцибының үзен яңадан карарга кирәк.

– Мин безнең мәгариф системасы һәрвакыт бай булган казанышларга, тырышлыкларга, кайбер бик югары нәтиҗәләргә бөтенләй каршы түгел. Ләкин анда басым үзгәрергә тиеш, дип саныйм. Мәгариф системасы дөньяда иң яхшысы саналган Финляндиядә укучылар мәктәптә көненә өч-дүрт сәгать уздыра. Ә педагоглар өчен төп ориентир – балаларның үзләрен бәхетле итеп тоюлары, – ди Ольга Константиновна. – Лайл Спенсерның «Компетенции на работе» китабында эштәге уңышка бәйле кеше сыйфатларын тикшерү нәтиҗәләре бирелгән. Басым эшне чыннан да иң яхшы итеп башкаруга ясала, «иң яхшы» белгечләрнең үз эшләрен «уртача» дәрәҗәдә үтәүчедән ни белән аерылуына. Үз-үзеңә ышанычның, башкалар турында уңай күзаллауның, кешенең төп сыйфаты булачак миһербанлык төшенчәсенең булмавы белгечләргә үз эшләрен югары дәрәҗәдә башкарырга комачаулый булып чыга. Нәтиҗә артыннан куып, без күп очракта баланың үз-үзен бәяләвен, ышанычын җимерәбез, ихтыярсыздан әгәр тестны бирә алмыйсың икән, димәк, син бернәрсә дә булдыра алмыйсың, дигән фикерне сеңдерәбез. Үз-үзенә һәм тирә-ягындагыларга шундый караш яшәгәндә, абитуриентка югары дәрәҗәдәге компетенциягә ия белгеч булып өлгерү өчен кыенга туры киләчәк.

Шул ук вакытта Владимир Собкинның югарыда атап үтелгән тикшеренүенең бер нәтиҗәсе – ата-ананың балаларының белем дәрәҗәсе белән канәгать калуының шактый зурга үсеше. Эксперт 1991 елга караган мәгълүматны китерә. Ул чакта «Балагыз барлык тармаклар буенча да җитәрлек дәрәҗәдәге белем аламы?» дигән сорауга респондентларның 7,5 проценты гына уңай җавап биргән. Ә 2016 елда – 48 процент. Ягъни сораштырылучыларның яртысы диярлек 25 ел элек ата-аналары шул ук уку дәрәҗәсе белән канәгатьсезлек белдергәнгә караганда үзләренең укулары нигезендә мәктәпкә югарырак бәя бирәләр.

Фото: Рамил Гали, «Татар-информ» МА

ЯҢА ӨМЕТ?!

Сентябрь азагында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов республика парламентына еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте. Республиканың эчке һәм тышкы хәле, киләчәккә планнар – барысын да колачлый ул. Быелгы чыгышта, мөгаен, иң күп бәхәс уяткан тема Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү булгандыр. Президент күз алдында тоткан әлеге документ нинди булачак? Аны кемнәр эшләячәк? Ни өчен кирәк ул безгә? Әлеге һәм башка темалар хакында ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев белән сөйләштек.



Автор:
Руфия Фазылова

ХАЛЫККА ТАЯНУ

Тарихка кереп калган бөек юлбашчыларның һәрберсенең үз стратегиясе булган. Стратегияләре дөрес булганнар максатларына ирешкән дә. «Стратегия төзү, бәлки, татар телен дә коткарыр...» Милли шура рәисе белән очрашканнан соң нишләптер шундыйрак уй килде. Әлбәттә, пафослы җөмлә кебек, тик, кем әйтмешли, ятып калганчы атып калырга кирәк.

Васил Габделгаязович та әлеге документның татар телен саклау, үстерүдә әһәмияте зур булачагына ышана.

– Өч вакыйга бер-бер артлы була, – дип сүзен башлады Милли шура рәисе. – Тарихтан беләбез: 1920 елда Татарстан автономиясе төзелә. Шул вакытта татар халкы үзенең телен, дәүләт теле югарылыгында танып, ТАССР булачак Указлар чыгара. Шул көннән башлап, документларны татарча да алып барабыз. Шулай булгач, бу зур вакыйганың 100 еллыгын билгеләп узу зарур. Татар халкы беркайчан да телен, динен, гореф-гадәтләрен югалтмаган. Йөз ел буена без милләтебезне саклап кала алдык.

Икенчедән, Бөтендөнья татар конгрессының эшли башлаганына 26 ел тулды. Шул дәвер эчендә ул үз платформасын төзеде. Милләтебезне барлау, саклау эшен Россия күләмендә генә түгел, ә дөнья буенча алып бара башлады. Димәк, татар милләте өчен икенче мөһим адым – Бөтендөнья татар конгрессының булуы.

Инде менә өченче юнәлеш: зур, өметле адым – Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү. ТР Президенты быелгы Юлламасында: «Конгресс шушы арада татар халкы үсешенең стратегиясен төзеп, кабул итеп, дөньяга күрсәтергә тиеш», – дип ассызыклады. Әйе, Стратегия кирәк, дигән сүзләр элек тә булды. Тик ул һаман чигерелеп килде, эш сүздән ары китмәде. Минә күрәсең, вакыты җиткәндер. Стратегия кичәге, бүгенге, иртәгә буласы вазгыятьтән этәрелеп эшләнергә тиеш.

Васил Шәйхразыевның фикерен шушы урында өзеп торып, укучылар игътибарына бер мәгълүмат

Фото: Ната Смирнова, Лилиана Валитова

җиткерәсем килә. ТР Президенты еллык Юллама белән чыгыш ясаганнан соң, икенче көнне үк ТР Министрлар Кабинетында Васил Шәйхразыев җитәкчелегендә киңәшмә үтте. Анда ТР Фәннәр Академиясе, Бөтендөнья татар конгрессы һәм республиканың дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашты. Киңәшмә ябык режимда узды, ягъни анда журналистлар да кертелмәде. Ни өчен? Милли шура җитәкчесеннән шул турыда сорадым.

– Беренче киңәшмә фикер алышу максатыннан уздырылды, – диде Васил Габделгаязович. – Әле андый очрашулар күп булачак, журналистларны да чакырырбыз. Стратегия булдыру – масштаблы, зур эш. Документны эшләгәндә, иң беренче чиратта, халык фикеренә таяначакбыз. Ә төп эш Бөтендөнья татар конгрессына йөкләнә. ТР Фәннәр Академиясе галимнәре, төрле министрлыклар һәм ведомстволар, чит төбәкләрдәге лидерлар – татар җәмәгатьчелеге белән бердәмләшеп эшләячәкбез.

Җитәкченең «халык фикеренә таяну» дигән сүзе кызык тоелды. Ничек булачак ул? Баксаң, массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет челтәре аша һәркем үзенең теләк-тәкъдимнәрен, Бөтендөнья татар конгрессына язып җибәрә алачак икән:

– Халык риза дигәч кенә, ул документ расланачак, – диде Васил Габделгаязович. – Без халык фикерен ишетергә, тыңларга һәм әлеге документны бергәләп кабул итәргә тиешбез.

МӨҺИМ ДОКУМЕНТ

– Тырышкан табар, ташка кадак кагар, дияргә ярата халкыбыз, – дип сүзен дәвам итте Милли шура рәисе. – Бу документ төрле яклап: халкыбызның мәдәниятен, динен, телен, гореф-гадәтләрен, милли ризыкларын, киемнәрен үз эченә алачак. Милләтне саклауда туган тел иң мөһим фактор булса да, без икенче кыйммәтләр турында да онытмаска тиеш. Халык җырын белгән кеше ана телен онытмый инде ул. Ризык пешергәндә «өчпочмак», «гөбәдия» дип сөйләшә икән, бу да телне саклауның бер алымы.

Татар халкы үсеше стратегиясенең махсус планы, программасы булачак икән. Һәм ул өч төрле юнәлешне: беренчесе – бөтен дөньяда яшәүче татарларны; икенчесе – Россиядә гомер итүче милләттәшләребезне; өченчесе – җирле, ягъни Татарстан татарларын истә тотып эшләнәчәк.

– Бу өч юнәлеш бер-берсенә каршы килмәячәк, киресенчә, берсе икенчесен тулыландырып, берләштереп кенә торачак, – ди Васил Шәйхразыев. – Без шуны аңларга тиешбез: документны кабул иткәч, программа була, дигән сүз. Димәк, телне үстерү юнәлеше өчен республика үзе генә эшләп калмаячак, федераль бюджеттан да финанслар җәлеп итәргә мөмкинлек туачак. Аерым өлкәләрдә дә акчасыз булмый, моны барыбыз да аңлыйбыз. Сүз Татарстан турында гына түгел. Дөньяда 10 миллионга якын милләттәшебез яши. Соңгы халык санын исәпкә алу буенча, Россиядә 5 миллион 300 мең татар исәпләнә, шуның 2 миллионы – республикабызда, димәк татарның 20 проценты Татарстанда яши, дигән сүз бу. Читтә яшәгән 80 процент татар да – безнең милләттәшләр. Милләт буларак берләшеп, берберебезне кайгыртып, дустанә яшәү – безнең төп максат.

Милли шура рәисе белән Стратегиянең кайсы елларны үз эченә алачагы турында да сөйләштек, ягъни документ ничә елга дип кабул ителәчәк? Җитәкче миңа нинди җавап бирде:

– Башта аналитика ясарга кирәк, – ди Васил Габделгаязович. – Дөнья буйлап 10 миллион

татар таралып яши, дип әйтәбез икән, бу нәрсәдән чыгып исәпләнә? Фамилиясе татар булганга гынамы, тел белгәнгәме, атасы-анасы шулай теләгәнгәме? 2030 елга кадәрге вакытны үз эченә алырмы ул документ, илленче елларга кадәргенеме – әлегә төгәлрәк әйтүе авыр. Әмма шунысы хак: аңа төзәтмәләр кертелергә мөмкин. Егерме елдан соң вазгыятьнең нинди булачагын, нинди проблемалар туачагын берәү дә белми. Димәк, яшәгән саен, күз күрер. Әлегә без бүгенге көннән чыгып кына фикер йөртәбез.

Тагын шуны да әйтәсем килә: без бергә, бердәм булырга тиеш. Чит төбәкләрдә йөргәндә еш күзәтәбез: ана телен белмәсә дә, үзен татар дип санаган, күкрәген кага-кага: «Ана телендә сөйләшә алмыйм, ләкин мин татар», – дигән милләттәшләребез шактый. Андый очракларда: «Әй, син татар телен белмисең, нинди татар инде син», – дип, кешене кире кагарга, күңелен кайтарырга ярамый. Аерым бер континенттан башлап, Россиянең һәр шәһәрендә йөзләгән, меңләгән татар яши. Хәер, Татарстанда да ана телен белмәгән күпме милләттәшебез бар. Стратегия аларны, ягъни телен оныткан татарларны да кайгыртырга тиеш булачак.

Татарларны милләт буларак саклаучы, берләштерүче документ Президентның киләсе еллык Юлламасына кадәр әзер булачак, дип ниятли Татар конгрессы җитәкчелеге.

«ТЕЛ ГАИЛӘДӘН БАШЛАНА...»

1990 нчы еллардан соң тыныч кына, үз көенә яшәгән ана телебезгә узган ел кисәк кенә күсәк белән китереп орган кебек булды. Татарстан суверенитет алганнан соң гел үзебезчә яшәрбез кебек иде, югыйсә. Ә юк, тарих янә кабатлана. Узган ел кайбер мәктәпләрдә яртышар ел татар теле укытылмавы, сыйныфысыйныфы белән «отказ» язулар, әлбәттә, җанында татар рухы булган меңләгән милләттәшебезнең төн йокыларын качырды. Мин исә быел ике балам белем алган татар гимназиясендәге расписаниедә «татар теле» сүзе булмавын күреп янә бер тетрәндем. Ул фәнне хәзер «родной язык» алыштыра. Әйе, анысы да шул татар теле, тик – аңлаган кешегә. Җанында татар рухы булмаган кеше «родной язык» урынына нәрсә сайлар, менә монысы – төп сорау...

ТР Премьер-министры урынбасары, Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев белән дә әнә шул четерекле темага кагылмый уза алмадык:

– Нинди генә авыр елларда да ана телебезне саклап кала

СҮЗ УҢАЕННАН:

Телләрне саклау, өйрәнү турында программа Татарстанда 2014 елдан бирле эшли. (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендә кабул ителгән 794 нче Карары). Ул «ТР Министрлар Кабинетының «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» дип атала. Аңлашылганча, сүз монда татар теле турында гына бармый. Программаның бюджеты 1 миллиард сумнан артык. Аерым елларга бүлгәндә, ул – түбәндәгечә:

- 2014 ел – 167,40 миллион сум;
- 2015 ел – 184,20 миллион сум;
- 2016 ел – 182,10 миллион сум;
- 2017 ел – 164,50 миллион сум;
- 2018 ел – 141,25 миллион сум;
- 2019 ел – 122,14 миллион сум;
- 2020 ел ел – 122,61 миллион сум.

Рөстәм Миңнехановның ТР Дәүләт Советына мөрәҗәгать иткән еллык Юлламасыннан:

– Соңгы вакытта Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен укытуга кагылышлы закон проекты буенча фикер алышулар билгеле бер киеренкелек нокталары булуын әлеге теманың илебездәге күпмилләтле мәдәниятнең киләчәге өчен аерым бер әһәмияткә ия булуын күрсәтте. Безнең карашларның, күзаллауларның федераль хакимият органнары, экспертлары тарафыннан ишетелүе сөендерде. Гамәлдәге законга кертелгән үлчәнелгән төзәтмәләрнең вариантлары Россия халыкларының туган телләрен өйрәнү өчен кирәкле шартлар тудыра.

...Шул ук вакытта тел мәсьәләсе тирәсендә барган фикер алышулар безнең мәгариф системасы өчен дә, барыбыз өчен дә җитди сабак булырга тиеш. Озак вакыт дәвамында татар телен өйрәнү методикаларын һәм технологияләрен камилләштерү мәсьәләләре хәл ителмәү – җитди кимчелегебез.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына, федераль министрлык белән хезмәттәшлектә, тиз арада вазгыятьне җайга салуга юнәлдерелгән чараларны күрергә кирәк. Уку планнарында һәм программаларында туган телне өйрәнүнең мәҗбүрилеге дә исәпкә алынырга тиеш. «Республика дәүләт теле» предметын өйрәнүне камилләштерү эше дә дәвам ителергә тиеш.

Моннан тыш, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына тулаем милли мәгариф инфраструктурасын үстерүгә кагылышлы мәсьәләләр комплексын эшләргә һәм, КДУ белән берлектә, Милли педагогика институтын төзүне тәмамларга кирәк.

Телне, мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклап калу мәсьәләләрендә республикадан читтә яшәүче татарларга булышу – Татарстанның конституцион бурычы. Үткән Бөтендөнья татар конгрессы съездлары әлеге сорауларның аеруча мөһим булуын күрсәтте.

Әлеге эш өчен җаваплы дәүләт хакимияте органнарына, Бөтендөнья татар конгрессына, урыннарда тиешле структуралары булган Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясенә үзара тагын да тыгызрак эш алып барырга кирәк. Эшчәнлекнең төрле форматларын үстерү, шул исәптән «Ана теле» челтәрен киңәйтү дә зарур.

Игълан ителгән Татар халкы үсеше стратегиясен кабул итүне сузу да безне бизәми. Ул үзтәңгәллеккә, халыкның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә карашларның уртаклыгына нигезләнеп, милләтне берләштерүче документ булырга тиеш. Исегезгә төшерәм, әлеге эш өчен Бөтендөнья татар конгрессы җаваплы.

алдык, – диде ул. – Бүгенге көндә бу мәсьәләдә проблема күрмим. Телне өйрәнәм, дисәң, бөтен мөмкинлекләр дә бар: мәктәпләрдә, балалар бакчаларында укыталар, татарча газета-журналлар чыга, Интернет-проектлар, «Ана теле» онлайн мәктәбе эшли, өйрән генә. Бер дә булмаса, репетиторлар бар. Башка телләрне репетиторлар ярдәмендә өйрәнәбез бит, ә ана телен бушка да укыйсыбыз килми! Асылда, өйрәнәсебез килми, шуңа күрә сәбәп эзлибез. Телләкне булдырыр өчен, рух кирәк, менә без шул юнәлештә эшләргә тиешбез. Әгәр һәр татар гаиләсе: «Мин татар, әби-бабамның мирасын югалтырга хакым юк», – дип уйласа, проблема булмас иде. Кайвакыт: «Татар телен белү нәрсә бирә?» – диләр. Бу сорауны бирүчеләргә мин шаккатып карыйм. Ничек инде ана телен белү нәрсә бирә? Әниләрне сайлап алмыйлар, димәк, ана телен дә... Җитәкче буларак, тулы ышаныч белән әйтәм: ике телне белгән кешегә бездә күп ишекләр ачык. Татар телен яхшы белсәң, Татарстанның Президенты була аласың! Яхшы мотивациядер бит?! Бик күп министрларыбыз, җитәкчеләребез барысы да татарча белә. Бүген яшьләр акыллы, карьера ясарга омтыла. Димәк, ике телне дә камил белмичә, зур үрләр яулап булмаячагын аңлый. Документлар бүген татарча да, русча да алып барыла. Димәк, дәүләт югарылыгында татар теле үзенең статусын югалтмады, борчылыр урын юк...

Татар теле турында сөйләшкәндә, Васил Габделгаязович еш кына бер фикерне кабатлады: «Ана теле, беренче чиратта, гаиләдә сакланырга тиеш». Һәм менә аны ничек дип дәлилли:

– Без әбиләр белән тәрбияләнгән буын. Элек балалар бакчалары юк иде бит. Балачак гел әби-бабайлар янәшәсендә үтте. Ә алар халык әкиятләрен дә, җырларын да беләләр, шуны безгә сөйлиләр. Шул рәвешле ана теленә мәхәббәт кечкенәдән сеңгән. Бүгенге әби-бабайлар да шулай эшләсә, тел мәсьәләсендә бер проблема да калмас иде. Шуны аңларга кирәк: телне бер генә кеше саклый алмый – бу өлкәдә һәркем үз өлешен кертсен. Әби-бабай, әти-әни, бакча тәрбиячесеннән башлап, дәүләт югарылыгындагы җитәкчегә кадәр.

... Милләтем, телем югалмасын дип, ут йотып яшәгән гражданин, әни буларак, Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның еллык Юлламасында тел проблемасын күтәрүенә чын күңелдән сөендем. Соңгы бер ел эчендә ана телебез, туган телебез – татар теле тирәсендә барган шау-шулы вазгыятьтә яңа документ – Татар халкы үсеше стратегиясе телне саклауда, милләтне берләштерүдә мөһим адым булыр, дип ышанасы килә. Әлеге темага яңадан әйләнеп кайтырбыз әле. Ә сез, хөрмәтле укучыларыбыз, редакциягә бу уңайдан фикер, тәкъдимнәрегезне юллый аласыз. Без аларны, һичшиксез, адресатларга тапшырырбыз.

САННАР

1920 елда Татарстанда 2 миллион 900 мең халык яшәгән. Хәзер исә 3 миллион 900 мең кеше гомер итә. 1920 елда Казанда 136 мең кеше булса, бүген башкалада 1 миллион 200 мең кеше яши. 1920 елда 86 процент кеше авылда яшәсә, бүген 76 процент халык шәһәрдә һәм район үзәкләрендә көн күрә.

ҖИҢЕЛ АКЧАНЫҢ **АЛДАУ КӨЧЕ**

Соңгы арада әллә ничә кешедән «үтемле» тәкъдим кабул иттем: финанс пирамидасының берсенә акча салырга кыстыйлар. Якын туганнарым да шунда. Дөресен әйтим, җиңел акчаларга ышанмыйм һәм төс тә түгел ул миңа. Ә ышанучылар бар икән, хәтта бик күп. Бизнеслары, яхшы эш урыннары булган кешеләр дә, ни гаҗәп, бу пирамидага килеп капкан.

Иллюстрация: Александр Алёшин

Автор:
Руфия Фазылова

БЕРСЕ УРЫНЫНА – ИКЕНЧЕСЕ

Финанс пирамидалары элек тә булган. СССР таркалган чорда без алар турында телевизордан туктаусыз ишетеп тордык. «МММ», «Властилина» кебек миллионлаган кешеләрне төп башына утырткан оешмаларны искә төшерү дә җитә. Абыйсы һәм хатыны белән «МММ» исеме астында теркәлгән пирамидага Сергей Мавроди, ким дигәндә, 10 миллион кешене җәлеп итә алган булып чыкты. Шул рәвешле ул якынча 2 млрд доллар акча белән эш иткән, дип фаразлана. 1994 елда, компания банкротка чыккач, аның халыкка 5 млрд доллар акча бирәсе кала.

Шул елларда популярлык казанган «Властилина» компаниясе исә үзенең акча салучыларына 2,6 млн доллар «гына» тиеш кала. Оешманың җитәкчесе – Валентина Соловьеваны суд 1999 елда 7 елга ирегеннән мәхрүм итә. Нәкъ бер елдан Валентина ханым «тәртибе яхшы булган өчен» вакытыннан алда төрмәдән чыга.

Тагын йөзләгән мондый мисалларны санарга була. Инде бу кадәр алдаулардан соң, яңадан пирамидага акча салучылар булмаска тиеш иде кебек. Тик юк, халык барыбер җиңел акчаларга кызыга. Күптән түгел туганнарым да шундый капкынга килеп капты. Башта берсе, аннан икенчесе «Кэшбери» дип аталган компаниягә күпләп акча салды. Эшнең башы апрель аена барып тоташа. Туганымның якын дусты төрле интернет биржаларда утыра, шул исәптән «Кэшбери»га да 300 сум акча салган. Көн саен 3 мең сум килеп торган. 300 мең сум 400 көн эчендә 1 миллион 200 мең итеп кайтырга тиеш булган. Бер ел эчендә 900 мең сум акча эшләп алу мөмкинлеге туганымның аңын томалады булса кирәк. Машинасының кредитын капларга дигән акчасын «Кэшбери»га салды. (Интернет аша үзеңә шәхси бит булдырып, акчаны онлайн касса аша күчерәсе.) Һәм, чынлап та, туганымның картасына көн саен 3 мең сум акча килеп тора башлады. 100 көн эчендә керткән акчасын кире кайтарды ул. «Тагын 300 көн акча килеп торачак, кешеләр шулай тиз арада баеп куя», – дип масайды туганым. Җәй көне янә 300 мең сумын салды. Шул рәвешле көн саен картасына 6 мең сум (алда керткән акчасы белән) килеп торды. Мин инде үземчә: «Бәхет елмайса елмая бит, аңа гел шулай уң килеп тора», – дип сөендем. Эшләрнең җәй баруын аңлагач, көз башында туганым тагын 300 меңен салды, бу юлы инде хатыны исеменә карта ачты. (Яңа кеше керткән саен «бүләк» буларак сиңа 13 мең сум акча күчә.) Әлеге хәлләрне күзәтеп торган тагын бер туганым да түзмәде, 300 мең сум кредит алып, «Кэшбери»га салды.

Инде «Кэшбери» турында: ул фәкать Интернет аша гына эшли. Аның филиаллары Россиядә генә түгел, бөтен дөнья буенча таралган. Компанияне оештыручылар Лондонда яши, дип фаразлана. Ләкин конкрет исемнәр, адреслар сайтта күрсәтелмәгән. Төптән уйлый торганрак кешене тагын бер мәгълүмат туктатырга мөмкин: «Пользователь согласен с тем, что Общество оставляет за собой право прекратить действие учетной записи Пользователя на Cashbery.com в любое время без предварительного уведомления Пользователя». Ягъни оешма теләсә кайсы көнне эшен туктатырга мөмкин. Шунда ук тагын бер шарт язылган: салган акчаларны икенче, унынчы көнне дә кире алып булмый. Аны фәкать 400 көн дәвамында процентлары белән генә кайтарырга мөмкин. Ә компания аның кадәр яшәрме, монысы инде, теге мәгълүм мәзәктәге кебек, икенче сорау.

Әлбәттә, туганнарым да, акча салучы башка миллионлаган кешеләр дә бу хакта белгән. Тик шуңа карамастан, кеше соңгы акчаларын (Интернетта сәгать саен яңа мәгълүматлар чыгып тора: фатирларын сатып «Кэшбери»га салучылар да күп), кемдер зур суммада кредитлар алып компания счетына салган.

Ни кызганыч, меңләгән кешенең өмете чираттагы мәртәбә чәлпәрәмә килде: 12 октябрь көнне оешма эшен туктатты. «Кэшбери»ның рәсми сайтында: «Вакытлыча кыенлыклар килеп чыкты, счетларга арест салынды. Эшне 1 нче ноябрьгә кадәр туктатып торабыз», – дип язылган. Бүген аның эшен РФ Генераль прокуратурасы тикшерә. Аналитиклар компания башка эшли алмаячак, дип белдерә. Үзәк Банкның намуссыз тәҗрибәгә каршы көрәш департаменты директоры Валерий Лях әлеге оешма турында: «Соңгы елларда билгеле булган пирамидаларның иң масштаблысы. Ул үз эшчәнлеген Россиянең күп кенә төбәкләрендә башлап җибәреп, бөтен ил буенча диярлек җәелдерген. Һәм соңгы вакытта үзенә тагын да күбрәк гражданнарны җәлеп итү өчен, көчлерәк реклама ясый», – диде.

Чынлап та, «Кэшбери» нигездә реклама хисабына яшәгән. Алай гына да түгел, танылган сәхнә йолдызлары биредә акча эшләп була икәнен кат-кат ассызыклаган. Компаниянең гимнын хәтта Николай Басков үзе җырлый. Кыскасы, ышанмас җиреңнән ышанырсың. Өстәвенә, туганнарым очрагындагы кебек, янәшәңдә көн саен әлеге оешмадан процентлар килеп торган кешеләр дә булса.

ОСТАРАЛАР!

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсенә «Кэшбери»дан зыян күргән кешеләр мөрәҗәгать итмәгән. Тик бу вакытлы күренеш икән: гадәттә финанс пирамидалары банкрот дип табылганнан соң, гариза язучыларның саны бихисап була.

Бер факт кызык тоелды: республикада финанс пирамидалары белән бәйле җинаять эшләре елдан-ел кимеп бара. Мисал өчен, 2014 елда – 14 эш, 2015 елда – 24 эш, 2016 елда – 4 эш, 2017 елда – 2, 2018 елда 2 эш ачыкланган.

– Тик бу финанс пирамидалары хәзер аз дигән сүз түгел, – диде ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсенең финанс-кредит системасында җинаятьләргә чик кую бүлеге җитәкчесе Руслан Дәүләтьяров. – Хәзер дә бик күп алар. Эш бары шунда: бүген алар интернет аша эшли. Ә виртуаль дөньяда төеннең башын табу бик авыр. Гадәттә оештыручылар чит илдә яши. Димәк, үзебез генә эшли алмыйбыз, Интерполны да җәлеп итәргә кирәк. Ә бу эшне әллә ничә тапкырга катлауландыра. Безнең хезмәткәрләр чит илгә барып йөри алмый бит. Хәтта Мәскәү белән бәйле оешмалар белән эшләү дә гаять авыр.

Бүген хокук саклау органнары ике оешманы тикшерү белән мәш-

гуль. Узган ел исә шулай ук ике кооператив үзәк – «Центральная Сберкасса» белән «Приволжский фонд сбережений»ларның эшен судка җибәргәннәр. Беренчесенең төп офисы Казанда урнашкан. Тик филиаллары Россиянең башка шәһәрләрендә дә бар икән. ТР буенча Эчке эшләр министрлыгына «Центральная Сберкасса» өстеннән 1300 гариза кергән. Гражданнарга килгән зыян суммасы – 195 миллион сум дип исәпләнә. «Приволжский фонд сбережений» кооперативының үзәге Хабаровскида булган.

– Алар белән эш катлаулырак булды, – диде тикшерүче. – Фондның эш системасы акчаны процентлап кайтарудан аерыла. Шуңа аларны финанс пирамидасы дип тану авыррак. «Приволжский фонд сбережений» акчаны төзелешкә кертүгә корылган. Төрле займнар бирү белән дә шөгыльләнгәннәр. Ягъни бизнес системасы алымнары бар. Оештыручыларны «мошенник»лар дип тану өчен документларны кат-кат өйрәнеп, катлаулы финанс экспертизалары үткәрергә туры килде.

Кооперативтан зыян күрүчеләр Татарстанда 3 мең кеше, алар җәмгысе 900 миллион сум акчаларын югалткан.

Ә хәзер иң кызыгы: финанс пирамидалары төзеп, меңәрләгән кешене тораксыз, акчасыз, кредитларга батырып калдыручыга каралган иң зур җәза – 8 елга кадәр ирегеннән мәхрүм итү. Әле моны да һәрвакыт кулланып булмый: әгәр моңа кадәр суд хөкеменә тартылмаган булса, мошенникны нибары шартлы рәвештә генә ирегеннән мәхрүм итәргә мөмкиннәр. Явыз нияте булмаганын раслый алса, билгеле. (Хәер, яхшы нияттән кешене талау ничек була икән, анысын күз алдыма да китерә алмыйм!)

– Яхшы, пирамиданың хуҗалары кулга алынды. Тик алданган гражданнар акчаларын кире кайтара аламы? Андый тәҗрибә бармы? – дим Руслан Маратовичка.

– Ни кызганыч, андый очраклар күп түгел. Безнең бурыч – пирамида төзегән мошенникларның эзенә төшү. Ә гражданнарга акчаларын кайтару өчен суд, приставлар бар. Дөресен әйтим, акчаны кайтару бик авыр. Аңлашыла бит: «пирамида хуҗасы» миллионлаган акчасын өстәл тартмасында тотмый. Ул бит үзенең иртәмесоңмы сак астына алыначагын белә. Шуңа да алдан ук хәстәрен күрә: кыйммәтле тораклар ала, күп очракта чит илләрдә. Һәм аларның берсен дә үз исеменә яздырмый, туганын, танышын, кемгә ышана, шуларны «хуҗа» итә. Аның исеменә бернәрсә дә теркәлгән булмый. Рәсми рәвештә мошенниктан бернәрсә дә алып булмый. Руслар әйтмешли: «Юкка суд та юк».

Тикшерүче, тәҗрибәсеннән чыгып, чәчләр үрә торырлык хәлләр

турында сөйләде. Пирамидага акча салам, дип, соңгы фатирларын сатып, сукбай булып йөрүчеләр дә бар икән.

– Чынлыкта, бик куркыныч юл бу, гражданнар шуны аңласын иде, – диде Руслан Дәүләтьяров. – Акчагызны андый җирләргә илтеп биргәнче, ни булып бетәсен уйлагыз: ә ала алмасагыз? Банкротлыкка чыккач, бик күпләр төшенкелеккә бирелә, эшен ташлый, гаиләсен югалта.

– Ә ни өчен эшен ташлый? – дим.

– Туктаусыз суд эшләре башлана. Гел эштән сорап китеп булмый, кеше башта административ ял ала. Акчаны кайтарам, дип, янып йөри башлый. Гадәттә, кайтара алмый. Тик инде ул эшенә дә бармый, үзен кулга ала алмый. Үз-үзенә кул салу очраклары бик күп... Күз алдымда булган хәлләр турында әйтәм, тормыштан алып. Алар берсе дә шул хәлгә төшәм дип уйламаган, билгеле. Тагын шунысы да бар: акчасын кайтарган кешеләр дә кире илтеп сала бит, янәсе тагын да күбрәк эшләячәкмен... Ә аннан әкияттәге кебек ярык тагарак алдында утырып калалар.

«ЛОХОТРОН»

Икътисад фәннәре докторы, профессор Илдар Аблаев финанс пирамидаларын шулай дип атады. Әле аларны «Буратинолар ярминкәсе» дип тә атыйлар икән.

– Иң беренче шуны әйтим: акчасы булган кеше дәүләт банкларына барсын, депозитка салсын. Начармы, яхшымы, ләкин барыбер табыш керә, – диде Илдар әфәнде. – Әлбәттә, финанс пирамидалары 100 процентка кадәр табыш вәгъдә итә. Менә мондый саннар иң беренче сигнал булырга тиеш. Бу пирамиданың ап-ачык мисалы. Кешегә мондый акчалар бирү өчен, кооператив хуҗалары нинди дә булса чыганаклардан акчалар алырга тиеш. Ә каян? Тагын шундый ук кешеләрдән. Менә бу пирамиданың башлангычы инде. Әйе, монда беренче керүчеләр ота. Икенче, өченче дулкын белән керүчеләр дә ота әле. Ә менә бишенче, алтынчы баскычтагыларның проблемалары башлана. Ни өчен дигәндә, 5 кешегә акча бирү өчен 10 кеше, 10 кешегә – 20, 20 гә 40 акча салучы табарга кирәк. Пирамида өскә күтәрелгән саен «ашарга сораучылар» күбәя генә. Бер айда 30 мең кеше керсә, икенче айда ул кешеләргә түләү өчен тагын 60 мең кеше кирәк. Аның кадәр табылмаса, бетте, пирамида «карта өе» кебек ишелә дә төшә. Шунысы бар: шәһәр зуррак булган саен, пирамидада кеше саны да күбрәк була. Ләкин, әйткәнемчә, ул кайчан да булса бер барыбер шартлаячак. Гадәттә алар, күп дигәндә, ике-өч ел яши. Хәер, ярты ел эшләүчеләре дә бар. Бу оештыручыларның ни дәрәҗәдә реклама бирүенә, күпме кеше җәлеп итүенә карый.

Илдар Аблаев финанс пирамидалары темасы белән күптән шөгыльләнә. Тәҗрибәсенә, күзәтүләренә нигезләнеп, менә нәрсәләр сөйләде ул:

– Андый җирләргә акча салучыларны ике төркемгә бүлеп карар идем: беренчеләре – беркатлылар. Монда күбрәк өлкән яшьтәге кешеләр керә, икенче төркем – җиңел яшәргә теләүчеләр. Алар пирамиданың кайчан да булса ишеләсен аңлый, тик «бүген, хәзер яшәп калыйм» дип уйлый, «бәлки, уңыш елмаер» дип ышана. «Ул ябылганчы, мин акча эшләп алам әле», – дип гөман кыла. Соңгылары, гадәттә, акчаны берничә тапкыр сала. Акча кергән саен күбрәк кирәк, эшләмичә генә рәхәт яшәү күзне, аңны томалый...

Финанс пирамидалары беркайчан бетмәячәк, ди аналитиклар. Мондый беренче оешмаларның 600 ел элек Голландиядә оешканлыгы билгеле. Илдар Мансурович та безнең фикерне куәтләде:

– Гафу үтенәм, кемнедер үпкәләтәсем килми, ләкин пирамидага акча салучыларны «лох» дип йөртәләр. Миңа калса, туры килә. Аңлы рәвештә батып баручы корабльгә утыру белән бер бит: ә бәлки исән калырмын, дип... Исән калган очракта да, акчасын процентларда кайтарган очракта да, аның бәрәкәте булмый. Җиңел кергән акчалар җиңел чыгып та китә. «Ә, ярар, иртәгә тагын шулай киләчәк», – дип уйлый кеше. Ә иртәгә булмаска да мөмкин. Меңләгән кеше кредитлар ала да пирамидага сала. Тик керә барган акчаны кредитын капларга салмый, туздыра тора. Җиңел акча ул бик куркыныч әйбер, кешене юлдан яздыра.

...Иң аянычы, авыл кешеләре дә шул юлга баскан. Балтач районына баргач, шундый берничә кеше белән аралашырга туры килде. Берәү илле мең бурычка алып торган, икенчесе сиксән мең кредит алган. Районы-районы белән бер пирамидада «утыручылар» бар. Нишлисең, «чыбыксыз телефон» яхшы эшли.



«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НӘ – СӘЛАМӘТЛЕК ҺӘМ МАТУРЛЫК ЭЗЛӘП

Күптән түгел минем пенсионер әнием һәм укучы кызым шифаханәдән кайттылар. Мин аларны, берсе туктаусыз умырткасы һәм аяклары сызлаудан интеккәнгә, икенчесе, бөтен яшьтәшләре кебек үк, фастфудка алданып, гастрит авыруына дучар булганга күрә, шунда җибәргән идем.

– Көз алдыңа китерәсеңме, санаторийда без көн саен терренкурга бара идек, ә хәзер мин тукталыштан өйгә кадәр бик җиңел генә кайттым, аркам да бөтенләй авыртмый! – дип белдерде әни дәвалануының нәтиҗәләре турында сөйләгәндә. Ул үзе дә, кызым да ял иткән, сафланып киткән һәм күңелләре күтәренке иде.

радуга
ТАТАРСТАН ШИФАХАНӘЛӘРЕ

Татарстан,
Яр Чаллы ш.,
«Түбән Кама»
Милли
паркының
Нарат урманы

Урнаштыру хезмәте:
8 (8552) 20-56-26

Веб-сайт:
www.lokraduga.ru

Әнием – шифаханәләрдә ял итүнең ветераны, төрлесендә булганы бар, димәк, чагыштыра ала. Ә мин «Салават күпере»нә юлламалар сатып алган чакта мондый ук нәтиҗәне көтмәгән идем. Мин аның шул ягына кызыктым: монда авыруның һәр төренә үз программасы эшләнгән. Аларның икесе – «Арканы һәм буыннарны дәвалау» һәм «Ашказаны-эчәклек трактын дәвалау» дигәне минем гаиләдәгеләргә идеаль туры килә иде.

Кич чәй янына утыргач, икесе дә, берберсен бүлдерә-бүлдерә, ял тәэсирләре белән уртаклаша башладылар. Ә мин, һәр нәрсәне системага салу гадәтем булганга, аларның сүзләреннән чыгып һәм шифаханәнең сайтын өйрәнеп, «Салават күпере»нең төп үзенчәлекләрен чыгардым. Беренчедән, ул «Түбән Кама» Милли паркы территориясендә, нарат урманы эчендә урнашкан, ә анда һава да дәвалый. Безнең күренекле якташыбыз Иван Шишкин бу искиткеч урыннарны юкка гына данламаган, аның «Нарат урманындагы иртә» дигән картинасын хәтерлисезме?

Икенчедән, биредә үз минераль дәва чыганагы бар. Суны 256 метр тирәнлектән чыгаралар, һәм ул ашказаны-эчәк трактындагы күп авырулардан файдалы. Артезиан суы хәтта номерларда да краннардан ага.

Өченчедән, «Салават күпере»ндә – бик яхшы дәвалау базасы, ул иң заманча һәм нәтиҗәле медицина технологияләрен файдалану мөмкинлеген бирә.

Дүртенчедән, шифаханә аерым авыруларны дәвалауга гына түгел, төрле категориядәге ял итүчеләргә дә дистәләгән сәламәтләндерү программасын тәкъдим итәләр. Мәсәлән, «Сәламәтлек энергиясе» дигән гомуми ныгыту программасыннан тыш, тар юнәлештәгеләрен дә – «Сәламәт йөрәк», «Шикәр диабеты белән яшәү» һ.б.ларны да сайларга була. Булачак әниләргә – «Сәламәт сабый», ябыгырга теләгәннәргә «Фигураны коррекцияләү» дигән махсус курслар эшләнгән.

Бишенчедән, монда уникаль, нәтиҗәле, куркынычсыз һәм бөтенләй авырттырмый торган процедуралар кулланыла. Мәсәлән, канны тымырлар аша лазер белән нурландыру – иммун системасын ныгыту һәм организмны тернәкләндерү өчен гаҗәеп көчле чара, аның нәтиҗәсе ярты елга кадәр дәвам итә; озон терапиясе – нәтиҗәлелеге буенча липоксация белән генә чагыштырырлык бердәнбер методика, фармакопунктура – организмның көйләү механизмнарын сафка бастыручы дәвалау ысулы һәм организмны тиз арада сафка бастыру һәм сәламәт дулкынга көйләү мөмкинлеге бирүче башка күп чаралар.

Алтынчыдан, «Салават күпере»ндә ял итү бәяләре, башка шифаханәләр белән чагыштырганда, күпкә демократик, юллама бәясенә шактый сандагы процедуралар керә, димәк, алар өчен өстәмә түлисе юк. Тагын җиденче, сигезенче пунктлар да бар әле: уңайлы яшәү шартлары, бай меню һәм бик яхшы шеф-повар. «Салават күпере» юкка гына Россиянең иң яхшы 100 топшифаханәсе исемлегенә керми инде.

– Ә мин шифаханә – һич тә заманча ысул түгел һәм анда бик күңелсез була, дип уйлаган идем, «Салават күпере»ндә безгә бик күңелле булды! – дип уртаклашты кызым, бер уңайдан торт кисәге белән сыйлана-сыйлана, ә бит элек мондый сыйдан эче авыртырга тотына иде. Ул тагын ял итүчеләр өчен көн дә кино күрсәтелүе, «Угадай мелодию», «Слабое звено» кебек уеннар, концертлар һәм дискотекалар оештырылуы турында да сөйләде. Ул туйганчы бассейнда йөзгән, велосипед һәм роликларда йөргән (алары прокатка бирелә икән), Алабугага экскурсиягә барган.

Бу мәдхияләрне тыңлаганнан соң, үзем дә ял итү турында уйлана башладым. Өстәвенә, «Салават күпере»ндә Яңа ел өчен ике яңа программа эшләнгән, алар кышкы каникулны тән һәм җан өчен файдалы итеп үткәрү мөмкинлеге бирәчәк. Берсе нәкъ шулай атала да – «Яңа ел рәхәтлеге». Ул кыска гына вакыт арасында сәламәтләнү генә түгел, яшәрү тәэсирен дә алырга теләгән хатын-кызларга каралган. Процедуралар комплексы шундый итеп сайланган – алар бер үк вакытта тәнне ял иттереп һәм аны энергиягә баетып, бер-берсе белән идеаль рәвештә яраша һәм уңай тәэсирне тагын да көчәйтә. Программага кедр мичкәсе, массаж, дәвалау ванналары, гидромассаж, озон терапиясе, парафин терапиясе, тоз белән төрү, пневмомассаж керә.

«Сәламәтлек эликсиры» программасы күбрәк SPAга түгел, ә сәламәтләндерү тәэсиренә корылган. Ул иммунитетны ныгытучы һәм ел буена җитәрлек көч бирүче дәвалау процедураларыннан тора. Программага су процедуралары, дәвалау физкультурасы, бассейн, физиотерапия, дәвалау массажы, кислород коктейле, парафин терапиясе, ароматерапия керә.

Кайсын сайларга икәнен мин әлегә хәл итмәдем. Әмма ашыгырга кирәк инде. 1 декабрьгә кадәр бронь ясасаң, махсус тәкъдим дә бар – «Сәламәтлек эликсиры» һәм «Яңа ел рәхәтлеге»нә юлламалар 17 мең сум гына торачак.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Фотолар «Салават күпере шифаханәсе» ЯАҖнән алынды. Реклама.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Өстәлләребездә **КАЙЧАН** чөгә балыгы пәйда булыр

Чын осталар тавыкны **НИЧЕК** әзерли

Татарстан театрлары туристларны **НӘРСӘ** белән җәлеп итә

ЧИСТА СУ БАЛЫГЫ

Татарстанда мәрсиннәрнең кыйммәтле вәкилләре популяциясен торгызу программасы гамәлгә ашырыла: күптән түгел «Чөгә балыгының уылдык чәчү урыны» дәүләт заказнигы оештырылды. Әмма әлеге кыйммәтле балык безнең өстәлләрдә пәйда булсын өчен бу гына җитәрме соң?



Автор:
Ольга Туманская

МӘРСИННӘР ӨЧЕН «РОДДОМ»

Салкын, җилле, шыксыз… Нәсел, токым калдыру турындагы уйлар өчен иң яхшы урын түгел кебек. Ләкин бу турыда мәрсиннәргә әйтеп кара син! Арасыннан салкынча агым уза торган вак һәм зур йомры ташлар өеме – мәрсиннәрнең «краснокнижник» дип аталган төрен үрчетү өчен төп урын. Ябышучан уылдыклар елга үзәненең иң тиз агымлы урыннарында да төпкә ныгып калырга сәләтле. Затлы мәрсин ләмне яратмый, аның каравы суның чисталыгын һәм агымның тизлеген бәяли белә.

Татарстанда мондый урыннар, әллә ни күп калмаса да, бар әле. Республиканың тугыз районы территориясендә урнашкан ун су участогы «Чөгә балыгының уылдык чәчү урыны» дип аталган зур бер проектка берләштерелгән. Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология заказнигын оештыру турындагы тиешле карар ТР Министрлар Кабинеты тарафыннан узган елның декабрь аенда имзаланган иде. Быел исә төп оештыру эшләре башкарылды.

Гади кеше буларак миңа шунысы кызык: әлеге заказник нindirәк? Күз белән караганда, ул гадәти сулыктан бары тик су янында урнаштырылган күрсәткеч такталар белән генә аерыла, анысы да балыкчылар өчен. «Чөгә балыгының уылдык чәчү урыны» географик координаталары төгәл билгеләнгән, һәм алар Биоресурслар буенча ТР дәүләт комитеты сайтында урнаштырылган. Заказник территорияләрендә файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару буенча һәртөрле эшчәнлек тулысынча тыелган, һәм шулай ук сәнәгать дәрәҗәсендә балык тотарга да рөхсәт ителми.

Заказникның гомуми мәйданы – 1750 гектар. Әлеге участоклар фаунаның башка сирәк төрләре яши торган урын булып санала. Алар арасында республика әһәмиятендәге 23 «краснокнижник», шуларның 8е Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән. «Фон» тудыручы дип аталган балыклар – корбан балыгы, чабак, сазан, карабалык, судак (сыла), җәен, чуртан һәм башкалар. Әйтик, мәсәлән, Түбән Кама сусаклагычы районындагы заказник участокларында 14 семьялыкка кергән 42 төр исәпләнә, шуларның 20се – сәнәгать өчен тотарга яраклылар…

– Ә балыкчыларга берәр нәрсә каламы? – дип сорадым мин Биоресурслар буенча ТР дәүләт комитетының су биологик ресурслары

Фото: Александр Ефремов

бүлеге башлыгы Ирина Мөстәкыймовадан.

– Безнең монда үзебезнең «татар диңгезе»! – дип елмая ул. – Без башка республикаларга караганда шактый зур күләмнәрдәге су запасларына ия. Шуңа күрә балыкчыларга да җитәрлек! Ләкин чираттагы мәртәбә исләренә төшерәсем килә: бездә чөгәләрне тоту тыела. Гомумән. Һәм әгәр балык очраклы рәвештә генә кармакка эләгә икән, аны җибәрергә тиешләр. Вәсвәсәгә бирелеп, киресен эшләүчеләргә җинаять җаваплылыгы яный. Без балаларыбыз һәм оныкларыбызның чөгә балыкларын ашауларын телибез, шуңа күрә шундый киң колачлы эш башкарабыз.

Беренче карашка заказник территориясен беркем дә күзәтми кебек тоелырга мөмкин. Чынлыкта исә күзәтчелек техниканың соңгы казанышларына таянып башкарыла. ГЛОНАСС системасы судноларның һәм баржаларның суга чыгуына җентекле рәвештә күзәтчелек итә. Һавада әкрен генә квадрокоптерлар йөри. Беспилотниклар мәгълүматны реаль вакыт режимында тиешле хезмәтләргә тапшырып тора. Кирәк булган очракта ихтимал булган җинаять эшләре буенча дәлилләү базасы белән тәэмин итә, чөнки видеога җинаятьнең барлык адымнары да теркәлеп бара.

– Быел гына да безнең хезмәткәрләр булышлыгы белән чөгәләрне тотуга кагылышлы өч җинаять эше ачылды, – ди Биоресурслар буенча ТР дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аерым саклана торган табигать территорияләре сферасында дәүләт күзәтчелеге идарәсе башлыгы Радик Мөтәхәров. – Чулман һәм Нократ елгаларында тотылган балыклары белән балыкчыларны тотабыз. Соңгысы Куйбышев сусаклагычы районында 11 сентябрьдә булды. Гражданин 60 метрлы ятьмә белән балык тота иде. Тотылганнар арасында 12 чөгә балыгы да бар. Хәзерге вакытта РФ Җинаять кодексының «Су биологик ресурсларын законсыз табу (тоту)» дип аталган 256 нчы маддәсе нигезендә җинаять эше ачу турындагы сорау хәл ителә. Браконьерга штраф яисә ике елга кадәрге срок белән ирегеннән мәхрүм итү яный. Уылдык чәчү урыннарында мондый хәлләрнең булганы юк – без профилактикалау буенча төгәл эш алып барабыз.

«Чөгә балыгының уылдык чәчү урыны» заказнигының гомуми мәйданы – 1750 гектар. Заказник территориясендә файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару буенча һәртөрле эшчәнлек тулысынча тыелган, һәм шулай ук сәнәгать дәрәҗәсендә балык тотарга да рөхсәт ителми.



Казан губернасында чөгә балыгын үрчетү белән киң күләмдә шөгыльләнә башлау 1913-1916 елларга карый. Шул заманнарда ук ул инде аз була!

Әлеге проектны төзүчеләрнең сүзләренә караганда, заказникка кергән су участоклары чөгәләрнең тарихи яктан билгеле табигый уылдык чәчү урыннары санала. Асылда, бик аз нәрсә таләп ителә – кеше бары тик балыкларга комачауламаска гына тиеш. Димәк, балык үзе яраткан урыннарга уылдык чәчәргә килә башлаячак?

ДИНОЗАВРЛАРНЫҢ ЗАМАНДАШЫ

– Чөгә – борынгы балык, эволюцион яшьтәшләре бик күптәннән югалган кимерчәкле ганоид, – дип сөйләде миңа Казан дәүләт энергетика университетының су биоресурслары һәм аквакультура кафедрасы мөдире, профессор Марина Калайда. – Казан губернасында чөгә балыгын үрчетү белән киң күләмдә шөгыльләнә башлау 1913–1916 елларга карый. Шул заманнарда ук ул инде аз була! Чөгәләрнең ясалма маймычларын алу буенча эшләр 1916 елда башлана. Уылдык инкубацияләнә торган аппаратлар уйлап табыла. Ләкин илдә башланып киткән революция әлеге бурычлардан бүлдерә, аннан соң – Бөек Ватан сугышы... Ә алдагы елларда ил күләмендә гидроэлектростанцияләр төзелеше киң җәелдерелә. Алар елгалардагы агым тизлеген киметә, вак ташлы грунтларга әкренләп ләм утыра. Чөгәләргә уылдык чәчәргә урын калмый – аны яңадан торгызуның нәтиҗәлелеге бөтенләй кими. Моннан тыш, әлеге сөйләшүебездә тагын бер әһәмиятле момент бар.

– Күптән түгел генә дөньяда кеше саны миллиард тирәсе санала иде, ә бүген исә җиде миллиардка якын кеше исәпләнә, – дип билгеләп үтә Марина Калайда. – Нәтиҗә ясап карыйк. Димәк, елгаларда балык үрчетү шактыйга кимегән, ә куллану ихтыяҗы арткан.

...Су биоресурслары һәм аквакультура кафедрасы урнашкан бүлмә түрендә махсус ике катлы итеп балык-су установкалары урнаштырылган. Менә каршымда чөгә белән мәрсиннең гибриды бер стенадан икенче стенага таба йөзә, ә менә чөгәнең анасы... Бу сикерүчән балык, шуңа күрә резервуага челтәр тарттырылган, суның температурасы һәм сыйфаты һәр бассейнда аерым көйләнә торган итеп эшләнгән. Кыслаларның «өйләрендә» суның тик торуын, ә чөгәләрнекенең күбекләнүен һәм хәрәкәтләнүен күрәм.

– Монда, су белән тәэмин итүнең йомык җайланмаларында, без чөгә өчен туры килә торган параметрларны саклый алабыз, – дип сөйли Марина Калайда. – Табигый мохиттә аны торгызу өчен иң яхшы участоклар Чулман һәм Иделнең елга режимы сакланып калган үрге агымында урнашкан. Нәкъ менә шул урыннарда заказникның уылдык чәчү урыннары урнашкан да. Чуерташлык монда табигый генә түгел, бу урыннарны әле 90 нчы елларда ук Казан елга порты компенсацион чаралар буларак юган. Кызганыч, бу эшләр күптән туктатылган.

Заказникның участоклары дөрес билгеләнгәнме соң? Вакыт күрсәтер, төгәлрәге – популяциянең сан ягыннан үзгәрешен ачыклау буенча мониторинг тикшеренүләре. Чөгә май аенда уылдык чәчә. Димәк, галимнәр инде киләсе елның язы ахырында ук ул урыннарда уылдык һәм яшь балыкларны җыярга тырышып караячак. Әгәр чөгә уылдык чәчү урынын үз итеп өлгерә икән, галимнәр моны күрәчәк. Әгәр бу урынны яратмасалар? Димәк, балыкка нәрсәдер ошамаган. Ә бәлки ул уылдыгын чәчкән дә инде киткәндер... Шуңа да бу бер еллык кына эш түгел.

Нәрсә генә булса да, заказниктан файда булачак, дип саный Марина Львовна. Теге яки бу формада. Бу кешеләргә актив рәвештә хуҗалык эшчәнлеге белән шөгыльләнү тыелган зона бит.

Чөгә балыгы популяциясен уылдык чәчү урыннарын булдырып кына арттыру мөмкинме соң? Менә без әлеге урыннарны билгеләдек, инде тынычланып, бу затлы балыкларның Татарстан сулыкларын тутыруларын көтеп утырырга тиешбезме? Әлбәттә, юк, дип раслый белгеч. Без табигатькә булышырга тиеш: республикада даими нигездә чөгә маймычын җитештерү буенча эшне көйләп җибәрергә кирәк. Аларның күпмедер өлеше һичшиксез җайлашачак, уылдык чәчү өчен кулай урын табачак. Ә инде якынтирәдә маймычлар үрчетү буенча завод та ачып җибәрсәк, бу эш тагын да нәтиҗәлерәккә әвереләчәк,

Чөгә балыгы популяциясен уылдык чәчү урыннарын булдырып кына арттыру мөмкинме соң? Әлбәттә, юк, ди Марина Калайда.

чөнки чөгә еракка китеп йөрми. Уылдык чәчкәнгә кадәр аңарга йөргәргә кирәк, ә азык базасы безнең акваториядә бар, гәрчә тигез бүленгән булмаса да.

БЕЗНЕҢ ӨСТӘЛДӘГЕ ЧӨГӘ

Күптән түгел генә «Минем алтын балыгым» акциясендә катнашучы балалар чөгә маймычларын суга җибәрделәр – Идел белән Нократ кушылган урында булды бу вакыйга. Әлеге балыклар – яңа коммерциячел балык үрчетү комплексының беренче «балалары», биредә елына 5 миллионга кадәр чөгә маймычы үрчетү планлаштырыла. Сүз уңаеннан, Татарстанда бүгенге көндә чөгә маймычы җитештерүче берничә предприятие бар инде. Бәлки бу безнең сулыкларда чөгә популяциясен торгызуга ярдәм итәр дә?

…Марина Калайда миңа спиртка салынган чөгәле колбаны күрсәтә. Балачагымнан бирле әлеге балыкны болай якыннан күргәнем юк иде. Аның сыртында сөяк үсентеләр күп – алар чәнчи, өстәвенә озын каты борыны – рострумы да бар икән чөгәнең. Гомумән, ерткычлар өчен җайлы балык түгел. Һәм хәтта кечкенә саналганы – 3–5 граммлысының да шундый ук саклык чаралары бар, дип сөйли Марина Львовна. Шуңа күрә, мәсәлән, айбалык 3 млн уылдык сала, ә безнең сулыклардагы чөгә – барлыгы 10 мең данәне генә. Табигатьтә аның дошманнары юк! Әлеге төрнең исән калуы, иң беренче чиратта, мохит параметрларыннан тора икән. Хәер, башка принципиаль аспектлар да юк түгел. Шуларның берсе: ясалма юл белән алынган чөгә табигый үрчүгә сәләтлеме?

– Фәндә әлегә төгәл генә җавап юк, – ди Марина Калайда. – Ләкин минем менә нәрсә әйтәсем килә. 1980 елда ак амур балыгы буенча да, юанбаш балыклар буенча да хәлләр шундыйрак иде. Ул чакта без Ташкентта узган конференциядә бу хакта фикер алыштык! Бүген ул сөйләшүне барыбыз да оныттык, чөнки бу балыклар шәп үрчиләр.

Әлбәттә, Свияжск янында балалар елгага җибәргән ике йөз маймыч чөгә санын арттыруга кагылышлы вазгыятьне үзгәртә алмаска да бик мөмкин. Татарстан сулыкларында мәрсиннәрнең популяциясен торгызу өчен ел саен күпме яшь балыкны суга җибәрергә кирәк булыр соң?

Бүген маймычларны үрчетү нигездә компенсацион чаралар кысаларында алып барыла: предприятиеләр үз эшчәнлекләре нәтиҗәсендә су биоресурсларына китергән зыянны каплый. Җитештерү күләме һәр аерым очрак өчен махсус методика буенча исәпләнә. Марина Калайда чөгә популяциясенә карата әлеге ысулның нәтиҗәлелегенә анализ ясаган һәм безгә инде күптәннән яшь балыкларны үрчетү эшен бары тик компенсация чараларына бәйләп караудан туктарга кирәк, дип саный.

– Югыйсә сулыкка маймычларны җибәрү өчен, безгә башта биоресурсларга шактый зыян салырга кирәк булып чыга. Ә чөгә инде Кызыл китапка кертелгән, аны шуннан сызып ташларлык итеп эшләргә кирәк! Шуңа да компенсация буларак үрчетү – эшләнергә тиешле гомуми эшнең бары тик бик кечкенә өлеше генә, дип саныйм..

– Соңгы еллар материалларын анализлау күрсәткәнчә, яшь балыкларны җибәрүнең еллык гомуми саны бары тик 211 мең балыкны тәшкил итә, ә бу ихтимал булган балык тотулар күзлегеннән караганда кирәк булган санның бары тик 2,5 проценты гына дигән сүз, – ди галим. – Бу юк дәрәҗәсендә! Асылда, без әле юл башында гына. Бүгенге көндә маймычларны сулыкка җибәрү буенча башкарыла торган компенсацион чаралар балык санын аны Кызыл китаптан төшерерлек дәрәҗәдә үрчетергә мөмкинлек бирми.

XX гасыр башында безнең якларда тотылган балык арасында чөгә 2 процентны тәшкил иткән. Барлыгы! Әле ул заманнарда. Марина Львовна фикеренчә, бүген әнә шул күрсәткечкә генә ирешү өчен дә, ел саен сулыкларга 7–8 млн яшь балык җибәрергә кирәк. Өстәвенә, шуны да истә тотарга кирәк: әлеге тотылган балык арасындагы 2 процентны өлергән, ягъни бер генә тапкыр булса да буын калдырган ун яшьлек (!) чөгә балыгы тәшкил итәргә тиеш. Бу Кызыл китаптан чөгә балыгын сызып ташлый алырбызмы һәм якын араларда аны тотарга рөхсәт булырмы дигән сорауга җавап.

Без әлеге «патшалар балыгын» якын елларда үз өстәлебездә күрергә телибез икән, бәлки аны үрчетүне индустриаль масштабларда башлау турында уйланырга вакыттыр? Су белән тәэмин итүнең идарә ителешле йомык җайланмаларда балык үрчетү, сугыш шартларында исән калу технологиясе буларак, япон галимнәре тарафыннан әле 1951 елда ук тәкъдим ителгән булган. Казан энергоуниверситеты хезмәткәрләренең эше шуны раслый: әлеге методикага таянып, һәр кубик метрдан йөз килограммга кадәр чөгә алырга мөмкин булачак. T

«Минем алтын балыгым» акциясенең яшь катнашучылары. Алар Свияжскига теләк теләр һәм чөгә маймычларын суга җибәрер өчен махсус килде.

Акция вакытындагы һәм Биоресурслар буенча ТР дәүләт комитеты фотолары

Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная Кухня
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
ВЕСТНИК

ЧЫН ОСТАЛАР ТАВЫКНЫ НИЧЕК ӘЗЕРЛИ?

Редакциябез кухнясына профессиональ пешекчеләр еш килми. Ни өчен дигәндә, рубриканың максаты – гади авыл апалары пешергән милли ризыкларыбыз турында сөйләү. Ягы-ягы белән аерыла бит ризыклар. Мисал өчен, актанышлылар, азнакайлылар бәлешне иттән пешерсә, Кайбыч, Апас якларында ул дөге, карабодай ярмасыннан әзерләнә. Шул ук кыстыбый бер якта – «якмыш», икенчесендә – «тәбикмәк». Пешерү ысуллары да төрле...

Бүген әлеге тәртиптән читкәрәк тайпылырга булдык. Үзенчәлекле егет белән милли булмаган ризык әзерләдек. Ни өченме? Сәбәбен алга таба белерсез.

Автор:
Руфия Фазылова

ИКЕ ЯШЬТӘ – ҮЛЕМ БЕЛӘН КӨРӘШҮ

Руслан Соловьев – Казан егете. Яңа гына егерме яшен тутырган. Икенче төркем инвалид. Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллиятенең 4 нче курс студенты, булачак пешекче. Узган ел Татарстан буенча «Абилимпикс» бәйгесе җиңүчесе. (Конкурс сәламәтлеге чикләнгән яшьләр арасында уза. «Абилимпикс» Россиядә чагыштырмача яңа бәйге – беренче тапкыр 2014 елда оештырылган иде. Ә дөнья күләмендә карасаң, алтмыш елдан артык тарихы бар. Беренче тапкыр Японияда 1953 елда узган ул.) Биредә мөмкинлекләре чикле кешеләр һөнәри осталыгын күрсәтә.

Руслан Мәскәүдә узган «Абилимпикс» Россиякүләм бәйгесендә дүртенче урынны яулаган. Аның белән Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллиятендә очраштык. Иң беренче шуны әйтим: әлеге уку йортында 900 дән артык егет-кыз белем ала, 66 сының мөмкинлекләре чикле, алар өчен көллияттә махсус төркемнәр дә оештырылган.

Руслан исә махсус төркемдә укымый, ә сау яшьтәшләре белән белем ала. Гаҗәп тә түгел, ясалма уң як күзен санамаганда, аның бар җире дә сау-сәламәт. Тормышы, көнкүреше башка яшьтәшләренекеннән аерылмый.

– Ике яшемдә миңа яман шеш диагнозы куйганнар, – дип сүзен башлады Руслан. (Бу хакта бер дә тартынмыйча, иркенләп сөйли.) – Аңа кадәр саусәламәт бала булганмын. Ике яшемдә күземнең агында кара тимгелләр барлыкка килә башлаган. Күз табибына алып барганнар. Тик анда: «Борчылыр урын юк», – дип кайтарып җибәргәннәр. Хәлем көннән-көн начарлана башлагач, әни Балалар республика клиник хастаханәсенә киткән. Шунда гына чын диагноз ачыкланган: күз алмасында яман шеш тапканнар. Һәм безне тиз арада Мәскәүгә җибәргәннәр. «Әгәр күзне тулысы белән алып атмасак, ямаш шеш таралачак», – дигәннәр. Әни ул вакытларны бүген дә күз яшьләре белән искә ала. Шулай итеп уң күземә операция ясаганнар. Мин үземне белгәннән бирле ясалма күз белән йөрим. Күндем инде, шулай тиеш кебек кабул итәм.

РУСЛАН СОЛОВЬЕВТАН ТАВЫК РУЛЕТЫ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Тавык ите (ак ит) – 0,5 кг
2. Шампиньон гөмбәсе – 0,2 кг
3. Сөт өсте – 150 г
4. Тоз – чама белән
5. Борыч – чама белән
6. Сыер мае – 0,1 кг

Бизәр өчен:
1. Кыяр – 1-2 данә
2. Помидор – 1 данә
3. Сыр – 50 г

Фото: Лилиана Вәлитова

Руслан бу турыда бик гади итеп, бер нәрсә булмагандай сөйли. Ә чынлыкта гомер буе бер күз белән яшәү, әлбәттә, рәхәт түгел. Үсмер чорда да кыенсынгандыр да. Ә ул сер бирми, үзен чын ирләрчә тота. Аның мескен буласы килми, бу хакта кат-кат әйтте! Хәтта әти-әнисе янынннан да чыгып киткән, мөстәкыйль тормыш белән яшисе килгән.

– Якыннарым миңа артык кайгыртучанлык күрсәтә иде, – ди Руслан. – Үсмер чорда шуның аркасында әти-әни белән конфликтка да кергәләдем. Мин бит ир кеше! Өйләнергә, тормыш алып барырга тиешмен. «Әни баласы» булып йөрү минем холкыма туры килми. Шуңа күрә ике ел инде, фатир арендалап үзем генә яшим. Уку белән бергә эшне дә алып барам, ресторанга урнаштым.

«ГАИЛӘ БЕЛӘН ӘЗЕРЛИБЕЗ»

Русланның әтисе – рус, әнисе татар милләтеннән. Егет татарча белми:

– Кызганыч, ана телемдә сөйләшмим. Гаиләдә рус телендә генә аралаштык, шулай да татарча аерым сүзләрне аңлыйм, – диде. Яшь пешекче өчпочмак, кыстыбый кебек милли ризыкларның ничек әзерлисен белә, чөнки аларны ашап үскән. Ә үзе исә беренче, икенче ашлар әзерләүгә өстенлек бирә икән.

– Дөресен әйтим, камыр ризыклары бик уңмый минем, – диде.

Алдан ук Руслан безгә тавык итеннән гөмбәле рулет әзерләргә вәгъдә иткән иде. «Үзе җиңел, үзе затлы», – дип кызыктырып куйды.

Чын пешекчеләр кебек, башта җиңел алымнар белән бөтен тавыкны бүлгәләргә керешә:

– Тавык бозлы булырга тиеш түгел, – диде. – Иплап кенә без аның түшеннән ак итен аерып алабыз да, калган өлешен кире суыткычка куябыз. Шулпага әйбәт булачак анысы. Рулетка ит калын кирәкми, шуңа күрә тавыкның ак җирен тигезләп бүләбез, җәймә кебек килеп чыксын. Аннан ике ягына да тоз, борыч сибәбез. Һәм аны суыткычка куябыз, тоз, борыч сеңә торсын.

Шул арада Руслан эчлек әзерләргә керешә. Башта шампиньон гөмбәсен турап, майлы табада аз гына кыздырып алды. Шуның өстенә сөт өсте (каймак та ярый) салып, биш минутка пешерергә куйды.

– Тавык ите коры була, ә гөмбә белән каймак катнашмасы аны сусыл, йомшак итәчәк, – диде Руслан. – Тавык рулетының берничә төрен пешереп караганым бар, иң тәмлесе гөмбә белән килеп чыга. Һәрхәлдә, безнең гаилә шулай ярата. Җиңел әзерләнә, тиз пешә. Телгән кеше тавык итен тоз, борыч белән генә дә төрәп электр миченә куя ала. Әйе, ул корырак була, тик аны табынга берәр соус белән бирергә мөмкин.

Гөмбә әзер. Руслан табаны уттан алып, өстәлгә куйды. Һәм суыткычтан ит кисәкләрен чыгарды. Шуннан бик җиңел, тиз итеп эчлекне ит өстенә җәеп тә чыкты:

– Минем рулетларым кечкенә, – диде Руслан. – Тавыгым 1 килолы гына иде. Зур тавыктан зур рулетлар чыга, кунакларга әзерләгәндә аң булырга кирәк.

Руслан башта рулетларны үтә күренмәле азык-төлек пленкасына чорнады, аннан тыгызлап ике ягын бөрде. Рулетлар «сосиска» кыяфәтенә килде. Шуннан аларны кургаш кәгазьгә (фольгага) төрде.

– Кургаш кәгазь рулетларны яндырмый, ә азык-төлек пленкасы итне сусыл пешерә, – диде егет.

Ялтыравыклы рулетларны Руслан табага тезде. Аннан азрак су салып, табаны электр миченә куйды.

– Су ни өчен кирәк? – дим.

– Пар белән пешсен өчен кирәк.

Төп эш тәмам. Рулетларның пешкәнен көтеп, тәлинкәләргә бизәп чыгарасы гына калды. Русланны күзәтәм: кызык егет, үз яшенә хас һавалылык, тормышка «ал күзлектән» карау да сизелә, хыялыйлык та бар. Атлап түгел, йөгереп йөри. Җырлап та, көлеп тә ала.

– Өйдә ризыклар әзерлисеңме? – дим.

– Үзем генә яшәгәч, әллә нәрсәләр пешереп ятмыйм. Күбрәк эштә ашап кайтам. Ә менә әти-әниләргә баргач, әзерлим. Минем әти дә тәмле пешерә. Гадәттә, ир-атлар аш бүлмәсенә ашарга гына керә. Ни өчендер бездә ризыкны хатын-кызлар әзерләргә тиеш кебек кабул ителә. Бу дөрес түгел, дип саныйм. Иң шәп пешекчеләрнең ир-атлар икәнен барыбыз да белә. Эштән кайткач, ир белән хатын бергә кичке аш әзерләп ашаса, күңеллерәк бит! Минем гаиләмдә шулай булыр, дип ышанам!

«ЙОЛДЫЗЫБЫЗ!»

Рулетлар пешкән арада Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллиятенең укыту, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Светлана Александровна Цветкова белән сөйләшеп алдык. Руслан Соловьевны мактады ул. «Көллиятнең горурлыгы, безнең йолдызыбыз», – диде.

Бактың исә, уку белән эшне бергә алып бару өстенә, егет волонтер да икән. Икенче курста укыганда ук Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте студентларының волонтерлар отряды җитәкчесе булган.

– Руслан бик актив, аралашучан, – диде Светлана Александровна. – Үзе кичергәннәрнең яртысын да сөйләмәгәндер әле сезгә. Зарланмый, мескенләнергә яратмый торган егет ул. Бик ярдәмчел. Югыйсә сәламәтлеге белән бәйле проблемалары бар, тик ул сиздерми. Икенче төркем инвалидлыкны юкка гына бирмиләр.

– Көллияттә белем алучы 66 студентның да мөмкинлеге чикле, дидегез. Араларында Руслан кебекләр тагын бармы? – дим директор урынбасарына.

– Юктыр. Беренчедән, алар Руслан белән чагыштырганда, күпкә начаррак хәлдә. Икенчедән, авырлыкларга бирешмичә, башкалар алдында үзеңне күрсәтү бөтен кешегә дә бирелми. Махсус төркемдә укучы ул балаларга бик авыр. Белем алу гына димим, ә тормышта үз юлыңны табу турында сүз бара. Кулга диплом алгач та, аларны көтеп тормыйлар, бәласыннан башаяк дип, эшкә алырга теләүчеләр бик аз. Әйе, соңгы елларда мөмкинлеге чикле кешеләргә дәүләт йөз белән борыла башлады кебек,

тик җәмгыятьнең, шул ук эш бирүчеләрнең аңы әле үзгәрмәгән. Чит илдәге гариплләр белән чагыштырганда, безнекеләр бөтенләй икенче тормышта яши. Ни кызганыч...

Без Светлана Александровна белән сөйләшеп торган арада Руслан, «Татарстан» журналы алъяпкычын киеп, көллиятне әйләнеп килде. Бөтен кеше белән сөйләшеп ала, шаярткан була. (Аеруча кызлар белән «борчагы пешә» кебек тоелды).

– Руслан, укытучың синең турында: «Үзе кичергәннәрнең яртысын да сөйләмәгәндер әле», – диде. Тагын башка проблемаларың да бар идеме әллә? – дим.

– Бар иде. (Елмая. – Авт.) Тик алар артта калды инде. (Берничә секунд уйланып тора. – Авт.) Күзем гариплләнү өстенә гәүдәм дә матур түгел иде. Башлангычта укыганда йөз килодан артык идем. Ала каргалар янында кара карга булып йөрдем. Кечкенә вакыттагы авыруым аркасында, гормоннар эчеп тордым. Авырлыгым артты. Дарулар эчүдән туктагач,ябыга башладым. Дөрес туклану, спорт белән шөгыльләнү – барысы да булышты. 9 нчы классны тәмамлагач, яңача яши башларга үз-үземә сүз бирдем. Көллияткә килгәч, ачылып киттем. Үсмердә булган комплексларым юкка чыкты кебек. Йомылып яшәргә кирәкми, ачык, аралашучан булсаң, башкалар сиңа да шундый ук мөнәсәбәт күрсәтәчәк. Шуңа инандым.

Шулай диде дә Руслан елмаеп җибәрде. Һәм очып электр мичена таба китте.

– Пешкән! – диде.

МИНУС ДҮРТ?

Руслан кайнар мичтән рулетларны алды. Башта кургаш кәгазьне сүтте, аннан азык-төлек пленкасын алды. Тәлинкәдә нәкъ сосиска формасындагы рулетлар утырып калды.

– Пленканы алганда, итнең суы чыга, шуның өчен аны тәлинкәгә төшерергә кирәк. Табада эшләсәң, ул анда кала, ә болай соус кебек бирергә була, – диде Руслан.

Шуннан яшь пешекче рулетларны икегә кыеклап бүлеп чыкты. Кисәкләрне тәлинкә уртасына куеп, янына кыяр, помидор тезде. Өстенә сыр уып җибәрде.

– Кем ничек тели, нәрсә ярата, шуның белән бизи ала, – диде Руслан. – Ризык әзерләү ул фантизиягә бәйле, сәнгать әсәре тудырган кебек. Пешекче һөнәрен шуңа яратам да.

Русланның ялкынлы сөйләмен ишеткән кергән Светлана Александровна булде:

– Син нәрсә, Руслан! Кайнар ризыкны кем шулай бизи? Салкын ризыкны гына болай бирергә була!

Егет югалып калмады. Гадәттәгечә елмаеп:

– Беләм, Светлана Александровна... Гарнир әзерләмәдем бит. Өйдә исә аны кайнар бәрәңге белән эшлим, – диде.

Студент белән укытучы ярым шаярып тагын берничә җөмлә алышты әле. Шуннан:

– Ничәле куясыз? – дип, Руслан пешергән ризыгын безгә сузып.

Мин үзем шампиньон гөмбәсе дә, тавык ите дә яратам. Шуңа күрә бу ике ризыкның катнашмасы да тәмле тоелды. Тавыктан тагын бер җиңел, яңа ризык. Кеше килсә дә, йөзең кызармаячак. Ә Светлана Александровна исә:

– Рулет өчен – «5», ә бизәлеш өчен «–4», – диде.

Тик Руслан үпкәләмәде, киресенчә, көлеп җибәрде.

– Икенче юлы «5»лелек итеп бизәрмен, вәгъдә! – диде.

Яшь пешекче белән Мәскәүдә узган «Абилимпикс» конкурсы турында да сөйләшеп алдык. Светлана Александровна әйткәнчә, анда һәр детальгә игътибар иткәннәр. Руслан 80 катнашучы арасыннан дүртенче урынны яулаган. Өченче урынга чыккан егеттән аны бары 0,5 балл гына аерып торган.

– Мәскәүгә конкурска бару, анда катнашу, минем өчен бик зур тәҗрибә булды, – диде егет. – Яшермим, азрак дулкынландым, призлы урын яуларга шул гына комачаулады, дип уйлыйм. Анда барлык катнашучы да балык пешерде. Балыкны кисүдән башлап, табынга биргүгә кадәр күзәтеп, жюри баллар куеп барды. Дүртенче урынга калганымны белгәч, кәефем төште. Мин җиңәм дип килгән идем. Кызганыч, әлбәттә, тик алга таба яңа конкурсларда катнашасым килә. Хыяллар тормышка ашарга тиеш, Алла боерса!

...Миңа калса, Русланның тормышта иң зур җиңүе булган инде – үлем белән көрәшеп исән калган. Көллияткә килгәч, янә бер җиңүгә ирешкән – биредә аны барысы да белә, ярата. Ә яңа үрләр, зур уңышлар алда әле, монысына шикләнмим. ▪

1. Эретәбез!

2. Кыздырабыз!

3. Салабыз!

4. Җәябез!

5. Түгәрәклибез!

6. Төрәбез!

7. Бәйлибез!

8. Ныгытабыз!

9. Куябыз!

10. Салдырабыз!

11. Кисәбез!

12. Бизибез!

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН СӘЯХӘТ ИТЕГЕЗ

ӨЧЕНЧЕ ЗВОНОК ЮЛГА ЧАКЫРА

Зур шәһәр утлары еш кына күктәге чын йолдызларны күрергә комачаулый. Ә инде сәхнә күгендәгеләре турында әйтеп тә торасы юк. «Татарстан» театр дөньясындагы иң күзгә ташланырлык вакыйгаларны ачыклар, исемнәрне барлар һәм сезгә дә күрсәтер өчен, республика буйлап сәяхәткә кузгалды.

Михаил Булгаков повесте буенча куелган «Собачье сердце» спектакле.

ДАИМИ ҮСЕШТӘГЕ ТЕАТР БУЛАСЫБЫЗ КИЛӘ!

Яр Чаллының «Мастеровые» театры куйган «Карл и Анна» спектаклендә төп геройлар бер-берсе белән пышылдашып кына сөйләшә торган бер эпизод бар. Спектакльнең иң тәэсирле мизгелләре булгандыр ул, мөгаен: гүяки гашыйклар пышылдавы аша зал белән режиссёр үзе сөйләште ул мәлдә. Пышылдаудан соң ук – шартлау, фатумның котылгысыз китереп оруы. Һәм ачык финал – кем исән калды да, кем юк, монысын да әсәренеп калган тамашачы үзе генә белә.

Автор:
Ксения Сёмина

«Мастеровые»ның төп үзенчәлеге дә шунда: алар куйган тамашаларны кабул итәргә, яратырга, кире кагарга, хәтта ки күтәрә алмаска мөмкин, ләкин алар беркемне дә битараф калдырмый. Бу кагыйдә бөтен спектакльләрдә дә сизелә. Баш режиссёр Денис Хөснияровның эшләре булсынмы ул («Карл и Анна», «Кроличья нора», «Старший сын», «Ревизор»), Мәскәү белән Санкт-Петербургтан килеп эшләүче режиссёрларныкымы.

– Без һәр яңа эшебезнең моңа кадәр булган эшләргә охшамавын телибез, спектакльләрне әзерләгәндә шуңа омтылабыз. Әмма бездә катгый таләпләр дә бар: сәхнәдә тәмәке тарту, сүгенү һәм шәрә тәннәр булмаска тиеш. Минем фикеремчә, натурализм – ул сәнгать түгел, ә публицистика, репортаж. Ә чын сәнгать – ул тамашачыга билгеле бер тарихны аңлаешлы метафоралар теле белән сөйләп бирү, – ди театрның директоры Армандо Диамантэ. – Сирәк очракларда гына, режиссёр моны аклый һәм исбатлый алганда, мин әле нинди дә булса эпатаж адымнарны, ысулларны кабул итә алам. Ризалашам. Ә болай, театрда тулы ирек хөкем сөрә.

Шулай да «Мастеровые» спектакльләренең берсендә – «Собачье сердце»да – ялангач мизгел бар. Шариков, эттән кешегә әйләнгән моментында, киемсез-нисез залга арты белән берара басып тора. Ләкин тамашачыда зур дулкынлану уяткан мизгел спектакльдә бу түгел.

– «Собачье сердце»ны безнең сәхнәдә кую – бу минем хыялым иде. Әмма мин шул ук вакытта спектакльнең атаклы экрандагы вариан-

Фотолар «Мастеровые» Рус драма театрыннан алынды.

ты белән конкуренциядә була алмавын да бик яхшы аңлыйм. Мине, мөгаен, шул гына тотып торгандыр, – ди Армандо Диамантэ. – Моннан кала, безнең театрда профессор Преображенскийны уйнарлык актёр да юк иде. Һәм менә Питер режиссёры Семён Серзин шундый юл тапты: ул кайбер ир-ат персонажларны хатын-кызлар белән алыштырды. Шул исәптән профессорны да. Әмма ир-ат исемнәрен калдырды…

Шушы ук мантыйкка нигезләнеп, Шариковны да әверелешкә кадәр ана эт уйный. Чын эт турында сүз бара, әйе.

«Гаҗәеп! Искиткеч атмосфералы, кәттә һәм киеренкелекне соң чиккә җиткерә торган куелыш!» – дип язалар бу спектакль турында кемнәрдер. Ә икенче берәүләр башка «Мастеровые»га бармаска дигән ант эчеп кайтып китәләр. Әмма боларның берсе дә театр директорының ышанычын да какшатмый, артык үсендерми дә.

– Безнең максатлар белән кассаның максатлары тәңгәл килмәгән очраклар булгалый. Әмма без нафталинга гына риза булып утыра алмыйбыз лабаса. Безнең үсештәге театр буласыбыз килә, идеалда – даими үсештәге театр. Шуңа без театрда бер генә режиссёр булырга тиеш, дигән концепциядән баш тарттык. Театр үз эченә йомылган көненнән башлап үлә башлый ул. Ә безнең сәламәт көндәшлектә яшисебез килә, без куйган спектакльләрнең ил күләмендә вакыйгага әверелүен телибез. «Алтын битлек»нең лонгисемлегенә керүебез дөрес юлда икәнлегебезгә ишарә, – ди Армандо Диамантэ. – Әгәр дә Россия белән дөнья театр мохитендә ниләр булганын күзәтеп, чагыштырып карасак, ни дәрәҗәдә артта калганлыгыбызны күрә алабыз. Безгә әле үсәсе дә, үсәсе! Бик күп өлкәләрдә лидерлык позицияләрендә торган Татарстанда моның өчен мөмкинлекләр дә, ресурслар да җитәрлек. Без бу өлкәдә дә дөнья күләмендә тиешле урыныбызны ала алыр идек.

«Мастеровые» гаҗәпләндерергә ярата торган театр. Юатырга да ярата. «Конечная постановка» («Осенняя скука» дип аталган Николай Некрасов пьесасына нигезләнгән караңгы бер авылда рок белән кыргый биюләр мотивлары), «Кроличья нора» (Дэвид Линси буенча куелган һәм хатын-кызның 50 минутка сузылган тоташ кычкырудан гыйбарәт истериясен чагылдырган психологик драма) белән беррәттән, алар Мария Ладоның якты һәм күңелне нечкәртә торган «Простая история»сен дә, Алехандро Касонаның «Дикарь» пьесасын да күрсәтә. Планнарында – «Варшавская мелодия». Аны да куйсалар, мәхәббәт чыннан да барысын да җиңәчәк.



Леонгард Франк пьесасы буенча куелган «Карл и Анна» спектакле.



ӘКИЯТЛЕ УЕН

Бу театр башка бер генә театрга да охшамаган. Аңа эләгер өчен башта элеккеге мәктәпнең вестибюле аша узарга кирәк, аннары – баскычтан менәргә, аннан котсыз коридор буйлап барырга… һәм, ниһаять, Аладдин мәгарәсенә аяк баскан халәттә калырга. Асылда – тамаша залында. Гадәти генә декорацияләрдән соң, бу гаҗәеп көчле тәэсир ясый.

Әмма бу гаҗәеп камералы мәйданның уңайсыз ягы да бар: үзләренең аерым бер бинасы булмыйча, ә заллары бик кечкенә булу сәбәпле (130 кеше сыярлык), театр алмаш таләп итә торган гастрольләрдә катнаша алмый. Ягъни үзенә башка коллективларны чакыру мөмкинлегенә ия түгел. Шулай ук потенциалы булганча үзендә дә чыгышлар ясау шактый кыенга төшә – барлык балалар үзеген күрсәтер иде, югыйсә.

Ул арада Чаллы курчаклары Санкт-Петербург, Мордовия, Чечня һәм башка театрларның режиссерларын илһамландыра. Труппа кечкенә булса да (барлыгы 10 кеше), җәлеп ителгәнлеге буенча эре драматик театрлардан бер дә калышмый: сезонга 4-5 премьера, план буенча гастрольләр, «Театры малых городов» проекты кысаларында катнашу, «Рабочая лошадка» исемле курчак театры өлкәсендәге белгечләр өчен ел саен уздырыла торган үз фестивальләре… Актерларның күбесе театрда бик күптәннән эшли – 20 еллап. Башкала уку йортларында «курчак театры артисты» белгечлеге буенча белем алган яшьләрнең күпчелеге провинциягә кайтырга ашкынып тормый. Шулай да биредә һәркемнең әкияткә күмелү мөмкинлеге бар һәм бу әкиятне балаларга җиткерү чаралары да.

– Безнең репертуар, нигездә, – балалар репертуары, өлкәннәр өчен берничә генә спектакль бар. Барлык спектакльләр дә традицион әкиятләргә нигезләнгән. Алар беренче карашка гына гади булып тоела, чынлыкта, бик күп һәм тирән мәгънә ята һәрберсендә, – дип сөйли безгә театрның режиссеры Гөлназ Нуретдинова.

Театрның «хитлары»ннан берсе – «Золотой цыпленок» спектакле. Ул Владимирда узган «Золотое колечко» Курчак театрларының II төбәкара фестивалендә призга лаек дип табылды. Шулай ук Сыктывкарда узган «В гостях у Мойдыса» исемле Курчак театрларының III халыкара фестивалендә дә. Ә сентябрь аенда Бүре ролен уйнаучы артист Егор Митрофанов Курчак театрларының Актүбәдә узган V халыкара «Әссәламөгаләйкем» фестивалендә (Казахстан) «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә җиңүче дип табылды.

– Күпләр курчак театрын җитди кабул итми. Әмма биредә нәкъ башка театрлардагы кебек үк режиссер белән актерлар эше бара, зал белән бәйләнеш тә шундый ук. Ә минә бер үк вакытта курчак белән идарә дә итү, шул ук вакытта уйнау да (бигрәк тә курчак классик, таяктан, агачтан ясалган булса) – минә монысы бик тә авыр һәм четерекле эш, – ди Егор.

Аңа үзенең роле баштарак бик авыр бирелгән, әмма туганнан туган энесе тугач, ул аны ничек уйнарга икәнлегенә төшенгән. «Золотой цыпленок»тагы Бүре, әйтерсең, кинәт кенә

Фотолар Яр Чаллы курчак театрыннан алынды

айнып киткән. Беркатлы, самими чебине ашарга хыялланган усал Бүредән ул кинәт кенә аның сакчысына, әтисенә диярлек әверелә. Һәм менә бу гайрәтле, кече күңелле Бүренең үз итә, ярата башлыйсың. Гәрчә ул курчак кына булса да... Хәер, бу театрда курчакларга тере кешеләргә карагандай карыйлар.

– Минем хәзерге иң яраткан образым – «Су анасы»ндагы малай. Мин аны бик яхшы аңлыйм: кызыксынуын да, шуклыгын да, куркуын да. Безнең арада уртаклыклар бик күп, каядыр, йөрәгемнең иң-иң түрендә, мин дә нәкъ шундый кызыксынучан бер сабый булып кала бирәм. Без монда барыбыз да балачакта уйнап туймаучылар җыелган булсак кирәк, менә хәзер шул бушлыкны тутырабыз, – ди Гөлназ. – Әмма мондый гаять үзенчәлекле, башкалардан аерылып тора торган театрда бары тик зур ярату булса гына эшләп була – курчакларга карата һәм балаларга карата. Мин театрның тәрбияви роле булуына ышанам. Бүгенге заманны чагылдырыр өчен аның элементларын спектакльләргә кертүне дә хупламыйм. Мәсәлән, слэнг телен һәм смартфоннарны. Кемдер мине, бәлки, консерватор дияр. Бәлки, шулайдыр. Мин фольклор яклы. Балаларга гасырдан гасырга күчеп килгән традицияләрне сеңдерүне файдалырак дип күрәм. Бәйрәм һәм уен – болар балалар дөньясының бик әһәмиятле өлешләре, алар баланың шәхесен формалаштыруда зур роль уйный. Татарстанның милли бәйрәмнәре белән таныштырганда, балаларга, әйтик, Сабантуй, Карга боткасының каян килеп чыкканын төшендерү зарур.

Өлкәннәр өчен куелган тамашалар да кызыклы бирелә. Бу сезонның премьерасы «Горебогатырь Косометович» – Казан режиссеры Илгиз Зәйниев эше. Аның нигезендә императрица Екатерина II тарафыннан XVIII гасыр азагында язылган либретто ята. Аталар белән балалар конфликты, сарай интригалары, халык белән хакимият арасындагы мөнәсәбәтләр... Болар барысы да мәңгелек, искерми торган темалар.

– Курчаклар фантазияне чикләми, – ди Илгиз Зәйниев, ни өчен спектакль өчен бу мәйданны сайлавы турында сорау биргәч.

Сүз уңаеннан, театр һәрбер курчакны кадерләп саклый, хәтта инде ул уйный торган спектакльләр сәхнәдән төшкән булса да. Моннан ун еллар элек Татарстан һәм Россия осталары ясаган матур, серле, үзенчәлекле, кабатланмас курчаклар киштәләрдә яшәп ятуын дәвам итә. Бераз моңсулана, әлбәттә, яңадан тамашачы каршына чыгарга хыяллана. Алар монда шулкадәр күп – музей ачсаң да була! Урын гына табылсын, ә әкият каһарманнары Чаллыда җитәрлек!

Владимир Орлов пьесасы буенча куелган «Золотой цыпленок» спектакле.

Габдулла Тукай әсәре буенча куелган «Су анасы» спектакле.

Вуди Аллен пьесасы буенча куелган «Централ Парк Вест» спектакле эскизы. «Буа Талиясе» фестивале. 2018 ел.

БУА АВИНЬОНЫНА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Ике яшь кенә туташ Буаның «Яшьләр» паркы фонтаны тирәсендә бер-берсен куыша.

– Минем бер гаебем дә юк» Сэм сине әле мине очратканчы ук яратмый башлаган иде инде! – дип кычкыра берсе.

– Ялган! – дип сөрән сала аңа җавап итеп икенчесе. Кызлар фонтанны әйләнедереп алган бортикка менеп басалар да бер-берсенең чәченә ябышалар. Тигезлекләрен саклый алмыйча, фонтанга егылалар, аяусыз сугыш бозлы суда дәвам итә...

Вуди Алленның «Централ Парк Вест» пьесасы буенча Буа дәүләт драма театры труппасының яшь артистлары белән Питердан килгән режиссер Степан Пектеев куйган эскиз – «Буа Талиясе» театр лабораториясенең бер өлеше. Лаборатория – театр белгечләре Александр Вислов белән Нияз Игламовның, шулай ук Буа труппасы җитәкчесе һәм директоры Раил Садриевның уйлап чыгарган форматы, ул инде быел икенче мәртәбә уза. Эскизларның күбесе тулыканлы спектакль рәвешен алып, җирле сәхнәдә яшәвен дәвам итә соңыннан. Әйтергә кирәк, «Централ Парк Вест» – быел күрсәтелгән эскизлар арасыннан иң эпатажлысы түгел әле...

Үзенең эксцентрик характеры, китчка йөз тотуы, экспериментлар ясатуы белән аерылып торган Буа театры шулай да татар сәнгате традицияләренә тугры кала. «Комедиянең чикләрен өйрәнеп, аны без ияләшкән кысалар чигенә чыгару» – кычкырып әйтмәсәләр дә, театрның девизы шундый. Асылда, миссия диярг дә була моны. Әмма өстәнөстән генә алдырып, тамашачы мәхәббәтен җиңел юл белән яулау, шул рәвешле аны театрга кабат килергә мәҗбүр итү дип уйлап, ялгышырга ашыкмыйк. Татар фольклорында кешеләрнең һәм җәмгыятьнең тормышын кинаялап сурәтли торган юмор – Буа театрының әләме ул. Әлеге әләм астында театр коллективы яңадан-яңа сәхнәләрне яулый тора.

Буалылар нинди генә материалга алынмасын – Валерий Шергинның «Концлагерист» исемле абсурд антиутопиясеме ул (кечкенә генә тоталитар дәүләттән «иректе Әгерҗе»гә качарга хыялланучы Федот маҗараларына багышланган), Чехов буенча куелган «Человек в футляре»мы – барысын да җиренә җиткереп эшлиләр. Труппалары бүген 19 кешедән гыйбарәт, аларның барысы да профессиональ белемгә дә ия түгел. Әмма үзешчән актерлар да театр тәнкыйтьчеләренең хуплауларына лаек булып тора. Декорацияләр минимум – бу театрның үзенә күрә бер «фишка»сы. Авыр йөк төяп йөрисе булмагач, алар гел хәрәкәттә: пьесадан – пьесага, шәһәрдән – шәһәргә. Башка төбәкләрдә аларга ихтыяҗ бик зур, үзләренең туган сәхнәсендә буалылар, күп дигәндә, сезонның нибары ике аенда гына уйный.

– Көннәрдән бер көнне нинди дә булса бөек эш эшләргә теләп уянасың икән, бел: ул көн – нәкъ менә бүген, – ди Раил Садриев. Соңгы берничә ел эчендә аның җитәкчелегендә театр күп кенә уңышларга ирешә.

Фотолар Буа дәүләт драма театрыннан алынды.

– Мондый провинциядә уза торган театраль фестивальләр, иң беренче чиратта, публиканы – тамашачыны тәрбияли. Менә сездә, Буада да, шундый тәрбияви процесс бара. Тамашачылар акрынлап уен-көлке генә түгел, ә җитди психологик спектакльләр дә карарага күнегә, драманы тоемлый башлый. Ышанам, бер биш ел узсын әле, сездә иң нәзберек тамашачы тәрбияләнеп җитешәчәк. Ә аны инде җыен юк-бар белән кызыктырып булмаячак, – диде май аенда «Буа: диалог пространствосы» театр фестивалендә үзенең «Маленький принц» спектакле белән катнашкан Сергей Безруков. (Бу фестивальгә 23 театр коллективы җыелган иде – Мәскәүдән, Башкортостаннан, Чувашиядән, Мари Элдан, Удмуртиядән, Кабарда-Балкардан, Казахстаннан, Швейцариядән, Азәрбайҗаннан. – Авт.). – Фестивальгә киләчәктә егәр туплавын, киңрәк колач алуын телим! Буада бу ай чын театр ае булсын. Бөтен шәһәр театр белән сулап яши торган! Берничә ачык мәйдан эшләп торып, спектакльләр, Авиньондагы шикелле, урамда уйналсыннар!

Чираттагы (исәбе буенча инде өченче тапкыр уздырылган) Буа фестиваленә Иран, Греция, Төркия, Сербия кебек илләрдән дә театр коллективлары килде. Гастрольләр, репетицияләр, фестивальләргә чыгуларны да исәпкә алсак, режиссерга (өстәвенә, Раил Садриев менә дигән характерлы актер да бит әле) искиткеч зур йөк йөкләнә. Әмма ул ирешкәннәргә генә риза булып утыра торган кешеләрдән түгел.

– Россиядә бүген 100дән артык милли театр бар. Һәр төбәк фестивальләр уздыра, аларга һаман шул бер коллективлар килеп катнаша, нигездә, күрше субъектлардан. Ә менә масштаблы бер, барысын да берләштерә торган фестиваль юк иде моңа кадәр. Һәм без аны Буада оештырырга булдык. Милли театрлар фестивале дигән исем астында, – ди Раил Садриев. – Логистика ноктасыннан караганда, безнең шәһәр бик яхшы җирдә урнашкан. Концепцияне Россиянең Мәдәният министрлыгында да яңгыраттык.

Хәзерге вакытта труппа Сербиягә фестивальгә кузгалырга җыена. Ә аңа кадәр татарстанлыларның сезон ачылуны күрәселәре һәм «Абага: мишәр хикәяләре»н карыйсылары бар. Спектакль Ркаил Зәйдулланың берничә лирик, якты, моңсу новелласы мотивы буенча эшләнгән. Һәм Буа тетары үз тамашачысына ачкан юлның ни дәрәҗәдә кызыклы һәм кабатланмас булуына янә бер кат инанасылары да...

Ркаил Зәйдулла новеллалары буенча куелган «Абага. Мишәр хикәяләре» спектакле эскизы. «Буа Талиясе» фестивале. 2018 ел.

Николай Гоголь пьесасы буенча куелган «Женитьба» спектакле эскизы. «Буа Талиясе» фестивале. 2018 ел.

Мирсәй Әмирнең «Миңнекамал» пьесасы буенча спектакль.

КАЗАН АРТЫ АҺӘҢНӘРЕ

Кыргыз милли драма театрының залы туп-тулы. Пәрдә ябыла, әмма алкышлар туктамый. Баш игәннән соң артистлар да сәхнәдә кала, һәм тере аралашу башлана.

– Килүегез ничек яхшы! – диләр алар. – Туган телебезне ишетү ничек рәхәт! Мин бит чыгышым буенча шулай ук Әтнәдән.

Күзләрендә яшь ялтырый.

Шулай итеп, бу көздә Бишкек шәһәрендә Габдулла Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театрының гастрольләре булып узды. Алар кыргыз тамашачасына Чыңгыз Айтматов әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр алып барып бүләк итте – «Гүзәлем Әсәл» белән «Кызыл яулыклы тупылым»ны.

Бу елда Әтнә театрының оешуына 100 ел тула. Казан артындагы иң күренекле театрларның берсе үзенең тамырлары, килеп чыгышы белән горурлана ала – ул тамырлар «Сәйяр» труппасына барып тоташа чөнки. Барысы да 1918 елда башлана: берләшмәнең бер әгъзасы – Әтнә белән Алат бистәләренең мәгариф инспекторы Мөхәммәт Парсин бирекдә мөстәкыйль драма түгәрәге оештырып җибәрә.

«Әтнә халкы театрга бик тә һәвәс! Нигә шулай икәнен бер Алла үзе генә беләдер, әмма дөресе шул: халык сәнгате бирекдә яши һәм яшәячәк. Опера, балет бу җирләргә килеп җитмәсә дә, татар театры туганнан соң ук, беренчеләрдән булып, Әтнәгә аяк атлый… 1906 елның декабрендә татар театры үзе хакында дөньяга сөрән сала: Казанда беренче ачык спектакль куела. Ә шуннан соң 12 ел узгач (тарих өчен болар мизгел генә, билгеле!), театр инде Әтнә төбәгенең ишекләрен шакый. Шакып кына калмый, бәреп кереп, үз кагыйдәләрен игълан итә», – дип яза туган театры хакында аның элеккеге җитәкчесе Гомәр Мәрданов.

Илнең яшьтәше булган әлеге үзешчән театр тарихтагы барлык тынгысызлыкларны кичерә. 1966 елда ул «Халык театры» дигән исемгә лаек дип табыла. Шундый булып кала да ул? Аның сәхнәсендә шушы еллар эчендә әллә никадәр һөнәр ияләре үйный, бу кешеләрнең барысын да, шикләнмичә, Әтнә җиренең ватанпәрвәрләре диярге була.

Әтнәлеләр өчен Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган «Мулла» спектакле бик әһәмиятле булды. Театрның баш режиссеры Рамил Фазлыев аны җирле сәхнәдә 2009 елда куйды. Спектакльне Туфан Миңнуллин үзе дә күреп калды. Ул аңа башка куелышлардан күбрәк ошаган иде.

Фотолар Габдулла Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театрыннан алынды

Тиздән театр, әлеге спектакль белән гастрольләргә чыгып, башка төбәкләрне урап кайтып, «Дәүләт театры» статусына да ия булып өлгерде. 10 елдан соң, Рамил Фазлыев, ниһаять, «Мулла»ны фильм итеп төшерде. Анда төп рольне дә үзе башкарды. Хәзерге көндә труппаның бер өлеше Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре буенча эшләнеп яткан фильмында катнаша.

– Әтнә артистлары уйнаган фильмнар аларда катнашкан шәхесләрнең исемнәре ярдәмендә таныла дисәк, дөресрәк булыр, – ди театрның директоры Ленар Зәйнуллин, фильмнарда катнашу театрга күбрәк тамашачыны җәлеп итәргә булышамы дигән сорауга җавап итеп.

Заманча спектакльләрдән тыш (сезонны Шәриф Хөсәенов буенча әзерләнгән «Әниемнең ак күлмәге» спектакле ачты), театр соңгы елларда үзләрендә куелган 60-70 нче еллардагы тамашаларны торгызу белән дә шөгыльләнә. Бу Сәет Шәкуровның «Туган туфрак» дигән хәрби драмасы да, сугышка китеп югалган ирләрнең йөген, вазыйфаларын үз җилкәләренә алып, тормышны тарткан атаклы «Миңнекамал» да. Әсәрне Мирсәй Әмир 1944 елда язган иде.

– Бу елда без «Бердәм Россия» уздырган «Кече шәһәр театрлары» проектында катнашабыз. Ул 300 меңнән азрак кеше яши торган җирлектәге театрларга ярдәм итү йөзеннән оештырылган проект, – дип сөйли Ленар Зәйнуллин. – Ике спектакль куярга ниялибез. Гастрольләргә әзерләнәбез.

Беренче спектакль – Морис Метерлинк әсәре буенча куелачак «Синяя птица». Ул олылар өчен дә, балалар өчен дә чын мәгънәсендә феериягә әвереләчәк тамаша булыр дип көтелә. Татар теленә пьесаны Татарстанның атказанган артисты Марат Хәбибуллин тәрҗемә иткән. Тамашада республикабызда исемнәре билгеле булган «Дорога из города» коллективы хореографлары катнашачак.

Икенче спектакль – «Безнең шәһәрнең серләре». Монысы инде – классика, Галиәсгар Камалның иң билгеле комедияләреннән берсе. XX гасыр башы буржуазиясенең интригалары, саранлыгы, азгынлыгы турында бәян итүче бу әсәр һаман да актуаль.

Ике премьера да – шушы көздә. Билетлар алырга ашыгырга вакыт!

«Мулла» фильмын төшерү вакытында.
Фото: Ната Смирнова

Сәет Шәкуровның «Туган туфрак» пьесасы буенча куелган спектакль.
Фото: Рамил Гали, «Татар-информ» МА

Рәдиф Сәгъдинең «Серле төн» пьесасы буенча куелган спектакль.

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
«Санта-Барбара» бер
якта торсын,
Сайтагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА
ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанның **КАЙСЫ** шәһәрендә Советлар Союзының барлык романтиклары җыелган

Комсомол туйлар **НИЧЕК** узган

Мәрҗани татар тормышын **НИЧЕК** үзгәрткән

КЕМ ул Идегәй

Пелевин **НИ** белән шаккатырды

Бер машиналык акчаны **НИЧЕК** эшләргә

БӘХЕТЛЕЛӘР ЯЗМЫШЫ

РЕАЛЬ КӨЧ

Фото: Александр Ефремов

Үзенең яшьлеге – комсомол еллары турындагы хатирәләре белән Борис Леушин уртаклаша. 80 нче еллар башында ул ВЛКСМның Татар өлкә комитетын җитәкли. Аның кебекләр өчен «комсомол – ул безнең яшьлегебез» дигән сүзләр гади җыр юллары гына түгел.

ПАРТИЯ: «КИРӘК!» ДИДЕ

ВЛКСМның Әлмәт шәһәр комитетында беренче секретарь булып эшләгән чагым иде. «Әйдә, яшьләрне күтәр!» – КПСС ның Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре Валентин Борисовтан мин шундый күрсәтмә алдым. Шәһәргә боз сарае төзергә булышырга кирәк. 80 нче еллар башы, урамда – кыш. Төзүчеләр чокыр казый башлаганнар, сазлыклы урын булганга күрә, су чыккан. Ә төнлә ул су катып килгән. Бетте! Алга таба авыр техникага эшләргә ярамый. «Ә урманны сал итеп агызу өчен комсомоллар елга өстендәге бозны ничек ватканнар», – дип мисал китерде Борисов, Комсомольск-на Амуре төзелешен үрнәккә куеп. Архивымдагы фото шул рәвешле барлыкка килде. Анда иптәшем белән мин яланөс диярлек зур чүкеч тотып торабыз, ә бездән пар күтәрелә. Гыйнвар аенда!

Ләкин моңа кадәр без, шәһәрдәге беренчел комсомол оешмаларының секретарьларын җыеп, хәлләрне аңлаттык. Каршы чыгучы булмады. График буенча эшләдек. Бозны лом белән ватабыз, аннан соң эшкә төзүчеләр кушыла. Алар нигез чокырын казыйлар, тагын су чыга, ката, ә без бозны ватабыз. Әкренләп геологлар билгеләгән күрсәткечкә кадәр җиттек. Нигез чокырына бетон түшәлде, боз сарае салынды. Бу комсомоллар берләшеп үз шәһәрләренә булышуның бик күркәм бер үрнәге булды.

ӨНДӘҮ ГЕНӘ САЛ!

Комсомолның Татар өлкә комитетына беренче секретарь итеп сайланырга өч ай кала, миңа «Алтын алка» зона турнирын ачарга туры килде. Анда ВЛКСМ Үзәк комитеты вәкилләре дә бар иде. «Татария комсомолы – көчле оешма. Без һәрвакыт алда, ә сез зона ярышларын үткәрүне генә ышанып тапшырасыз. «Алтын алка»ның Бөтенсоюз уеннарын уздыруны да безгә бирә аласыз!» – дим. «Булдыра алырсызмы соң?» «Булдырырбыз!» – дип җавап бирдем. Секретарь булуга, әлеге сөйләшүне искә төшерделәр: «Әзер булуыгызны раслыйсызмы?» Кая барасың, расламыйча?! Уйлый башладым: әгәр без Әлмәттә менә дигән боз сарае салганбыз икән, нигә уеннарны Казанда үткәрергә? Ул вакытта шәһәр башкарма комитеты рәисе булып эшләгән Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшинга шалтыратам. Ул – безнең кеше, элеккеге комсомол активисты! «Әлбәттә, кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез, Борис!» – дип җавап бирде ул.

Тик барысы да шома гына бармады. Менә беренче авырлык та үзен сиздерде: сарай салынган салынуын, ә боз җәю машинасы юк. Мондый машиналарны Свердловск чыгара – елына дүрт кенә данә! Кемгә биреләсе өч елга алдан язылып куелган. Әмма без чигенергә иялләшмәгән! Әлмәт шәһәре комсомолының беренче секретаре Мансур Хафизовны командировкага җибәрәбез: «Митинглар җый, шимбә, якшәмбе өмәләре оештыр, тик машинасыз гына кайтма!» Үзем исә комсомолның Свердловск өлкә комитетының беренче секретаре Царегородцев-

ка шалтыратам: «Алеша, ярдәм ит, дускаем! Сездә – завод, бездә Боз сарае белән «Алтын алка» финалы. Белгечләрне күтәр!» Нәрсә дисез? Эшләделәр бит! Шундый эш хакына төрле шәһәр комсомоллары берләште. Ул вакытта Советлар Союзы иде, мин һәрвакытта да төрле шәһәр комсомол комитетларына – Минскига, Краснодарга, Мәскәүгә һәм башкаларга мөрәҗәгать итә алуыма һәм анда мине һичшиксез тыңлаячакларына, ярдәм кулы сузарга тырышачакларына ышана идем.

«Алтын алка» турниры шәһәр өчен чын бәйрәмгә әверелде. Бөтен илдән командалар җыелды. Турнирның мактаулы кунагы совет хоккее аксакалы Анатолий Тарасов булды, ул безгә ярышларны оештыруда зур ярдәм күрсәтте. Аның белән бергә легендар хоккейчылар – Рагулин, Волчков килгән иде. Әлмәт «Нефтьче»се өчен мастер-класслар күрсәттеләр... Ул чакта безнең малайлар чын егетләрчә көрәште – призлы урын яулады. Менә шул рәвешле бары тик бер инициатива гына да таулар күчерергә сәләтле. Күркәм эшләргә өндәү генә сал!

ФОРМАЛИЗМГА КАРШЫ – ЧЫН ЭШЛӘР

Идеаллаштырырга теләмим: комсомолда каршылыклар бар иде. Шуларның иң зурысы – формализм. Идеалистик лозунглар, Ленин зачетлары, комсомол сәяси сораштырулары кебекләр... Бу эшләрне яратмый идем. Ничек котыла идемме? Технологиясе бик гади: әлеге сорауларны артык контрольгә алмыйм, әйтеп китәм, ә алга таба – ни булса, шул була. Комсомолда миңа бөтенләй башка нәрсәләр: реаль эшләр – төзелеш отрядлары, шефлык десантлары – ошый иде. Әйе, безгә тырышырга, урау юлларны эзләргә туры килде, әмма эшнең шундый тере формаларын тапкач, үзебезне бик бәхетле сизә идек!

Миңа җай килеп торды. Казан университетының икенче курсында мине студентлар бюросы секретареның уку-тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп сайладылар. Ләкин безгә андый исем ошамады, мин бөтен кеше өчен – факультетның студент деканы идем. Бездә ул вакытта ук үзидарә иде инде! Кемгә тулай торактан урынның, стипендиягә тартып бетермәсә дә, акчаның бик кирәкләгеген бездән – укучылардан да яхшырак кем белә ала соң! Без кешенең хәленә керә идек, ә менә ялган белешмәләр, шикаятьләргә исебез китмәде. Тарих-филология факультеты деканы Сөләйман Иксанович Даишев безнең бер генә тәкъдимебезне дә кире какмады.

Бервакыт шулай КДУның ВЛКСМ комитеты секретаре Володя Егоров (соңрак – ВЛКСМ ҮКның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире) мине үзенә чакыртты. Ул заманда КАМАЗ ның гөрләгән чагы, ә университет ничектер бу эштән читтәрәк калган кебек тоелды. «Борис, уйлап кара әле, без ничек ярдәм итә алабыз. Мөмкинлекләр бар!» – диде. Шулай итеп мин КАМАЗда университетның шефлык десанты командирына әйләндем. Кайсы юнәлешкә кушылырга кирәклеге турында төзелеш штабына шалтыратып белештем, һәм тиз арада без консультация пунктын эшләтеп җибәрдек, чөнки төзелешкә дип йөзәрләгән кеше килә иде. Әлеге пунктта иҗтимагый профессияләр факультетының яшь мөгаллимнәре һәм аспирантлары Казан университетына керү шартлары турында сөйләделәр. Ләкин моннан тыш безгә әтиәниләре көне-төне эштә булган балаларның буш вакытын оештырырга кирәк булды. Балалар өчен «Зарница» хәрби-спорт уеннарын оештырырга карар кылдык. Ләкин таяклар белән япан кырда йөгерү кызык түгел, шуңа без КАМАЗ районында ун хәрби радиостанция эшләргә тиеш дигән кызыклы фикергә килдек. Рөхсәтне КГБдан алырга кирәк иде. Мин шунда киттем. Һәм, беләсезме, проблема тумады. Үз идеяңне дөрес итеп аңлаткач, аның кешеләргә, бигрәк тә балаларга кирәклегенә төшендергәч, каршы килүче булмый икән. Нәтиҗәдә балаларның разведгруппалары хәбәрләрен радио буенча тапшырдылар. Бу балалар өчен шундый зур шатлык булды. Мин үзем дә рәхәтләнеп алар белән йөгереп йөрдем. Штабта гына утырып торып булмый бит инде. Шул рәвешле без ихтыяри хәрәкәт традицияләрен дәвам иттек һәм ныгыттык! Бүген аны никтер безнең өчен ят булган «волонтерлык» сүзе белән атыйлар.

ТУГАН ИЛ ГЕНӘ ЯШӘСЕН...

Бер очрашу аеруча истә калды. Ул ВЛКСМның Татар өлкә комитетының элеккеге беренче секретаре, ә мин – булачак беренче секретарь. Рәис Кыямович Беляев – легендар шәхес. Аны бөтен ил белә иде. Казан университеты ректоры Михаил Тихонович Нужин мине үзенә чакыртып алганда дүртенче курста укый идем. «Борис, бу статуэтканы һәм безнең университетны тәмамлаган мактаулы белгеч дипломын сиңа ышанып бирәм. Син аларны Беляевка тапшыр», – диде ул. Шундый зур эш белән мин Чаллы партия комитетына, беренче секретарь янына юл тоттым. Анда миңа: «Кичке унберләрдә килегез», – диделәр. Килдем. Штабта эш гөрли. Кабул итү бүлмәсе тулы халык. Беляев янына керергә чиратта министр урынбасарлары утыра. Шулай да ул мине кабул итте. Тиешле унбиш минут урынына аның янында кырык минут утырдым. Үзебезнең эшләр турында сөйләдем, ул кызыксынып тыңлады, үзенең комсомол вакытларын искә төшерде. Безнең дуслык нәкъ шушы очрашудан башланып китте. Күп кенә сорауларны алга таба мин аның аркылы хәл иттем. Бервакыт минем янга Казанның 1нче музыка мәктәбе укучылары һәм ата-аналары килде. Мәктәпне тарихи бинадан чыгаралар икән. Рәис Кыямовичка шалтыратырга туры килде, булышты – эшне туктаттылар. Комсомол – реаль көч иде. Безнең өлкән иптәшләребез рәсми юллар белән барырга мәҗбүр булганда, алар, формализмга юлыгып, таптанып торганда, без проблемаларны үзебезчә чишәргә тырыштык. Әле дә хәтерлим, бервакыт миңа ВЛКСМның Киев өлкә комитеты беренче секретаре шалтыратты: «Борис, нигәдер безнең өлкән иптәшләребез үзара килешә алмыйлар. Булыш, зинһар, өч вагон полиэтилен кирәк иде», – ди. «Оргсинтез» директоры Владимир Лушниковка шалтыраттым. «Яхшы! – диде ул. – Комсомолга өч вагон төяргә кушам». Мәсьәләне хәл иттек. Чөнки болар барысы да эш өчен, ил өчен кирәк иде! Т

Әзерләде:
Катерина Котова

КАМАДАГЫ БАТЫРЛЫК

Гигант автозавод рекордлы кыска вакытта сафка бастырыла. Янәшәсендә шулай ук яшен тизлегендә шәһәр калкып чыга. Мондый удар төзелешкә Советлар Союзында гына түгел, бөтен дөньяда да тиңнәр табылмый.

Әзерләде:
Ольга Туманская

ГАСЫР ТӨЗЕЛЕШЕ

Менә бу фотосурәт бик күп нәрсә турында сөйли ала. Буяуга батып беткән роба кигән кызлар ышанычлы адым белән каядыр үз эшләре буенча бара. Сменалары башланамы, әллә төшке ашка ашыгалармы? Безгә, ике меңенче еллар күзәтчеләренә, фаразларга гына кала. Һәм аларның курткаларындагы «Вологда», «Брянск», «Киров» дигән язуларны укып гаҗәпләнергә... 1970 нче еллар... Ул чакта бик кечкенә шәһәр булган Яр Чаллы бөтен Советлар Союзыннан комсомол романтикларын җыя. Бүген безгә бу турыда Романтиклар һәм Энтузиастлар бульварлары, Яшьлек тыкрыгы һәм Яшьләр бульвары гына нидер сөйләргә омтыла...

Яр Чаллы Тарих-туган якны өйрәнү музеенда комсомолның 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды. Тәүге илһамландыргыч экспонатлар – комсомол юлламалары, алар буенча яшьләр үзләре теләп Бөтенсоюз удар төзелешенә агылган. Менә, мәсәлән, мондые: «Иптәш Цай Сун-Ок Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте чакыруы буенча мөһим төзелешләрдә тырышып эшләргә теләвен җиткерде... һәм комсомол оешмасыннан Кама автозаводы төзелешенә җибәрелә».

Цай Сун-Ок кебекләр тулы бер «армия» була. Яшьләр КАМАЗга грандиоз проектта катнашу, тарихка керү, автогигант төзү хыялын тормышка ашыру өчен җыйнала. Фәймә Гыйниятуллина төзелешкә 1976 елда, заводның беренче чираты сафка бастырылыр алдыннан килә. Чит телләр укытучысы, Балык Бистәсе район комсомол комитетының беренче секретарен тынгысызлыгы «харап итә». Ымсындыргыч яңа «КАМАЗ» сүзе үз эшен эшли. Яңа урында иң беренче алган тәэсирләренең транспарантлардан булуын бүгенгедәй хәтерли әле ул. «Не всем дано так щедро жить – на память людям города дарить» яки «Трудность забудется, чудо свершится, сбудется все, что сегодня лишь снится» кебек гыйбарәләр нәкъ менә КАМАЗ рухын чагылдыра да инде. 1975-1976 нче елларга туры килгән иң киеренке чорда бер төзелеш мәйданчыгында 95 меңгә якын кеше эшли!

– Төзүчеләрнең мондый тупланышы буенча дөньядагы башка бер генә төзелеш тә тиңләшә алмый, – ди энциклопедияче, Яр Чаллы Тарих-туган якны өйрәнү музееның өлкән гыйльми хезмәткәре Билал Канеев. – Хәтта



Товарищ Цай
Сун-Ок
(фамилия, имя, отчество)
По Призыву Коммунистической Партии и Советского Правительства добровольно изъявил желание самоотверженно трудиться на важнейших стройках народного хозяйства Узбекской ССР и направлен комсомольской организацией
Ташкент
(города,
района, края, республики)
на строительство Камского (название
автозавода
предприятия)
Секретарь горкома (райкома)
комсомола
М. П.

Цай Сун-Ок кебекләр тулы бер «армия» була. Яшьләр КАМАЗга грандиоз проектта катнашу, тарихка керү, автогигант төзү хыялын тормышка ашыру өчен җыйнала.

Фотолар Яр Чаллы шәһәре Тарих-туган якны өйрәнү музее архивыннан;



Эшчеләр, инженерлар, укытучылар, табиблар үз эшләре буенча каядыр ашыга... Һөнәрләре төрле булуга карамастан, барысының да аяк киеме генә бертөрле резин итек. Бөтен җирдә – тездән балчык. Тик шулай да Маяковскийның сүзләре киләчәктән хәбәр кебек яңгырый. Биредә шәһәр-бакча булачак.

БАМ төзелеше дә территориясе буенча да, вакыты буенча да сузылганрак була. Автогигантның проект куәте дә таң калдыра – елына 150 мең автомобиль һәм 195 мең көч агрегаты белән двигатель җитештерелә!

...Гигант төзелешкә 1969 елның 13 гыйнварында нигез салына башлый – нәкъ шул көнне экскаваторчы Михаил Носков завод салынасы мәйданчыкта беренче чүмеч җирне чокып ала. Шуннан соңгы унбер елда КАМАЗның файдалануга тапшырылган төп фондлары бәясе ЗИЛ, ГАЗ, ВАЗның өчесенең бергә кушып исәпләнгән фондлары бәясе белән тигезләшә һәм 3,9 миллиард сумны тәшкил итә. Дәүләт комиссиясе заводның ике чиратын да «бик яхшы» билгесенә кабул итә.

«БЕЗ ШӘҺӘР-БАКЧА ТӨЗЕРБЕЗ»

Өр-яңа йорт диварына зур хәрефләр белән язылган әлеге сүзләр күлләвекләрдә чагыла. Эшчеләр, инженерлар, укытучылар, табиблар үз эшләре буенча каядыр ашыга... Һөнәрләре төрле булуга карамастан, барысының да аяк киеме генә бертөрле – резин итек. Бөтен җирдә – тездән балчык. Тик шулай да Маяковскийның сүзләре киләчәктән хәбәр кебек яңгырый. Биредә шәһәр-бакча булачак. Әмма дүрт елдан түгел – Яр Чаллыны төзү темплары шаккатыра. «Иртән өйдән бер юл белән китәсең, кич инде аны урап үтәргә туры килә – ул урында яңа объект төзелгән яки котлован казылган була», – дип искә ала берничә ел буе Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабын җитәкләгән Рим Халитов.

Төзелеш башланганчы да Чаллы, кечкенә саналса да, инде үзенең тарихы, традицияләре булган шәһәр санала. Тик шулай да КАМАЗ аңа икенче тапкыр туу мөмкинлеге белән яңа тарих бүләк итә.

– Яр Чаллы ялан кыр уртасында төзелә башлады дигәнне ишетсәм, минем ачуым чыга, – ди шәһәрнең мактаулы гражданины, күп еллар буе «Энергетик» Мәдәният йортын җитәкләгән Гөлзада Рзаева.

– Шәһәр бар иде инде, һәм аның үзенең тарихы да бар иде. Партия шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Кыям улы Беляев бирегә килүче һәркемгә бу җирне һичшиксез яратуны максат итеп куйды. Нәкъ менә яратуны, ә инде «Без КАМАЗ төзергә килдек, ә сез кем соң әле» дигән әйбер бөтенләй булмаска тиеш иде.

Яр Чаллы музее күргәзмәсендәге экспонатлардан берсе – гадәти һәм бүген күнегелгән җиһаз – бетон өчен төзелеш вибраторы. КАМАЗ өчен ул нинди әһәмияткә ия соң?

– Чаллыда беренче нигез чокырын казыгач, җирле туфракның бик төрле булуын, кайбер урыннарда сулы комнар да очравын аңлыйлар, – дип сөйли музей секторы мөдире Светлана Бабич. – Шунлыктан нәкъ менә биредәге төзелештә беренче булып субайларны бораулау ысулын куллана башлыйлар – котлован урынына скважина бораулыйлар, булачак бинаның нигез формасын ясыйлар, аны бетон белән тутыралар, аннары инде бинаның үзен төзиләр. Ә мондый төзелеш вибраторларын эшчеләр бетонны тыгызлау өчен файдалана. Ысул үзен аклый – ул тиз, уңайлы һәм арзан булып чыга.

«Мондый колачлы төзелешнең һәм мондый кыска вакыт эчендә шәһәр төзүнең дөньяда булганы юк иде әле», – бу сүзләрне күренекле совет архитекторы Борис Рафаилович Рубаненко әйткән. Төзелеш проектын һәм шәһәрнең Генпланын нәкъ менә ул эшләгән. Төзелеш темпларын халык саны арту темпларына яраштырып үзгәртергә туры килгән. Халык саны исә геометрик прогрессия



Күпләргә яхшы таныш «малосемейка» термины да биредә барлыкка килгән. Тулы бер гаилә яшәгән бүлмәне шулай атаганнар. Еш кына бер фатирда өч гаилә күрше булып яшәгән.

буенча арткан: 30 дан 500 мең кешегә кадәр! Кайбер көннәрдә КАМАЗга 500 ләп хезмәткәр килгән.

Вакытлыча торак төзү идеясеннән шунда ук баш тартканнар, чөнки беразга дип кенә төзеп куелганның даимигә әйләнү ихтималы бик зур. Яңа килүчеләрне еш кына вагонга, якын-тирәдәге авылларга, тулай торакка урнаштырганнар. Әмма ул елларда нәкъ менә Чаллыда торак алу бик җиңел булган. Яшерен-батырын түгел, бик күпләр төзелешкә нәкъ менә шуның өчен килгән дә. Сүз уңаенда, күпләргә таныш «малосемейка» термины да биредә барлыкка килгән. Тулы бер гаилә яшәгән бүлмәне шулай атаганнар. Еш кына бер фатирда өч гаилә күрше булып яшәгән. Аларның күбесе КАМАЗ төзелеше вакытында гомуми кухняларда башланган дуслыкка хәзергә кадәр тугры.

КОМСОМОЛ, АЛГА!

Ул чакта дәүләт бүләген алганда, кеше гадәттә совет хакимиятенә рәхмәт укыган, Ватан бәхете өчен киләчәктә дә тырышып эшләргә вәгъдә биргән. Әмма әлеге кагыйдәдән чыгармалар да булган. 1976 елда КАМАЗда бер бригадир Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән. Аның сәхнәдә әйткән гади сүзләре күпләрнең күңелен йомшарткан. «Бу орден минеке генә түгел, ул минем хатынымныкы да, балаларымныкы да. Чөнки алар мине көне-төне сагынып көтеп торды...» – дигән ул.

Үзе дә орденлы Виктор Ластовка ул очракны хәтерли әле. Виктор КАМАЗ төзелешенә инде тәҗрибәле төзүче-инженер булып килә, аннары исә «Камгэсэнергострой» җитәкчесенең беренче урынбасарына кадәр үсә.

– Яр Чаллыга килеп төшүгә үк, мин анда чын удар комсомол төзелеше булуын тойдым! – дип искә алган Ластовка. – Комсомолның өлгермәгән җире юк иде. Дөресен әйткәндә, еш кына моннан файдаландылар да: берәр җирдә эш тукталса – комсомол, әйдә, алга! Һәм комсомоллар сынатмый иде, зарланмыйча, көчәнмичә генә тиз арада хәлне төзәтә.

КПССның Яр Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Кыям улы Беляев эшне шундый итеп көйли ки, беркем дә комсомол оешмалары фикеренә, аларның башлангычларына һәм претензияләренә кул селти алмый. Бу турыда шәһәр партия оешмасында аннан соң беренче секретарь булган, карьерасын исә КАМАЗ төзелешендә гади мастердан башлаган Уел Хөсәенов искә ала.

– Таләпчәнлек тә югары булды. Берәр җирдә өзеклек килеп чыкса, Беляев гел: «Ә комсомол кая караган?» – дип сорый иде. Һәм беркем дә, беркайчан да: «Бу безнең эш түгел», – димәде. Чын комсомол хезмәткәре нормаль эш көненең нинди булуын да белми иде, ә безнең төзелештә бигрәк тә көнне төнгә ялгап эшләү гадәти хәлгә әйләнде.

Ул вакытта теләсә кем Беляев янына кереп, бетон китерүне тоткарладылар, соңга калдыралар, дип зарлана алган, дип сөйлиләр. Төзелеш җитәкчеләре үзләре дә кабинетларында гына утырмаган. Итек кияләр дә – объектка. Теләсә нинди тәнкыйтьне тыныч кабул ителәр. Комсомоллар шундый алар: эш бармый икән – шунда ук «Яшен»! Сүз уңаенда, «Яшеннәр» адым саен булган.

– Бөтен җирдә диярлек «Не пищать!» дигән плакатлар эленеп торды, – дип искә ала Гөлзада Рзаева. – Кем зарлана, кем елый – юлына ак җәймә. Күп нәрсә энтузиазмга һәм яшьлек дәртенә корылган иде.

Бу өзлексез ярышлар заманы була. Бөтенесенең комсомол-яшьләр бригадасы исемен йөртәсе килә – мактаулы бит! Үзләренең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә кешеләр дан казана. Алдынгыларны бөтенсоюз телевидениесе күрсәтә, алар турында радиодан сөйлиләр, газеталарга язалар. Һәркемгә мәгълүм журналлар исә КАМАЗ төзүчеләр өчен махсус бүләкләр булдыра. Әйтик, ВЛКСМ Үзәк Комитеты журналы «Молодой коммунист» абруйлы «Красная гвоздика» кубогы призы белән бүләкли. «Огонек» журналы исә ел нәтиҗәләре буенча иң яхшы бригадаларга кубок бирә. Аны алу өчен җитди көрәш бара, чөнки җиңүчеләр хезмәт каһарманнары булып кына калмый, журналдагы репортажлар геройларына да әйләнә. Анда басылганнан соң алар турында бөтен ил белә. Әле алай гына да түгел. Кубок иияләрен Мәскәүгә чакырып, алар өчен махсус әзерләнгән бик кызыклы мәдәни программа күрсәтәләр.

«Огонек» бүләген беренче булып Александр Зотов бригадасы егетләре ала. Алар шәһәрдә мәктәпләр төзи. Үз объектының һәр почмагына Зотов 5 тиенлек акча куеп калдырган, дип сөйлиләр. Янәсе, укучылар да аның кебек алдынгы булсын һәм гел бишлегә генә укысын. Сүз уңаенда, менә ул – әлеге заманның тагын бер истәлекле фотосурәте: беренче сентябрь линейкасында А дан Н га кадәр параллель сыйныфлар тезелеп баскан! Әти-әниләре сменалап эшләгән кебек, мәктәптә дә өч сменада укыганнар.

Инде 1973 елда ук Яр Чаллыдагы Бөтенсоюз удар комсомол төзелешендә катнашучы 8 мең комсомолга «Коммунистик хезмәт ударнигы» дигән исем бирелә. Биредә әле тагын бер мактаулы исем булдырыла – КАМАЗ төзелеше ударнигы. Билал Канеев әйтүенчә, хәтта бөтен Советлар Союзы масштабында да шундый әһәмияткә ия башка билге булмый: камазлылар аны Геройларга бирелә торган «Алтын Йолдыз» кебек кабул итә. Алар өчен ул иң югары бүләк була. Абруйдан кала, бу исем өстенлекләр дә бирә: аның белән бүләкләнүче торак алганда

Яр Чаллының Тарих -туган якны өйрәнү музеенда комсомолның 100 еллыгына багышланган күргәзмә эшли.
Биредәге йөзләгән экспонат Камадагы батырлыкның ничек башкарылуы турында сөйли.

өстенлеккә ия була, чираттагы ялын үзе өчен уңайлы вакытта ала, транспортта бушлай йөри, һәм аңа шифаханәгә ташламалы юллама эләгә. Бу исемгә Чаллының 5 меңнән артык алдынгы төзүчесе лаек була.

Камадагы хезмәт каһарманнарының даны тиз арада бөтен Советлар Союзына тарала. Гасыр төзелешен үз күзләре белән күрергә теләүчеләр бик күп булып чыга. Әмма ул чакта шәһәрдә профессиональ экскурсия үткәрүчеләр һәм туган як тарихын өйрәнүчеләр булмый диярлек. Шунлыктан 1972 елда Казан сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросының Чаллы филиалын ачарга ниятлиләр. Әлеге бурыч география укытучысы Валентина Забродинага йөкләнә. Ул төзелеш буйлап кызыклы турлар оештырырга тиеш була. Оештырылачак экскурсияләрнең барышын объектлар җитәкчеләре белән килештерү таләп ителә. Шундый эшче сәфәрләрнең берсендә Валентина Андреевна яңа гына казылган нигез чокырында поши күреп шакката. Урман кунагын коткаралар, экскурсия маршруты да төзелә. Шундый маршрутлар буйлап йөрергә көн саен уннарча, кайвакыт исә йөзләрчә кеше теләк белдерә – шәһәргә туристлар тулы сигезәр-тугызар пароход килә.

ЯШӘГӘН ДИ, БУЛГАН ДИ...

Анатолий Васильев Чаллыга дусты белән 1972 елда самолетта очып килә. Шәһәргә төнлә генә килеп җитәләр. Кунакханәгә барырга җыенуларын әйткәч, автобустагы юлдашлары барып та тормаска киңәш бирә – анда урын юк икән. Янәшәдәге бер-берсен ярты ел буе күрмәгән гашыйклар үзләре янына тулай торакка чакыра аларны: «Әйдә, килегез, безнең тулай торакта урын бар!»

– Кая килеп эләктек соң без, бу удар төзелешкә изгеләр җыелганмы әллә, дип аптыраштык, – дип искә ала үзенең Чаллы турында беренче тәэсирләрен киләчәктә шәһәр электр челтәренең район башлыгы буласы Анатолий Васильев.

– Яшәү шартларымы? Бөтен җирдәге кебек, бездә дә проблемалар җитәрлек иде, тик без аларга игътибар итмәскә тырыштык, – ди Гөлзада Рзаева. – Резин итек, бер телем икмәкне икегә бүлеп ашау... Яңа ел алдыннан бер банка майонез табылса, димәк, оливье булачак! Кемдәдер суган, кемдәдер бәрәңге бар. Бергәләшеп ясыйбыз да бергә ашыйбыз. Бөтен бәйрәмнәрне бергә үткәрдек. Бу чын дуслык иде.

Ул чакта чаллыларның уртача яше 24 яшь тәшкил итә. Зур төзелешләр романтикасы гүзәл затларны да үзенә тарта. Еш кына Чаллыны кәләшләр каласы, аннары исә... йөкле хатыннар шәһәре дип тә йөрттеләр. Биредә башта бәби тудыру йорты булмый, Зәйдә табарга туры килә. 1973 елда үзләренең бәби тудыру йорты файдалануга тапшырыла. Беренче ярты елда анда 5 меңнән артык бәби туа. Балалар бакчалары җитешми, шунлыктан сабыйларны чиратлап карыйлар – шул ук комсомол дуслыгы ярдәмгә килә. Әмма автогигантны һәм бөтен бер шәһәрне төзергә хәлләреннән килсә дә, үз гаиләсен төзи алмый калучылар да шактый биредә.

– Беләсезме, бу төзелеш аркасында күп кеше ялгыз калды, – дип сөйли Гөлзада Рзаева. – Эшкә баралар да – арып-талып кайталар. Монда инде кәләш йә кияү эзләү кайгысы түгел. Нәтиҗәдә, гаилә дә, бала да юк, туганнар исә еракта, шунлыктан гомере буе ялгыз яшәүчеләр дә күп. КАМАЗ күп язмышны сындырды.

...Бервакыт, тулай торак яныннан үткәндә, Гөлзада Рзаева мондый күренешкә тап була: ике комсомол, сагышланып, гармунда уйнап утыра. Нишләп болай боегып утыруларын сорарга дип яннарына туктала. Егетләргә туган йорт, туган авыл җылылыгы җитмәве ачыклана. Шунда авыллардагы кебек кичке уен оештыру идеясе туа.

– Бер атна эчендә диярлек без үзебезнең Мәдәният йортында бик күп гармунчыны тупладык, – ди Гөлзада Рзаева. – Беренче уенны атнакич – пәнҗешәмбе оештырдык. Яшьләр агыла башламасынмы! Аларга рәхәтләнеп бию, җырлау, кызлар белән танышу мөмкинлеге туды. Безнең кичке уенны хәтта ТАСС килеп төшереп китте. Әле хәзерге чараларда да: «Кайсыгыз кичке уенга йөрде?» – дип сорасам, бик күпләр кулын күтәрә.

Сүз уңаенда, бүген без күрергә күнеккән «Энергетик» Мәдәният йорты 1973 елда төзелгән. Шул ук комсомоллар салган аны. «Без гигант завод һәм гүзәл шәһәр төзибез, һәм анда күркәм күңелле кешеләр яшәргә тиеш», – дигән Рәис Беляев.

– Без бит бушка, ял көннәребез – шимбә һәм якшәмбеләрдә салдык бу бинаны. Рәхәтләнеп йокы туйдырыр урынга, төзелешкә килә идек, – дип искә ала Гөлзада Рзаева. – Акча лимиты заводка һәм шәһәргә генә бирелә иде. Әмма безнең җитәкчеләр Мәдәният йорты салуга да каяндыр акча тапты. Кемнәр генә килмәде аннары безнең янга! Без Евтушенко һәм Рождественскийны тыңладык, Высоцкий һәм Зыкина белән кочаклаштык...

...Чаллыдагы тарих музее экспозициясенең иң түрендә, пыяла витриналар чолганышында илдәге Бөтенсоюз удар комсомол төзелешләренең эстафета факелы тора. Аңа үзе булган героик хезмәт урыннарының эмблемалары беркетелгән. Чиркей ГЭС, Чернобыль АЭС, Тольяттидагы машина төзү заводы... Яр Чаллы – әлеге бөтенсоюз эстафетасының соңгы пункты.

Мәкаләне әзерләгәндә «Доброхот» альманахы материаллары файдаланылды.

КОМСОМОЛ ТУЕ



Комсомолларның иң якты хатирәләре 1 Май демонстрацияләре белән дә, ВЛКСМ сафларына кабул ителгән көннәре белән дә түгел, әлбәттә инде, туйлар белән бәйле. Кияү белән кәләш, ак фата, Мендельсон маршы, «Волга» ретро-автомобиле (ул чакта ретро түгел әле), туй табыны, иртәнгә кадәр биюләр һәм... нинди туй үпкә-низагсыз булсын инде... Барысы да гадәттәгечә. Барысы да, тик барысы да түгел шул! Кайчакта комсомол туйларында үзенчәлекле комсомол юнәлеше күзәтелә – туйны алкогольсез ясыйлар. Аларда катнашкан кешеләр ул вакытларны аерым бер горурлык белән искә ала, чөнки ничек кенә тырышырга туры килмәгән үзләренә: спиртлы эчемлекләрне чәйнекләргә дә салганнар, туйга кадәр үк «кызмача» да килгәннәр, «Әче!» – диясе урында «Бөтенләй әче түгел!» – дип кычкырганнар һәм башкалар, һәм башкалар... Тик болар соңыннан булган инде. Безнең бүгенге кияүләр һәм кәләшләр туй өстәленә килеп җитмәде әле, безнең янга турыдан-туры ЗАГСтан «килделәр» – алар барысы да комсомоллар һәм күпләре бу елларда үзләренең якут, сапфир, кайберләре хәтта алтын туйларын билгеләп үтә. Бәхетләре түгәрәк булсын! Һәм йөз тапкыр «Әче!»

Иллюстрация: Алексей Алёшин

«Комсомолец Татарии» газетасының комсомол тормышы бүлеге хәбәрчесе Римма Булатова һәм рәссам Владимир Ратниковның туе.

1981 елның 5 июне.

Фото Ратниковлар гаилә архивыннан

Комсомолның Казан шәһәре Бауман райкомы беренче секретаре Андрей Ершов һәм Бауман райкомы хезмәткәре Светлана Колешеваның туе.

1981 елның 21 феврале.

Фото Ершовлар гаилә архивыннан

«Комсомолец Татарии» газетасы хәбәрчесе Евгений Ухов һәм корректоры Галина Стеканованың туе.

1967 елның 4 ноябре.

Фото Уховлар гаилә архивыннан



КАИ ның радиоидарә кафедрасы инженеры Изольда Шәймарданова һәм Казан медицина университеты укытучысы Евгений Сахаровның туе.

1986 елның 4 гыйнвары.

Фото Изольда Сахарова архивыннан

«БҮГЕН БӘЯЛӘҮЧЕ БУЛМАСА, КИЛӘЧӘКТӘ БУЛЫР...»

Мәрҗанине тормышта белгән кешеләр аны мәһабәт гәүдәле, горур, аз сүзле, җитди, мөстәкыйль фикере булган бер зат дип сурәтләп калдырган. Ул чиксез тырыш булган, күп эшләгән. Үз хезмәтләре, аның турындагы хезмәтләр, Мәрҗани керткән яңалык-реформалар хакында күпмедер хәбәрдар булып, исемен еш телгә алсак та, тормышы-көнкүреше турында яхшы беләбезме? Бу санда 200 еллык юбилее уңаеннан хәтеребездәге «ак таплар»ны барларга булдык.

Рөстәм Шәмсутов рәсеме

Әзерләде:
Луиза Янсуар

НӘСЕЛ ҖЕБЕ

Мәрҗанинең нәсел-нәсебе ике яктан да гыйлемле кешеләрдән торганга, ул нәселләреннән булган имамнарны санаганда да, егермедән артык авылны искә алган. Бабасы Сөбхан шәкерт вакытында ук гарәп һәм фарсы телләрендә алтмыштан артык китап күчереп чыккан. Ул тарихны яхшы белгән, халыкның хәл-әхвәленнән дә хәбәрдар булган. Мәрҗани бабасыннан байтак тарихи мәгълүматлар ишетеп калуы турында үзе дә әйтә.

Сөбхан бабасы 25 ел буена Җәке һәм Хөсна (Кысна) авылларында имам була, мөгаллимлек итә. Соңрак, имамлык хезмәтеннән азат булгач, кәсеп һәм сәүдә эше белән шөгыльләнеп, 87 яшендә дөнья куя. Бу чакта Шиһабетдин 16 яшендә була. Бабасы Сөбхан Мәрҗанине үз итә, анасыннан ятим калган бала, дип, аны күп вакыт янында йөртә, гыйлемен тирәнәйтергә булыша, таяныч була. Мәрҗани, Бохарада укып кайткач, бабасының каберенә таш яздыртып куйдыра.

Мәрҗанинең әтисе Баһаветдин заманында Бохарага барып укып кайткан, Бохара әмире Әмир Хәйдәр бине Мәгъсум якын иткән затлардан була. Ул әмир сараенда уздырылган гыйлем мәҗлесләрендә катнашкан, әмирдән күп илтифат күргән, хәтта үзенең авылына кайтып тора башлагач та әмир аңа даими рәвештә бүләкләр юллаган. Баһаветдин башта Ябынчыда, аннан Ташкичү авылында имам һәм мөдәррис булып торган, 40 елдан артык төрле фәннәрдән дәрес укыткан, байтак шәкертләр әзерләгән. Мәрҗани бер мәҗмугасында атасында укып чыккан имамнардан 35 кешенең исемен телгә ала.

Әнисе Бибихөбәйбә акыллы, зирәк, гыйбадәтле хатын булган. Ул бик иртә – 29 яшендә дөнья куя. Хөбәйбә күркәм язуы белән билгеле – Мәрҗани аның кулы белән язылган догалардан торган бер кәгазьне саклавы турында язып калдыра. Шулай ук ул 18 яшендә әнисе каберенә үзе бер таш язып куя.

Әнисе тарафыннан бабасы мулла Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек Сембер тарафында, Чокалы исемле авылда, соңрак Ашыт авылында имам һәм мөдәррис була. Әлеге бабасы йогынтысында Шиһабетдин үзендә Коръән вә Сөннәткә мәхәббәт тәрбияләнүен искәртә.

Фотолар: Луиза Янсуар; Комыргуҗадагы 2 нче гимназия каршындагы Мәрҗани музееннан, Ислам музееннан, архивлардан алынды

КӨРӘШЧЕ ШИҺАБИ

Мәрҗани 1233 һиҗри ел, 7 рабигыль-әүвәл / 1818 милади ел, 3 гыйнварда кич, ястү намазы вакытында Ябынчы авылында гаиләдә беренче бала булып дөньяга килә. Ул туганда әтисенә – 32, әнисенә 24 яшь була. Әнисеннән ул 5 яшендә кала.

«Бервакыт су янында мин мәче баласы илә уйнап йөри идем. Шулвакыт, әнкәң чакыра, диеп, аның янына алып кайттылар. Ул вакытта әнкәм авыру иде. Янына барганда, кайгылы рәвештә булган күзләре илә бераз өстемә карап торды. Аннан күзләреннән яшьләрен агызып: «Әй балам! Миннән соң анаң кем булыр? Өсбашыңны кем карар? Кем тәрбия кылыр?» – диде.

Шуннан соң анам вафат булып, бер шәкерт үземне анам җеназасы артыннан каберга кадәр күтәреп барган иде».

Шиһабетдин Мәрҗани истәлекләреннән.

Мәрҗанинең балачагы, үсмер еллары, яшьлеге турындагы хатирәләрнең иң тулылары – энесе Садреддин истәлекләре. Ул аларда Шиһаб абыйсының зирәклеге, кечкенәдән акыллы, диндар булуы, үткенлеге, булдыклылыгы турында да яза, кылган балачак шуклыкларына да мул урын бирә. Аның бар яклап үзен тәрбияләгән, үстергән кеше булуын аеруча ассызыклый. Яңа нәрсәләргә һәвәслеген дә искәртеп уза. Әйтик, аның истәлекләре буенча без Мәрҗанинең яңа уеннар уйлап табуын, өлкәннәргә генә хас булганча фикер йөртү сәләтенә ия булуын, өлкәннәргә яшьли киңәшләр бирүен беләбез.

«СӘЛАМӘТ ҮССӘ, ЗУР БЕР ГАЛИМ БУЛЫР...»

Мәрҗани бик кечкенәдән укый башлый. Алтынчы яшеннән башлап атасының мәдрәсәсенә йөреп, борынгы тәртипне үзләштерә, озакламый гарәпчә укырга керешеп, җитди китапларга күчә.

«Мин никадәр шәкерт укыттым, күрдем. Әмма Шиһабетдин кадәр зиһенле, аның кадәр аңлы шәкерт күрмәдем. Сабакларын берәр генә мәртәбә укый да, һәммә яшьтәшләреннән артык белә, дәресне буташтырып икенче урыннардан сорагандa да һич аптырамый, буталмыйча җавап бирә, унике-унөч яшьлек балаларның шулкадәр белүенә гаҗәпләнәм. Әгәр дә хәзрәтнең бу баласы сәламәт кенә үссә, зур галим булыр».

Ташкичүдәге мәдрәсә хәлфәсе истәлекләреннән.

Мәрҗани гаиләдә олы бала булгач, йорт эшләрен карау, башка балаларга күз-колак булу да аның өстенә төшә торган була. Күп вакытларда ул дәресләрен барысы да йоклап беткәч, кичләрен хәзерли. Өлкәнәйгәч, яшь вакытларын искә төшереп, ул йорт хезмәтләре, балалар карау мәшәкатьләре белән мәшгуль булып, дәрес укырга вакыт таба алмый интегүе турында сөйли торган була. Үги анасыннан эштән арынырга рөхсәт алуы читен булганга, мәдрәсәгә төннәрен курка-курка барып сабак өйрәнгән чаклары да була. Яшь анасы белән икесе арасында каршылык чыгып, атасына бу билгеле булып, кайчак Шиһабетдин җәзага да тарый. Аның үз мәдрәсәсе шәкертләренә болай сөйләгәнлеге мәгълүм: «Балаларыгыз булса, сукмый, кыйнамый, яхшы тәрбия итәргә тырышыгыз. Суккан вакытта да башка, җилкәгә сугудан сакланыгыз. Башка сугу мигә зарар бирә, хәтер көчен, зиһенне киметә. Безнең әткәмез яшь вакытында минем башыма суккалый иде. Шуның илә бераз зарарландым. Хәтерем кимеде...»

Әмма үги ана кулында тәрбияләнүенә ул беркайчан да үкенү белдермәгән. Киресенчә, әни назы, иркәләве татып үсмәгәч, күбрәк үземә таянырга, үземне-үзем кайгыртырга, башкалардан артыграк тырышырга туры килде, бу яхшыга булды, дия торган була.

Мәдрәсә елларында ук өлкәннәр белән гыйльми бәхәсләргә керергә, бу бәхәсләрдә өстен чыгарга ярата Мәрҗани. Бабасы, атасы белән дә бәхәсләшә ул, хәлфәләре белән дә. Хәлфәләре аңарда тәнкыйди карашның бик нык һәм иртә сизелүен, бөтен нәрсәне чагыштырып карап, хакыйкатьнең төбенә төшәргә омтылуын ассызыклыйлар. 17 яшендә ул инде әтисенең мәдрәсәсендә башкаларга да белем өйрәтә, укыта башлый.

«Мәрҗани бар җәһәттән башкалардан өстен булуны сөя иде. Көрәшне бик ярата иде. Көрәшкә яхшы ук осталыгы да бар иде. Яңа гына балигъ булган заманында Ташкичү вә күрше авыл сабантуйларында камил ир булган таза мужикларны ега иде. Шуңа күрә Ташкичү вә әтрафында батырлык вә көрәшчелек илә исем алган тирә-якның кешеләре Мәрҗанине «Көрәшче Шиһаби» дип таный иде.

Көрәшкәндә Мәрҗанинең шундый гадәте бар иде – егылганнар белән түгел, бәлки егучы баһадирлар белән көрәшүне сөя иде. Үзеннән бер мәртәбә егылган кеше илә көрәшми иде. Һәм дә ул кеше еккан кеше белән дә көрәшми иде».

Энесе Садреддин истәлекләреннән.

ХЫЯЛДАГЫ БОХАРА

Әтисе Бохараны һәрчак мактап искә ала торган булгач, анда барып уку Мәрҗанинең хыялына әверелә. Һәм менә 21 яшендә ул Бохарага кузгала. Ул чакларда татарларның сәүдә һәм җәмәгать эшләре куәтле була, Бохара белән Казан арасында кәрван йөреп тора. Мәрҗани Мәңгәр авылындагы сәүдәгәр Мөхтар бине Мөхәррәмнең Бохарага баручы йөкләре белән кузгала сәфәргә. Моңарчы аның, тирә-юньдәге берничә авылдан кала, Казанны да күргәне булмый. Әтисе улын Мәңгәр авылына кадәр ат җигеп озатып куя.

«Күңелем тулып еларга теләсәм дә, ачык белдереп елаудан тартындым... Атамны озаткач, әллә ниләр уйладым. Күңелем бик йомшарды. Мәңгәр мәчетенә кереп, елый-елый, ике рәкәгать намаз укып, дога кылдым».

Мәрҗанинең замандашларына сөйләгәннәреннән.

Троицкига барып җиткәч, юлчылар туры килмәгәнлектән һәм кәрванның сәфәр вакыты булмаганлыктан, Мәрҗани шәһәрдә фатир алып 4 ай вакыт түләп тора. Биредә ул тик ятмый – төрле гыйльми мәҗлесләрдә катнаша, бер галим

1. Мәрҗанинең өс киеме белән бизәкле таягы.

2. Мәрҗани затлы савыт-саба яраткан. Юл сәфәренә чыкканда да, һәрчак үз савыт-сабасы белән чыга торган булган.

3. Мәрҗанинең Хаҗга барганда кигән фәсе.

4. Намазлыгы, кәләпүше һәм дисбесе.

5. Мәрҗанинең шәхси мөһере.

мөәзин белән танышып аралаша. Атасы юлга биреп җибәргән акчалары Бохарада хөҗрә сатып алып урнашырлык һәм яшәрлек тә булмый. Шуңа күрә Мәрҗани акча юнәтү юлларын эзли башлый.

«Бохарага барганда, кулындагы акчасына Троицкидан кечкенә сандык, бизәкле савыт вә тартмалар алып, кайсыларын юлда, кайсыларын Бохарага барып саткан. Ул нәрсәләрдән яхшы гына файда итеп, Бохарага баргач, үз акчасына хөҗрә алырга ирешкән».

Энесе Садреддин истәлекләреннән.

Кыргызлар аша узганда Мәрҗани бер кыргызның өендә кунак була. Анда аның галимлегенә таң калалар. Шулай итеп, Ташкичүдән чыгып китеп, 7 аен сәфәрдә уздыргач, Мәрҗани хыялындагы Бохарага барып ирешә.

«Ишан хәлифә Ниязколый» мәдрәсәсеннән 35 сумга хөҗрә алып урнашкач, Мәрҗани баштанаяк укуга керешә. Ул төрле мәдрәсә мөдәррисләренең дәресләренә йөри. Остазлары аның гыйлемле, тырыш, үзфикерле булуын күреп алып, бер елдан соң инде кайбер шәкертләргә дәрес бирүне дә ышанып тапшыра башлый. Бохарага зур өметләр баглап килгән Мәрҗани үзе, мәдрәсәләрне йөреп чыгып, чагыштырып караганнан соң, мондагы дәрес тәртипләреннән канәгать булмавын ваемлый.

Дәресләрдән канәгатьлек алудан туктагач, ул Бохара китапханәләрендә булган кыйммәтле әсәрләргә ябырыла. Мәрҗани алга таба шәкертләренә дә бу ысулны тәкъдим итә торган була – зиһенле, аңлы кешеләргә остаздан алган белемгә караганда артыграк белемне үзлектән уку һәм өйрәнү бирә ала, дип ышана ул. Аңа дамелла Хөсәен Каргалый бик нык ярдәм итә: кирәк булган китапларны биреп тора, булмаса, юнәтә. Бервакыт хәтта сирәк китапны әмир китапханәсеннән алып кайтып тапшыра Мәрҗанигә. Урта Азиядә уздырган 11 ел эчендә Мәрҗани аның белән дустанә мөнәсәбәттә яши. Дамелла Хөсәен кереме бик аз булган, һәрчак акчага мохтаҗлык күргән Мәрҗанигә тормыш итү ягыннан да зур ярдәм күрсәтә.

Бохарада бер кыш кичкәч тә Мәрҗани, тамагын туйдырыр өчен, мөгаллимлек эшенә керешә. Каракүл каласында гына да ул 7 ел дәрес укыта. Шулай ук китап күчерү белән шөгыльләнеп тә бераз керем ала.

СӘМӘРКАНД СӘФӘРЕ

Бохарада 5 ел торганнан соң, Мәрҗани Төркестан якларының икенче бер бөек гыйлем мәркәзе исәпләнгән Сәмәркандка юл тота. Атаклы «Ширдар» мәдрәсәсендә урнаша. Биредәге үз заманының зур фикерле галиме саналган Әбү Сәгыйдь казыйның балаларына хосусый дәресләр бирә башлый, үзе исә хәзрәтнең дәресләренә йөри. Сәмәрканд чоры Мәрҗанине Мәрҗани иткән чор буларак исәпләнә. Ә казый Әбү Сәгыйдь аның карашлары формалашуда, тәгаенләнеп җитүдә зур роль уйнаган шәхес була. Мәрҗани аның китапханәсендә теләгән кадәр вакытын уздыра, кадерле кунак була. Соңрак ул Сәмәркандта торган вакытларын гомеренең «иң рәхәт вә ләззәтле сәгатьләре» итеп саный, казый хәзрәтләрен зур илтифат белән искә ала.

«Мин Сәмәркандта аның хозурында торганда, намаз укыганда, һәрвакыт мине имам итә, кайбер вакыт юлда яки бакчада намаз укырга туры килеп, үзенә намазлык яки кием бирсәләр, моңа имам лаеклырак, дип, миңа бирә, үзе җирдә укый иде. Бервакыт Сәмәрканд хакиме хозурында мине артык мактап: «Бу егет гыйлем тугрысында зур китаплар язган борынгы галимнәрдән дә өстен», – дип сөйләде.

...Суфыйчылык тарафдарларын вә шәехләрне бик ихтирам итә, чит мәмләкәт адәмнәрен очратканда, сөнни, шигый булуына карамыйча, ярдәм вә хөрмәт итә, мәмләкәтләре хәлләрен сораша иде. Үзе бик бай булып, күп урыннарда җирләре, бакчалары, йортлары бар иде... Мин китапларын алып торып, күп файда күрә идем. Башка урыннарда табылмаячак сирәк вә нәфис китаплар күреп, күп нәрсә күчереп тә алдым. Минем тарих илә шөгыльләнүемә, тарих китаплары укый башлавыма баш сәбәп ошбу Сәгыйдь хәзрәтләре булды».

Шиһабетдин Мәрҗани истәлекләреннән.

«ЯЛАНАЯК БЕР ШӘКЕРТ ИДЕ...»

Бохарага кайткач, Мәрҗани иң бай һәм күркәм мәдрәсәләрнең берсе – «Мир Гарәб»тә бүлмә сатып алып тора башлый. Энесе Садреддин да Бохарага килеп, бергә яшиләр. Бер җәй Мәрҗани биредә имам да булып тора.

Бохарада икенче яшәвендә ул инде вакытын бушка сарыф итми: гыйлемен арттыра, үзе дә язмалар яза. Энесе Садреддин искә алганча, Мәрҗанинең зур ике букчасы булып, ишеткән, күргән бар нәрсәләрен язып, шуларга тутыра барган. Бу вакыт эчендә үзбәк, төрекмән һәм татар шәкертләрен укыта, күп кенә олы мәдрәсәләр белән хезмәттәшлек итә. Голамә-мәҗлесләрдә еш катнаша.

Бохарада чагында ул суфыйчылык белән дә кызыксына, бу тарафта эзләнә башлый. Башта мәшһүр шәех Хәлифә Ниязколыйның улы шәех Гобәйдулла хәзрәтләре белән бәйләнешкә керә. Бохарадан кайтасы елында иң мәшһүр шәехләрдән Сахибзадә белән аралаша башлый.

«Мәрҗани һичнәрсәдән һушсыз калуны, бер нәрсәне аңлап җитмичә, башкаларга ияреп кенә тәнкыйтьләүне сөйми, һәртөрле бөтенлекне җыярга омтыла иде. Шунлыктан Сахибзадә ишанга барып йөрде. Һәр көн иртә намазына барып, кояш чыкканчыга кадәр шунда торып кайта иде. Ошбу рәвешчә ике ай кадәр йөрде. Бүлмәдә вакытында һәр көн берникадәр Коръән укый, миңа да Коръәнне күп укырга киңәш итә иде. Бохарадан киткәндә, ошбу ишан Мәрҗанигә ишанлык шәһадәтнамәсе, бер таяк һәм хирка (кием) бирде».

Энесе Садреддин истәлекләреннән.

Мәрҗани китапларында суфыйчылыкны һәм суфыйларны һәрвакыт ихтирам белән искә ала, суфыйчылыкның нәфесне тыю юлларын мактый, аны зур бер тәҗрибә, Аллаһка якынаю юлы буларак таный. Әмма шәкертләрен суфыйчылык юлына кереп китәргә өндәгәне булмый. Бары Коръәнне мәгънәсен аңлап, тоеп, үзегез аша кичереп укыгыз, дип кенә әйдәгәнен искә ала замандашлары.

«Бохарада ул яланаяк йөри торган бер шәкерт иде. Тәкәллефсез генә тормыш итә, киемсалымга күп әһәмият бирми, шәкертләр арасында булган әшәке гадәтләрдән саклана, үзен бик саф итеп сакларга тырыша, башка шәкертләргә күп катнашмый, атна кичләрдә булган шәкертләр мәҗлесенә бармый, тамаша вә хозур урыннарына йөрми. Казанга кайтканнан соң миңа да: «Дуслык гыйлемгә киртә була. Башкалар белән күп аралашма, шәкертләр мәҗлесләренә вә хозурларга йөреп вакыт әрәм итмә», – ди иде».

Энесе Садреддин истәлекләреннән.

«КАЙСЫ ФӘННӘН БАШЛЫЙК?..»

Мәрҗани Бохарадан кайткан вакытта Казандагы Беренче мәчетнең имамы мелла Сәгыйдь бине Хәмит, имамлыгыннан чыгып, хаҗ сәфәренә китеп, беренче мәхәллә имамсыз калган була. Беренче мәхәлләнең ул вакыттагы табигый рәисе, Казан мөселманнарының атаклы, абруйлы бае Ибраһим бине Гобәйдулла Юнысов (Озын Ибрай), үз мәхәлләсе булган беренче мәхәлләгә беренче дәрәҗәдәге галим затны имам итеп сайларга карар кылып, шундый кешене эзләтә башлаган була. Мәрҗани белән бергә кайтучы кәрвандагы байлар Ибраһим байга Шиһабетдин әфәндене күрсәтеп, болай тәкъдим итәләр: «Ошбу дамелла Шиһабетдинның Казанның иң мәшһүр зур мөдәррисе булган хәзрәтләрдә дә ул ел укытырлык куәте бар», – диләр.

Ибраһим бай Мәрҗанине Казанга голамә-мәҗлескә чакыртып ала. Аңа кадәр инде Бохарадан кайтып ике аен туган ягында уздырган Мәрҗанинең даны төрлечә таралып өлгерә. Берәүләр аны бик олылый: «Галим зат, мулла итеп куярга тырышырга кирәк», – диләр. Икенчеләре исә, киресенчә: «Бохарада чагында кирәкмәгән нәрсәләр укып кына гомер үткәргән, мәдрәсә гыйлеменә әллә ни дикъкать бирмәгән. Остазларының дәресләрен дәвам итеп, алардан фатиха алырга тырышмаган. Мулла итеп куюдан бер дә бәрәкәт чыкмас», – дип коткы тарата.

Ибраһим бай корган мәҗлес, аңлашыла инде, Мәрҗани өчен үзенә күрә бер имтихан, сынау була.

«Ошбу мәҗлестән соң Казан шәһәрендә вә тирә-юнендә сүзләр күбәеп, олуг шөһрәт илә күп сүзләр чыкты. Мәҗлестән соң Мохтар бине Мөхәррәм, Ибраһим бай вә мәхәллә халкы тарафыннан вәкил булып килеп, беренче мәхәлләдә җәмигъ мәчете имамы вә хатыйб вә мөдәррис булуыбызны үтенүләрен ирештерде. Атабыздан рөхсәт алу шарты илә вәгъдә бирдем вә авылга кайтып киттем. Аннан соң мәхәллә әһелләреннән иттифакнамә (приговор) алып, Ибраһим бай безне корбан ашына чакырды. Атабыз илә Казанга килдек. Зур мәҗлес булып, бәгъзе сөйләшүләр вә бәхәсләр булды. Соңра авылыбызга кайтып, бер ай кадәр торганнан соң, өч чана, сигез ат илә Ташкичүгә алырга бардылар. Шуннан тәмам күчеп килеп, 12 мөхәррәм, 1266 / 28 ноябрь, 1849 елда беренче мәртәбә җомга намазында имам булып укыттым».

Шиһабетдин Мәрҗани истәлекләреннән.

Мәрҗани турында Казанда сүз таралган булганга, мәдрәсәдәге шәкертләр дә аны зур түземсезлек һәм өмет белән көтеп ала. Беренче дәрес милади белән 1849 елның 12 декабрендә узган. Шәкертләр аңардан: «Кайсы фәннән дәрес башлыйк?» – дип сораган. «Кайсы фәнне ихтыяр итсәгез, шуның илә башларбыз. Ләкин иң элек тәфсир дәресе илә башлау муафыйк булыр», – дип, иң беренче эш итеп, Мәрҗани тәфсир дәресе укыткан.

Дәресләргә зур әһәмият биргән, тырышып әзерләнгән. Күп вакытын мәдрәсәдә уздырган. Ул имам булып урнашканнан соң бер ел узгач, Казанның дүртенче мәчете имамы вафат булып, андагы күп кенә шәкертләр Мәрҗани мәдрәсәсенә күчә. Шушы шәкертләр арасыннан зыялы, затлы, аңа фикердәш булырдай бер плеяда үсеп чыга. Мәрҗанинең абруе артканнан-арта, тормыш хәле дә яхшыра. Мәхәлләнең иң яхшы җиреннән аңа йорт урыны бирелә, шунда ул йорт торгыза.

Әмма тора-бара хәлләр мөшкелләнә: Казанның байтак муллалары Мәрҗанинең фикерләре белән килешмичә, аның туры тәнкыйтен яратмыйча, кискен каршылыкка күчә. Аннан да бигрәк, Ибраһим бай белән аралары бозылып, аның тәэсире нәтиҗәсендә Мәрҗанинең ике мәртәбә указы алына.

«Ибраһим бай үзен һәммә байлардан гына түгел, муллардан да өстен тота, һәрнәрсәне үзе теләгән рәвештә йөртергә тырыша, башбаштаклыгы да бик куәтле була. Мәрҗанине никадәр генә олылыса да, үзенә табигый булган уен-көлкедән сакланмый; башка муллаларга мөгамәлә иткән кеби мөгамәлә итүне сөя, Мәрҗанине дә үзе теләгәнчә йөртергә тели иде. Фәкать гаять җитди, гали табигатьле Мәрҗани хәзрәтләре башкалар кулында уенчык булуны, башкалар фикеренә ияреп йөрүне кимчелек саный. Ибраһим бай ишарәсенә карап тора торган кайбер муллалар кеби булуны бик түбәнлек саный, шунлыктан аны тиешеннән артык зурламый иде.

Бервакыт Ибраһим бай, Мәрҗанигә очрап: «Ахшамнан соң миндә голамә-мәҗлес, шунда барсагыз иде», – ди. Мәрҗани бер фәкыйрь кешене искә алып: «Ахшамнан соң фәлән кешегә вәгъдә иткән идем, шунда барасым бар». – ди. Ибраһим бай: «Вәгъдә итсә дә, мине ташлап, шул фәкыйрьгә бара алмас әле», – дип мәҗлес хәзерләткән. Мәрҗанинең бай мәҗлесне ташлап, бер фәкыйрь адәмгә китүе гакылына сыймаган».

Җәмәгать һәм дин эшлеклесе, язучы, педагог, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме Шәһәр Шәрәф китабыннан.

Ахыр чиктә, Мәрҗанинең өстеннән «яше җитмәгән кызга никах укыды» дигән гаепләү белән гариза бирдерәләр. Аны дәрес укытудан да читләштерәләр. Аның урынына хаҗдан кайтып төшкән Сәгыйдь хәзрәт тиз генә арада урнашып куя. Мәдрәсә шәкертләре көтмәгәндә гауга кубара: «Без Мәрҗанидән башкада дәрес укымыйбыз, гомеребезнең әрәм булуына һич разый түгелбез», – диләр. Шулай итеп, гөрләп торган мәдрәсәдәге шәкертләр башка мәдрәсәләргә тарала...

«КАТЫП ҮЛМӘССЕЗ ӘЛЕ...»

Эше эчке эшләр министрына бирелеп, яңадан тикшерелгәч, бер елдан соң Мәрҗани яңадан укыту хокукы ала. Указы да кайтарыла. Элеккеге шәкертләренең күпчелеге, яңадан җыелып, аңардан дәрес ала башлый.

Мәрҗани Ибраһим байга мөрәҗәгать итеп, мәдрәсәне төзәттерүне сораса да, бай түбәнчелек күрсәтми, «вакытым юк», дип кенә җавап кайтара. Мәдрәсә акрынлап ташландык хәлгә килә.

«Мәдрәсәнең югары каты агач булып, аның читләре черегән, ишелеп төшмәсен дип, берничә җиргә баганалар куелган, диварлары юеш, идән башлары череп сынып төшкән, кыш көннәрендә читләреннән, тәрәзә тирәләреннән буран керә иде. Ашханәнең тәрәзәләре ватылган, ишеге ачык, хайваннар кереп йөри, кыш көнендә буран уйный. Мәдрәсәгә су китермиләр. Үзебез комган, чиләк берлә Кабан күленнән су ташыйбыз, салкын кыш көнендә тышта тәһарәтләнәбез. Ибраһим байга утын сорарга барсак: «Катып үлмәссез әле. Тышта кар күп, мичкә кар ягыгыз», – дип көлеп кайтарып җибәрә, кыш айлары кергәч кенә азрак утын җибәрә иде».

Кыяметдин әт-Тәрҗемани һәм мәдрәсә шәкертләре истәлекләреннән.

Әмма Мәрҗани, яңа мәдрәсә төзелгәнче, биредә укытуын дәвам итә, аны һәм шәкертләрне ташлап чыгып китми. Ә аларның саны 70-80, күп булса, 100 тирәсе була. Бу елларда Мәрҗани үзенең иң атаклы хезмәтләрен яза, мәдрәсәдән калган вакытын иҗатка сарыф итә. Атаклы Радлов тәрҗемә итәчәк «Болгар вә Казан тарихы» да шушы чорга карый.

«БЕР КӨН ЭЛЕК УРАЗАГА КЕРДЕ...»

Хезмәтләре таралып, акрынлап Мәрҗанигә булган мөнәсәбәт үзгәрә башлый. Аның дәрәҗәсе, абруе көннән-көн арта бара. Ул заманнарда Казанда әһәмиятле бер гадәт була: гаетләрдә, бөтен Казан халкы бергә җыелып, Яңа Бистә ягында, бер имам артында һәммәсе бергә намаз укый. 1863 елда Корбан гаетендә Мәрҗанине чакыралар. Ул килеп намаз укый.

1867 елда Мәрҗанигә Диния нәзарәте тарафыннан ахун вә мөхтәсиблек дәрәҗәсе бирелә. 1869 елда Казан губернаторы чакыртып алып, аңардан хайваннарны саклау һәм аларга шәфкать итү турында татарча бер рисалә язып бирүен үтенә. Мәрҗани язган рисалә кабул ителеп, губернатор имзасы белән аңарга рәхмәт хаты тапшырыла. Рисалә үзе, казна акчасына бастырылып, халыкка таратыла.

Ул арада тискәрелеге чиктән ашкан Ибраһим байга инде башка байлар да ачу белән карый башлый, мәдрәсәне рәтләвен таләп итәләр. Ибраһим бай: «Мәхәллә халкы сарыклар, миннән башка эш эшли алмаячаклар», – дип сөйләнгәч, гайрәтләре бөтенләй чиктән аша. Мәдрәсә күршесеннән җир алып, аны мәдрәсәгә кушалар. Мәдрәсә җирләрен карау өчен махсус назирләр (попечительләр) сайлап, Диния нәзарәтенә гариза бирелгәннән соң, ниһаять, Ибраһим бай мәдрәсәне таштан яхшы итеп салдыра да, «мәдрәсәгә шәкертләр керсеннәр» дип, Мәрҗанигә хәбәр итәргә боера. «Мәдрәсәне бөтенләй мәхәллә ихтыярына тапшырса, шәкертләр күчәчәк», – дип җавап бирә Мәрҗани. Әмма Ибраһим бай бу шартны кабул итми.

«Ибраһим бай турында шуны да онытмаска кирәк: аралары никадәр салкын булып гомер итсәләр дә, Ибраһим бай Мәрҗанигә матди мөнәсәбәтен, ярдәмнәрен һичвакыт үзгәртмәде. Хәтта указы алынган вакытларында да бирә торган ярдәмен, бүләкләрен җибәреп торды. Бу да аз тырышлык түгел».

Сафиулла хәзрәт сөйләгәннәрдән.

Ахыр чиктә эшне татар мәктәпләре инспекторы, мәшһүр шәрык белгече Радловка тапшыралар. Аның 1875 елның 1 августында Мәрҗанигә юлланган мәктүбендә Ибраһим байның мәдрәсәне мәхәллә халкы хөкеменә тапшырырга җыенуы хакында хәбәр ителә. Ул арада Казан муллалары Мәрҗани өстеннән, бер көн элек уразага керде дип, Диния нәзарәтенә гариза юллап өлгерә. Шуны сылтау итеп, 6 айга Мәрҗанинең указы алына, имамлыгы тыела. Соңыннан, Истанбул, Шам, Бохара якларында шулай уразага керергә тиешлек раслангач, Мәрҗанинең указы кайтарып бирелә.

Алдагы елларда Мәрҗани мөгаллимлек иткән мәдрәсә зур абруй казана, елдан-ел биредә шәкертләр арта башлый. Ул арада Мәрҗанинең үз мәхәлләсендәге байлар белән дуслары, акча җыеп, «Мәрҗани мәдрәсәсе» буларак танылачак зур таш мәдрәсәне салырга керешеп, 1881 елның 25 сентябрендә аны тәмамлыйлар. Шәкертләр яңа бинага кереп урнашып, дәрес укый башлый. Иң күп ярдәм итүче Сафа хаҗи Галикәев була – ул 7 меңгә кадәр чыгым тота. Ул үз чорындагы мәдрәсәләрнең иң камиле һәм яңа ысул белән салынганы дип исәпләнә. Мәрҗани бу мәдрәсәдә 8 ел буена, гомеренең азагына кадәр дәрес укыта.

«Борынгы әйберләргә бик омтылышлы булды. Төшкә зур игътибар итте, төшләрен гел сөйли иде. Яшь вакытында икешәр мәртәбә хәзрәти Мусаны, хәзрәти Гомәрне күргән.

Русча өйрәнүне, һәртөрле чит гыйлемнәрне өйрәнүне мәгкуль күрсә дә, русча катыштырып сөйләшүне ишетсә: «Мин рус түгел, миңа татарча гына сөйләгез», – дип, кискен тыя иде.

Кием-салымда купшы, затлы булып, һичбер тап тотмый иде. Чалмасы һәрвакыт ак вә чиста булыр, ара-тирә төсле чалмалар да кияр иде.

Кунак йөрешүне сөймәсә дә, акыллы кешеләр белән гәпләшеп утырырга яратты. Иосиф Готвальд – Мәрҗанигә, Мәрҗани Готвальдка барып озаклап утыралар иде. Радлов та еш килеп йөрде, кайвакыт танышларын, кунакларын да алып килер иде.

Бер тапкыр губернаторга баргач, губернатор Мәрҗанине бик олылаган. Шуннан кайткач: «Төче телле түрәдән саклан, дигәннәр. Моннан да сакланырга кирәк», – дип сөйләде. Губернатор бер вакыт үзе Мәрҗанигә килгәч, хәзрәт йоклый, дип, аны асраулар борып кайтарып җибәргәннәр...»

Кызы Галия сөйләгәннәрдән.



Мәрҗани мәчете. Аның мөнбәре.

«КЫЯМӘТТӘ КУЛЫБЫЗ ЯКАСЫНДА БУЛСЫН...»

1870 елның 2 февраленнән соң ачылган мөселман мәктәп вә мәдрәсәләрендә русча укытуның мәҗбүри булуы хакында канун игълан ителә. 1872 елда моны күзәтү өчен махсус инспектор билгеләнә. Мөселман мәдрәсәләренә рус телле мөгаллим кую турында сүз булып, халык арасында бу җәһәттән шактый гына фетнәләр дә куба. Галимнәр русча укытуның зыяны турында зур бәхәсләргә керә, халык дулкынлана. Бу – хәрам, диешәләр. Русча укытуның да булуы дөрес вә тиеш икәнлеген яклаучылар арасында Мәрҗани хәзрәтләре дә була.

Озакламый Казанда русча мөгаллимнәр хәзерләү өчен Учительская школа ачыла. Бирегә дин мөгаллиме булып Мәрҗани хәзрәтләре билгеләнә. Аны Радлов махсус үтенеп чакырып ала. Хәзрәтнең бу эшкә алынуын тәнкыйтьләүчеләр күп була. Ул укыта башлагач, урамга җыелып, күпләр аның «школага» барганын һәм кайтканын күзәтеп торган. Казанның ул чакта абруйлы булган бер мөдәррисе олы мәҗлестә: «Шиһаб мелла – миссионер. Ул сатылган кеше. Русча укуга баш сәбәп ул гына булды. Кыямәттә кулыбыз якасында булсын!» – дип белдерә. Мәрҗанинең «рус школасы»на йөреп укытуын дошманнары гына хәкарәт итеп калмый, дуслары да урынсыз күрә.

1880 елның 3 июнендә Мәрҗани Казан губернаторына хаҗ сәфәренә рөхсәт бирүен сорап гариза яза. Ике айдан соң рөхсәт язуы ала. Шуннан соң хаҗга барырга хәстәрлек күрә башлый. Үзенең икътисадый эшләрен карауны аерым бер карендәшләренә тапшыра һәм васыятьнамә яза. Васыятьнамәдә 10 баласына да акчалата өлешне бүлә. Шулай ук аларга китапханәсен, язмаларын мирас итә. «Вә тагын шкафымда булган барлык шкаф әсбабым, касә вә чынаяк вә чәйнек һәм табаклар, күбесе үз бабаларымнан калган төсләре дип хөрмәтләп сакланган нәрсәләр булганы өчен ул нәрсәләр беркайчан да сатылмасын, кешегә бирелмәсен», – дип тә өсти. Мәхәллә эшләрен карауны шәкертләренә тәгаенли.

1880 елның 11 августында иртәнге намаздан соң хаҗ сәфәренә кузгалалар. Бу сәфәр вакытында сәфәрдәшләре аның төрки дөньяда абруе никадәр зур булуына инана. Искә алулары буенча, Россия калаларында да, Төркиядә дә, Мисырда да, гарәп илләрендә дә Мәрҗани үзен өендәге кебек иркен хис иткән. Гарәп һәм фарсы телләрендә, рус телендә җиңел аралашкан.

Вафат көнендә Мәрҗани хәл белергә кергән бер төркем укымышлыларга тәфсир китаплары турында сөйли. Бу көнне күп Коръән укый, тәкъбир әйтә. Мәшһүр дин әһеле 1889 елның 18 апрелендә дөнья куя. Үлгәндә иң соңгы сүзләре «Аллаһ Раббәнә вә Раббилгаләмин» вә «»Бәл лилләһил-әмри җәмигуһа» аяте кәримәләре була.

«Русча уку кирәк. Икенче милләт кул астында торучы кешеләргә баш милләтнең тел, язу һәм дә дәүләт арасында тәртипкә салынган канун вә кагыйдәләрен белү кирәк вә тиешле. Фәкать аларның тел, йолалар вә гадәтләрен алудан, үзара русча сөйләшүдән һәм сүз арасына русча катыштырудан сакланырга, мөмкин кадәр үз телеңне сакларга тырышырга кирәк».

Низаглар вакытында Мәрҗанинең китапханәсендә сакланган язулардан.

ИДЕГӘЙ МОРЗА
ҺӘМ АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАРКАЛУЫ

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

Нәсел җепләре Чыңгызлар династиясеннән ерак тору сәбәпле, хан тәхетенә утырырга хокукы булмаса да, озак кына вакытлар Алтын Урда ханнарын үз кубызында биетеп тоткан, асылда ил белән бернинди чикләүләрсез идарә иткән Идегәй морзаны соңгы елларда, бигрәк тә аңа багышланган мәшһүр дастан татар әдәбияты хозурына яңадан кайтарылгач, татар тарихының иң күренекле шәхесләреннән санау гадәткә кергән иде. Кем соң ул чынбарлыкта Идегәй? Татар тарихында нинди роль уйнаган? «Идегәй» дастанына түгел, ә тарихи документларга таянып, шул сорауларга җавап табарга тырышыйк.

Автор:
Фаяз Хуҗин

КЕМ УЛ ИДЕГӘЙ?

Идегәй – 1370 елларда Алтын Урда тәхетен биләп торган Ырыс һәм Тимер Мәлик ханнарның баш әмире Балтычакның улы, 1352 елда Маңгыстауда туган. Балтычак әмир – Түбән Идел, Җаек, Маңгыстау (Мангышлак), Арал буйларында таралып утырган аксөяк мангыт – Күк Урданың югары аристократия ыруыннан. Сүз уңаеннан әйтеп үтим: бу җирләр белән заманында Туктамышның әтисе Туйхуҗа идарә иткән. Идегәйнең әтисенә килгәндә исә, ул табигате белән тыныч холыклы, төпле һәм зирәк акыллы зат була, Ырыс хан һәм Тимер Мәлик хөкүмәтендә алдан уйлап эш йөртүче дипломат, мәртәбәле сәясәтче буларак танылa. 1379 елда Аксак Тимер тарафыннан Тимер Мәлик ханга каршы җибәрелгән Туктамыш гаскәрләре Карабак елгасы тирәсендә – Күк Урда җирләрендә очрашалар. Әлеге канкойгыч сугышта Тимер Мәлик һәм аның баш әмире Балтычак әсирлеккә төшә. Туктамыш Тимер Мәликне шундук үтерергә боера, ә менә Балтычак белән күзгә-күз очрашып сөйләшергә була. Ул аны, Алтын Урда хөкүмәтендәге иң акыллы дәүләт эшлеклесен, үзенә хезмәткә чакыра. Баш әмир һәм хан киңәшчесе Балтычак шәһит киткән ханына тугры бу-

Туктамыш хан.

лып калачагын белдерә. Аксак Тимер ярдәме белән Күк Урда ханы булып алган Туктамышның тәкъдименнән катгый рәвештә баш тарткан Балтычакны үлем җәзасына хөкем итәләр.

Бу вакыйгадан соң Идегәйнең Туктамышка мөнәсәбәтен аңлау авыр түгел, ул – аның әтисен үтерүче явыз. Әмма сәяси тормыш бик катлаулы, хәтта ки мантыйкка буйсынып җитмәслек дәрәҗәдә катлаулы нәрсә. Чынлап та шулай: хәйләкәр һәм, әйтергә кирәк, мәкерле Идегәй, күңеле түрендә Туктамышка үчен-ачуын саклаган хәлдә, аның киявенә әверелә, күренекле дәүләт эшлеклесе, хәрби җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелә. 1380 нче елгы Куликово сугышыннан соң тәхеткә менгән Туктамыш хан аны Алтын Урда гаскәрләренең сул канаты башкомандующие итеп билгели. Туктамыш ханның бу гамәлләрендә мантыйк бар, әлбәттә: шул юл белән ул Идегәйне үз ягына авыштырмакчы булган, күрәсең.

ХАН УГЫЛЫ – ТИМЕР КОТЛЫК

Язмабызның тагын бер герое белән танышып үтик. Ул – Тимер Котлык, Туктамыш фәрманы белән үтертелгән Тимер Мәлик ханның улы, Идегәйнең туганнан туган энесе (апасының улы). Хан угылы буларак, аның Алтын Урда тәхетенә тулы хокукы бар. Әтисеннән яшьли ятим калган Тимер Котлык башлыча Идегәй әмир хозурында тәрбияләнә һәм, әлбәттә инде, Туктамышка мөнәсәбәте дә абыйсы Идегәй йогынтысында калыплаша. Тимер Котлык Идегәйгә нәкъ менә хан угылы буларак кирәк. Аның җентекләп уйланылган киләчәк планы – Алтын Урда тәхетен яулап алу, ә бу планны Тимер Котлыктан башка тормышка ашыру һич мөмкин түгел. Ә бүген исә аны Туктамыштан саклап калу зарур, чөнки ул, Туктамыш, хан тәхетенә дәгъва кылырга хокукы булган һәркемне, шул исәптән Котлыкны да теләсә кайсы вакытта, һич көтмәгәндә юкка чыгарырга сәләтле. Идегәй Тимер Котлыкны Сәмәркандка, Кавказ аръягы өчен сугышлардан соң Туктамышның кан дошманына әверелгән Аксак Тимер хозурына җибәрергә карар кыла. Сәмәрканд әмире яшүсмер угланны шатланып каршы ала.

ИДЕГӘЙНЕҢ САРАЙ ӘЛ-ҖӘДИДТӘН КАЧУЫ

Сарай әл-Җәдидтә исә тормыш үз көенә бара. Гаскәриләре һәм хөкүмәт әһелләре арасында көче ташып торган, әтисе кебек акыллы, әмма бераз кырысрак һәм сүзен үлчәп кенә сөйләшә торган Идегәйнең абруе үсә баруын күреп, Туктамыш хан аңа шикләнебрәк, хәтта көнләшеп карарга мәҗбүр була. Ул Идегәйнең күңел төбендәге яшерен хыялын – аның хан тәхетенә хуҗа булырга омтылуын сизми әле. Аның шикләнүләре нигезсез булмаган, әлбәттә. Тиздән Туктамышка Идегәй тирәсенә тупланган бер төркем бәкләр һәм угланнарның ханга каршы фетнә оештырып маташулары турында хәбәр җиткерәләр. Яшерен планнары ханга билгеле булуын һәм үзенә куркыныч янавын белеп (бу турыда аны Туктамыш хатыннарының берсе, каенанасы, кисәткән булырга тиеш), Идегәй Сарайдан чыгып качарга мәҗбүр була. Әлбәттә инде, Сәмәркандка, Аксак Тимер янына. Анда Тимер Котлык – тәхет турындагы хыялларын тормышка ашыруда төп таяныч. Аны тәхеткә утыртмыйча торып, Идегәйгә Алтын Урда хуҗасы булырга мөмкин булмаячак.


Аксак Тимер

ИДЕГӘЙ АКСАК ТИМЕР ЯНЫНДА

Аксак Тимер Идегәйне дә якты чырай белән каршылый. Чөнки аның үз хыялы: Алтын Урда биләп торган бай төбәкләрне, беренче чиратта, Түбән Иделне, Кара диңгез һәм Каспий буйларын, Кавказ аръягын басып алып, үз дәүләтенең чикләрен киңәйтү. Бу эшләрне башкарып чыгуда Идегәй белән Тимер Котлык, әлбәттә, аның төп ярдәмчеләре булачак. Идегәй – менә

дигән хәрби җитәкче, батыр сугышчы, Котлык исә хан тәхетен яулап алган очракта да аның сүзеннән чыкмаячак. Өстәвенә әле Идегәйнең дә, Тимер Котлыкның да хыяллары бер – үтерелгән әтиләре өчен Туктамыштан үч алу.

Идегәй белән Аксак Тимер бер-берсен бик яхшы аңлыйлар. Сәмәрканд әмирен Алтын Урда җирләренә яу чабарга күндерү авыр булмый.

АКСАК ТИМЕРНЕҢ ТУКТАМЫШКА КАРШЫ ҺӨҖҮМЕ

Аксак Тимернең 200 мең сугышчыдан торган гаскәре Алтын Урда җирләренә 1391 елның гыйнварында аяк баса. Туктамыш армиясе дошманны Кавказда көтә (чөнки элегрәк, 1385 елда, алар шул якларда сугышкан була), әмма Аксак Тимер Алтын Урда биләмәләренә керү өчен Түбән Иделне, Кыпчак далаларын сайлап ала. Юлда очраган шәһәр-авылларны юк итеп, Урта Иделгә кадәр күтәреләләр. Хәлиткеч сугыш 1391 елның 18 июнендә Кондырча елгасы буенда була. Туктамыш армиясе тар-мар ителә. Шулай итеп, Идегәй Аксак Тимер кулы белән Туктамыштан үч ала. Нәтиҗәдә меңләгән кешенең гомере өзелә, шәһәр-авыллар талана, дәүләт казнасына зур матди зыян салына.

Аксак Тимер, сугышчыларын бераз ял иттереп, кайтыр юлга әзерләнә. Шул заман аңа Туктамышка каршы сугышкан бер төркем Алтын Урда бәкләре мөрәҗәгать итә. Алар Аксак Тимердән Урта Азия якларына китәр алдыннан Идел-Җаек арасында яшәп ятучы ыругдашларына кайтып килергә рөхсәт сорыйлар. Озак та үтмәс, туганнарыбыздан җыелган гаскәр белән Сәмәркандка, сезнең карамакка килеп җитәрбез, диләр. Бу үтенечне Аксак Тимер бик шатланып канәгатьләндерә, әлбәттә. Тегеләр кайтып китәләр (араларында Идегәй белән Тимер Котлык та була!), әмма Аксак Тимер аларны бүтән күрми инде. Бу эшнең башында Идегәй торганлыгын ул бик тиз аңлап ала.

САРАЙ ТИРӘСЕНДӘГЕ ЧУАЛЫШЛАР

Авантюрист характерлы Идегәй, туган якларына кайтып, үзен Мангытау олысының хакиме – өлкән бәк дип игълан итә. Һәм Алтын Урда хәлләрен игътибар белән күзәтеп бара. Ә биредә тәртипсезлек хөкем сөрә. Туктамышка каршы көчләр баш күтәрә. Шуларның берсе, Бикбулат углан, Туктамышның Сарайда булмавыннан файдаланып, хан тәхетенә менеп утыра. Моны ишетеп алган Туктамыш Сарайга ашыга, Бикбулатны башкаладан куып җибәрә һәм аны эзәрлекләп Кырымга кадәр барып җитә.

Бу хәлдән Идегәй бик оста файдалана: үзенең сугышчан отряды белән тиз арада Сарайга килеп җитә һәм буш калган тәхеткә Тимер Котлыкны утыртып куя. Ниһаять, Идегәй морзаның күптәнге хыялы тормышка аша – тәхеттә ул теләгән хан. Тик менә бу хәбәрне Туктамыш ничек кабул итәр?

Ә Туктамыш, башкаладагы хәлләрне ишетеп, тәхетне көтелмәгән бәладән азат итәргә ашыга. Һәм ул аны җиңел генә башкарып та чыга – Тимер Котлыкны Сарайдан куып җибәрә. Илдә бераз тынычлык урнашкан кебек була.

АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАРКАЛУЫ

Шул ук вакытта Туктамыш белән Аксак Тимер арасында мөнәсәбәтләр кискенләшә бара. Сәмәрканд әмиренә каршы көрәштә Туктамыш үзенә союздашлар эзли, Литва кенәзенә, Мисыр солтанына, Грузия патшасына илчеләр җибәрә. Аксак Тимер исә ике арада булып торган бәрелешләрне туктатып тору максатыннан Туктамыш белән сөйләшүләр алып барырга карар итә. Әмма Туктамыш хан аңа тупас җавап кайтара һәм сөйләшүләрдән баш тарта. Нәтиҗәдә – яңадан сугыш.

1395 елның апрель аенда Терек елгасы тирәсендә башланып киткән сугыш элгәреләренә караганда күпкә дәһшәтлерәк була һәм ул, ахыр чиктә, Алтын Урданың таркалуына китерә. Төньяк Кавказда башланып киткән сугышта Аксак Тимер гаскәрләре җиңүгә ирешә. Туктамыш, сугышчыларын ияртеп, Идел буйлап төньякка хәрәкәт итә. Аның артыннан дошманнары да калышмый, юлда очраган йөзләгән авылларны, Сарай, Әстерхан, Үкәк, Җүкәтау, Кашан, Болгар кебек эре-эре шәһәрләрне яндырып, тар-мар итеп, талап, Урта Иделгә кадәр күтәреләләр. Шул ук шәһәрләрне, һәм дә Бәлҗемән, Маҗар, Азак ишеләрен, Кырым калаларын кайту юлына төшкәч тә талыйлар. Әмма Туктамышның эзенә төшә алмыйлар, ул кечкенә гаскәре белән Болгар урманнарына кереп качкан була.

Аксак Тимер үз иленә кайтып китә. Харәбәгә әйләнгән Алтын Урда шәһәрләрендә дә тормыш әкренләп җанлана. Хансыз калган Урда исә аерым олысларга бүленә башлый. Бу хәлдән Идегәй белән Тимер Котлык бик оста файдаланалар. Үзәк олыс һәм Сарай әл-Җәдид сугышсыз-нисез диярлек алар кулына күчә. Шулай итеп, Тимер Котлык хан тәхетенә ия була, Идегәй морза төп киңәшчесе сыйфатында үз өстенә илнең хәрби җитәкчесе – Алтын Урда гаскәрләренең башкомандующие вазыйфаларын ала.

ТУКТАМЫШНЫҢ КЫРЫМНАН КУЫЛУЫ

Туктамыш хан, бераз вакыт Болгар җирендә яшеренеп ятканнан соң, Кырымга килеп төпләнә һәм үзен Сарайдан бәйсез мөстәкыйль хан буларак таныта. Бу хәлләрне ишетеп, Тимер Котлык белән Идегәй Кырымга яу белән киләләр һәм Туктамышны аннан куып җибәрәләр. Куылган хан үзенең союздашы Литва кенәзе Витовтка барып егыла. Витовт аны хөрмәт белән кабул итә. Литва җирендә бераз хәл җыйгач, Туктамыш Витовттан Сарай тәхетен үзенә кайтаруда ярдәм сорый, моның өчен ул аңа Мәскәү, Новгород, Псков җирләрен Литва биләмәләренә кушуда булышырга вәгъдә итә. Витовт, әлбәттә, бу шартларга ризалаша.

ИДЕГӘЙ – АЛТЫН УРДА ХАКИМЕ

Союздашларның планнары Идегәйгә барып ирешә. Ул һич тә сугыш яклы түгел. Аксак Тимер белән 1395 елгы канкойгыч бәрелештән соң үткән өчдүрт ел эчендә Алтын Урданы элеккеге чикләрендә торгызу, аның бердәмлеген ныгыту өчен күп тырыша Идегәй. Хуҗалыкның барлык тармакларында да җанлану сизелә. Тормыш җайлана, әкренләп үз калыбына керә

бара. Яңа сугыш бу уңышларның барысын да юкка чыгарырга мөмкин.

Әмма Идегәй кулы астындагы Урданың көннән-көн ныгып баруын күзәтеп торган Туктамыш яуга ыргыла. Витовт – Туктамыш һәм Тимер Котлык – Идегәй гаскәрләре Днепрның сулъяк кушылдыгы Ворскла елгасы тирәсендә 1399 елның 12 августында очраша. Бу Идегәйнең киләчәктәге язмышы өчен дә, Туктамыш өчен дә хәлиткеч сугыш була. Идегәй җитәкчелегендәге Алтын Урда гаскәрләре басымына чыдый алмыйча, Витовт – Туктамыш сугышчылары кача башлый. Идегәй сугышны җиңү белән тәмамлый. Җиңү шатлыгын Тимер Котлыкның кинәттән үлеп китүе генә бозып куя.

Идегәй Сарайга әйләнеп кайта. Ул хәзер. Корылтайда күпчелек аның ягында – ханнарны сайлаганда Идегәйнең теләген искә алып эш итәргә әзерләр. Тәхеткә утыру бәхетенә ия булучы ханнарның барысы да: 1407–1411 елларда Шадибәк, 1407–1411 елларда Булат Солтан, соңыннан Тимер хан (Тимер Котлыкның улы) – ил белән чынлап торып идарә итүне Идегәйгә тапшыралар.

Идегәй илдә тәртип урнаштыру өчен көчен кызганмый. Тик эш ул теләгәнчә генә бармый. Идегәйгә каршы көчләр Тимер хан тирәсенә тупланалар. Яшь хан алар кулындагы курчакка әверелә. Шул арада сәяси аренага Туктамышның улы Җәләлетдин күтәрелә. Ул Тимер ханны үтереп, тәхеткә үзе менеп утыра.

Идегәйнең соңгы еллары Туктамышның уллары белән канлы көрәштә үтә. Кырым тәхетенә утырып алган Кадыйрбәк белән соңгы көрәш 1420 елда Җаек елгасы тирәсендә, Сарайчыктан ерак түгел бер җирдә була. Бу сугышта Кадыйрбәк һәлак була. Каты яраланган Идегәй элегрәк Туктамыш ханда хезмәт иткән бер әмир тарафыннан үтерелә.

Әйе, фаҗигале язмыш иясе ул Идегәй морза. Аның бөтен тырышлыгы Алтын Урданың куәтен ныгытуга, бердәмлеген саклауга юнәлдерелгән кебек, асылда исә аның авантюристик характердагы эшчәнлеге дәүләтнең көчсезләнүенә һәм ахыр чиктә таркалуына гына китерә. ■

Идегәй морза.

Иллюстрация: Рушан Шәмсетдинов

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

АЛЕКСЕЙ ГУСЬКОВ: МИНЕМ МӘҢГЕЛЕК ТОРМЫШ СЕРЛӘРЕМ

Ел ярым элек актер Алексей Гуськов үзе өчен катгый бер карарга килә: «Җитте!» – ди. Акча булсын өчен җаны теләмәгән проектларда катнашудан баш тарта. Ә нишләргә соң? Бөтенләй эшләмәскәме? Юк, әлбәттә, эшләргә: әмма «үзеңне илһамландырган идеяләр һәм проектлар» булган очракта гына... Шундыйларның беренчесе – «Александр Христофоровның мәңгелек тормышы» фильмы. Биредә Гуськов төп рольне дә уйный, продюсер буларак та катнаша, сценарий автордашы буларак та. Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыга соң? Бу турыда актер «Татарстан» журналына биргән махсус интервьюсында сөйләде.

– Сезнең фильмыгызны беренче мәртәбә Ялтада, «Евразия күпере» фестивалендә күрсәттеләр. Публикада ул нинди тәэсирләр уятты?

– Мин, хәзерге, заманча тел белән сөйләшсәк, тыныч күңел белән әйтә алам: «кереп китте». Без бит фильмны җиңел жанр буларак кабул итәргә ияләшкәнбез. Әмма жанрның җиңеллеге көлдерү, кәмит тудыру, хихылдату белән генә бәйле булырга тиеш түгел. Хихылдауны аны кем дә булдыра. Минемчә кеше заты затлы итеп көлә белергә тиеш. Безнең очракта нәкъ шундый көлүне күздә тотып эшләнде фильм. Ул көлү лентаның буеннан-буена сузыла, үзеннән соң рәхәт бер тәм калдыра: «Йа Ходам, бу бит минем хакта!» – дип уйлыйсың. Сәнгать асылда бернигә дә өйрәтми, ул яшәргә булыша. Без фильмның трейлерын тәкъдир иткәндә, шәрехләрнең берсе мондый иде: «Нинди сурәт! Нинди чагылыш! Мөгаен, җиңел фильмдыр, тормыш матавыкларыннан арынып торырга ярдәм итәрдәй булырга охшаган, карарга кирәк!»

– Сез нигә уңыш елмаймый торган актер турында фильм төшерергә булдыгыз?

– Бу фильмның идеясе җиде ел элек үк килгән иде. Ул чакта мин Интернетта бер сораштыруга тап булдым. Анда ике генә сорау бар иде: мәңге яшь алсагыз, нишләр идегез, ике атна гына гомерегез калса, нишләр идегез. Җаваплар бик күптөрле: «акча эшләр идем», «Җир шарын очып әйләнер идем», «космонавт булыр идем»... әмма алар барысы да 10 нчы урыннан соң гына очрый башлый. Ә беренче урында – ир-атларның да, хатын-кызларның да ихтыяҗы бер – «яратыр һәм яратылыр идем» дигән җавап. Минем каһарманым, әйтергә кирәк, көлке булмаган нәрсәләрдән көлә, асылда. Ул үзенә сорау бирә: ә синнән соң нәрсә калачак? Без һәр кеше өчен әһәмиятле булган һәм аңа якын нәрсәләр турында сөйләргә теләдек – бу аталар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр дә, хатын-кыз белән ир-ат, дуслар арасындагылар да. Христофоровка актер һөнәре бирсәк тә, фильм актер турында түгел – анимация кешенең табигатендә. Кеше гомумән сәнгатькә тартыла, ул ансыз яши алмый. Менә, мәсәлән, кечкенә кыз бала әнисенең туфлиләрен кия дә өлкәнрәк булырга хыяллана, ул үзен шулай тоя да – бу шул ук анимация. Ә минем героебызның тормышка карашы үзгәргәч, тормыш аңа гаҗәеп бүләкләр китерә башлый – бер караштан гашыйк була, улы аны ихтирам итә башлый, якыннары һәм моңарчы якын булмаган кешеләр дә таный, үз итә...

– Ә сезнең дусларыгыз-курсташларыгыз арасында бармый андый Христофоровлар? Зур өметләр баглап та, билгеле бер сәбәпләр аркасында арбадан төшеп калучылар...

– Бу һәрбер театр вузының актерлар курсы практикасы – 20 елдан соң, гадәттә, профессиядә бары тик дүрттән бере генә кала, җәмгысе – 6-7 кеше. Әгәр курстан чыкканнар арасында ике халык артисты бар икән, димәк, аны гениаль курс дип атарга мөмкин. Атказанган артистлар булса – әйбәт курс. Бу теләсә кайсы вузның гына түгел, ә профессиянең дә практикасы. Еш кына без һөнәребез профиле буенча эшләмибез. Әйтик, мин фәкыйрегезнең тормышында театраль институт – икенче вуз, аңа кадәр Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техника университетында укыган идем. Әниемә рәхмәт – ул миңа тиешле 5 елдан артыграк, 8 ел буена укырга мөмкинлек бирде. Әтиебез, хәрби очучы, иртә вафат булуга, миннән соң сеңлем дә булуга карамастан...

– Балачактан актер булырга хыялландыгызмы?

– Мин актер булам дип беркайчан да хыялланмадым. Бу – очраклы очракларның чылбыры гына. Хәер, барлык очраклыклар да – үзенә күрә бер закончалык. Бер генә нәрсә дә юктан килеп чыкмый бит. Театр теле белән әйтсәк, барысы да – яхшы репетицияләнгән импровизация. Мин элегрәк нинди дә булса конкрет рольне уйнарга хыялланмавым өчен кыенсына идем. Беркайчан да булмады «моны уйнасам иде» дигән хыялым! Кемдер бит Гамлет турында хыяллана, Король Лир хакында, Войницкий, Треплевны уйныйсы иде, дип йөри. Беркайчан да алай гасабиланмадым. Ә менә теманы мөмкин кадәр дөрес, төгәл итеп җиткерү, аны үз уйларым белән чагыштырып карап, кисешү нокталары табып, вакытны, ситуацияне тамашачыга бар колачында тәкъдим итү – бу хакта гел хыял-

Фото: Александр Ефремов



ланам. Сценарийда андый темага юлыксам, бөтен барлыгым белән күтәреләм, кайныйм, иҗади дәрт биләп ала күңелне. Шунда ук фантазияләргә бирелә́м – ничегрәк уйнасаң, шәбрәк килеп чыгар иде...

– Сезгә бу елда 60 яшь тулды – нәтиҗәләр ясый торган җитди чор. Нәрсәләрне эшләп өлгермәдегез әле?

– Хәтерегездәме Пушкинның юллары: «Кто в двадцать лет был франт иль хват, А в тридцать выгодно женат; Кто в пятьдесят освободился От частных и других долгов...» Әнә ничек үз урынына утыртып куйган бөтенесен дә Александр Сергеевич. Тик ул елларда кешеләр иртәрәк олыгайганнар да, вафат та булганнар. Хәзер – башкачарак. Ә менә «шәхси һәм башка бурычлардан азат булу» дигәндә, мин аны үзем өчен болайрак шәрехлим: балалар инде үсеп җитте, әбием әйтмешли, «дошманнарыңның дошманнары» – оныклар пәйда булды...

– Нигә «дошманнарыңның дошманнары»?

– Шундый әйтем бар бит. Әбием аны шаярып искә алырга ярата иде. Балалар ахыр чиктә әтиәниләренә шатлыктан кала нинди борчулар, хәсрәтләр китерүләрен барыбер дә аңлый. Еш кына әйтәбез бит: үз балаң булсын әле, шунда аңларсың. Ә менә нәтиҗәләргә килгәндә, беркайчан да нәтиҗә ясамадым, хәзер дә ясарга җыенмыйм. Мин тормышны яратам, аның тәмен беләм, ул әле дәвам итә. Соңгы еллардагы барлык фикерләрем дә – сүзләрнең бушлыгы турында. Без үзебез һәм кешелек үз гомерендә нәрсә генә уйлап чыгармаган. Бәхет, мәхәббәт... Бу сүзләрнең артында гомуми мәгънә ята, әмма бит алар гомуми кабул ителә алмый торган төшенчәләр.

Нәрсә ул бәхет? Әгәр мин бәхетле мизгелләремне искә алам икән, бик күп мизгелләрне искә төшерәчәкмен, гомеремнең төрле чорларын. Алар төрле чакларда янәшәмдә булган кеше белән дә, уңышлы эшем белән дә, күңелне күтәргән, канатлар куйган вакыйгалар белән дә бәйле булачак. Кеше яши, аннан китеп бара... Бер фиргавен, Рамзес II, ялгышмасам, үлгәннән соң, үзен кулларын җәйгән хәлдә бөтен Мисыр буйлап йөртеп чыгарга боерган. Карагыз, янәсе: бернәрсә дә алмадым! Пирамидалар да торгызган, бихисап коллар белән дә идарә иткән, байлыкка да күмелеп яшәгән, юкса, әмма берсен дә теге дөньяга алып китә алмаган...

Кеше хәтерендә нәрсә калдырасың син – тормышны һәм яшәешеңне мәңгелеккә тоташтыручы җеп әнә шул гына була ала. Кеше хәтерендә шундый эз калдыручылар да бар: үзләре киткәннән соң, аларны тизрәк онытасы килә! Шундый уйланулар ятты «Вечная жизнь Александра Христофорова» картинасының нигезенә. Ярты ел элек гаиләмне җыеп алдым да төрле-төрле сораулар бирә башладым. Кызым: «Әти, синең белән бар да тәртиптәме?» – дип хафага төште. Аның инде үз гаиләсе бар, кызы, фатиры. Улларым белән дә сөйләштем. Алар да аптырашта калды: «Син нишләп әле бу турыда сүз кузгатасың?» Мин әйтәм: «Бүтән унитаз өчен эшлисем килми», – дим. «Бу нәрсә дигән диюең, әти?» – дип шаккаттылар. «Башка теләмәгән проектларда төшәргә җыенмыйм. Монысын аласы бар, монысын төзеп бетерәсе, дип, керем булсын, диеп... Минем хәзер үземә берни дә кирәкми, аңлагыз, үзем теләгәнчә яшим әле, ярыймы?» – дип сорадым. Алар миңа: «Әти, соң бөтенләй эшләмәсәң дә була!» – дип җавап кайтардылар. «Юк, юк, анысы турында сүз дә булырга мөмкин түгел, бары тик мин үзем теләгән идеяләр белән яшәргә һәм чынчынлап җәлеп иткән проектларда төшәргә генә телим...»

Нәтиҗәсе – шушы фильм. Тамашачыма яхшы кәеф бүләк итәсем килгән иде, бүләк итә алгамындыр, дип ышанасы килә. 🅃

Әңгәмәдәш:
Гүзәл Подольская



Фотолар: medium.com сайтыннан алынды

ПЕЛЕВИН АТТРАКЦИОНЫ, ЯКИ НИРВАНА ГАРАНТИЯЛӘНӘМЕ?

Без инде бер генә «әдәби сезон»ны да Виктор Пелевин романынинннан башка күз алдына китерә алмыйбыз. Сентябрь саен – яңа китап. Традиция буенча. Бу мәдәни-иҗтимагый күренешнең рус әдәби мохитендә үз исеме дә бар –Пелевин «аттракционы». Танылган «аттракциончы» быел да үзенең фанатларын чираттагы, исәп буенча уналтынчы, романы белән сөендерде. «Тайные виды на гору Фудзи» дип аталган әсәре 2018 елның 27 сентябрендә «Эксмо» нәшриятында дөнья күрде.

Автор:
Луиза Янсуар

ФИЛЬТРЛАНГАН САТИРА, ЯКИ «ФОРБС» ИСЕМЛЕГЕ МАГИЯСЕ

Әле китап үзе киштәләрдә пәйда булганчы ук, «Медуза»ның алыштыргысыз күзәтүчесе, әдәби тәнкыйтьче Галина Юзефович укучылар игътибарын инде «кыздырып» куярга өлгерде. Ул язучының бу әсәрен «иң буддистик» һәм «иң турыдан бәрә торган» роман булырак бәяләде. Романның мизогиния үрнәге булуын да аерым ассызыклаган иде үзенең күзәтүендә Юзефович. Монысы, әлбәттә, укучыны тагын да ныграк кызыксындырды. Пелевинның буддизм җәйләүләре тирәсендәрәк йөрергә яратуын ул азмы-күпме чамалый иде (хәтта авторның үзен гомерендә бер мәртәбә укып карамаса да!). Ә менә мизогиния глашатае булуы… – монысы кызык!

Шөкер, аңлаешсыз терминнарны тиз арада үзләштерер өчен хәзер челтәр бар һәм андагы фильтрланган, кайчак хәтта бөтенләй тәмсезләндерелгән, шыр шәрә скелеты гына калган мәгълүмат арасыннан чыннан да нидер сөзеп алырга мөмкинлек таба кулланучылар. Юзефович кулланган «мизигония» төшенчәсе бу очракта үзенең тиешле мишенена барып тиде – күзәтүне укыганнан соң күпчелек Гуглны «Пелевин мизогиниясе» дип тәгаен җәфалагандыр. Ә инде аның, шартлы рәвештә, «хатын-кызны түбән

итеп күрсәтү һәм аны нәфрәт белән сурәтләү» икәнлеге турында белеп алгач, феминизм тарафдарлары буза куптарыр өчен булса да укырга ябырылгандыр, дип уйлыйм. Хәер, шул ук Юзефович, өстәп, романда антифеминизм да ярылып ята, дип өсти. Шуннан соң, буталып беткән укучыга инде ни кала? Йә һичшиксез әсәрне алып укырга һәм, анализ ясап, үз фикерен булдырырга. Йә – тотынып та тормаска...

Мизогиния белән феминизм мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтәсем килә: бу ике термин да әсәргә карата шактый спекулятив максат белән кулланыла кебек тоела миңа. Җәлеп итү максаты белән. Аннан да бигрәк – «тискәре тәэсир аша җәлеп итү». Шәхсән мин махсус күздә тотылган чәнечкеле антифеминизмны тоймадым. Автор гадәттәгечә – Пелевинча бу темага орына, һәрвакыттагыча ирония белдерә. Урыны-урыны белән ачыктан-ачык сарказмга, сатирага күчә.

Менә без сатираны узган гасырда һәм аның да узганында – Салтыков-Щедрин, Гоголь, Булгаков, Ильф һәм Петровларда калган дип исәпләргә күнеккәнбез. Алар чорга бәяне нәкъ менә сатира аша биргәннәр бит. Пелевинның «Тайные виды на гору Фудзи» романы бу яктан караганда – чын мәгънәсендә сатира үрнәге, хәтта «контркультура» жанры яратканча, фарс, күпмедер дәрәҗәдә стильләрне укмаштырган трэшка да тарта.

Асылда, сюжетның бернинди хәйләсе, катлаулылыгы юк. Ул искиткеч ачыклык, аныклык белән чынбарлык моделен кабатлый. Роман Дамиан Улитин исемле Сколково стартаперының Fuji experiences дип исемләнгән проектын сату максаты белән «Форбс» исемлегенә кергән, 90 нчы елларда төрмәдә утырып чыкканнан соң, тәвәккәлләп, үз империясен төзегән олигарх Федор Семенович янына килүеннән башланып китә. Нинди баналь, дип көлемсерәп куярга да бик мөмкин укучы. Ә Федор Семеновичка әлеге яшь эшмәкәр егетне дуслары, «Форбс» исемлегендә тагын да югарырак рәтләрдә торган Юра белән Ринат тәкъдим итә. Шулай итеп, Пелевин безне бүгенге байларның тормышына күмелдерә дә, 90 нчы еллардагы «Байлар да елый» сериалының мәгънәви эчтәлеген хәтерләтеп, психологик пластка күчә.

Молодой человек снял бейсболку, положил ее на шезлонг таким образом, чтобы видна была надпись на ней, и деликатно присел рядом. На бейсболке было написано: SKOLKOVO SAILING TEAM. Видимо, молодой человек давал понять, что у него тоже есть лодка, но пока еще маленькая.

– Вас зовут...

– Дамиан Улитин. Можно на «ты».

– Точно Дамиан? А не Демьян?

– Точно. Могу паспорт показать.

Тому было лет тридцать с небольшим. Уверенная улыбка, высокий сократовский лоб, черные волосы и бородка – то ли широкая goatee, то ли узкая шкиперская. В Дамиане чувствовалась сладкая восточная – скорее всего, среднеазиатская – кровь и такая же сладкая восточная нега...

– Если вообще, – сказал он решительно, – то 90% всех стартапов – это чистой воды кидалово.

– Ух ты! Прямо-таки кидалово?

– Ну не в прямом уголовном смысле. Просто их начинают с одной целью – создать видимость движухи, чего-то такого многообещающего и рвущегося в небо, и сразу, пока никто не разобрался, эту видимость продать. Продают в таких случаях, по сути, презентацию с картинками, файл программы power point, а деньги берут настоящие... То есть, люди с самого начала думают не над тем, как перевернуть рынок, или хотя бы предложить людям новый продукт или услугу, а над тем, как склеить эффектное чучело. Продемонстрировать рост, сделать отчетность с красивыми цифрами, заинтересовать инвестора, снять лавандос и отчалить. При этом продают, как правило, клон какого-нибудь клона...

– Клиентов много?

– Вот список.

Федор Семенович поглядел в бумажку, усмехнулся и уважительно поднял бровь.

– Впечатляет...

Дамиан вынул из кармана зажигалку и поджег бумагу. Потом пустил по ветру дотлевающие остатки бумаги.

– Говорить вслух о таких вещах неразумно. Это может быть записано подслушивающим устройством и использовано. Прайвеси клиента – святыня номер один.

– Хорошо, – сказал Федор Семенович, – так что же ты хочешь мне продать? Если коротко?

– Счастье, – сказал Дамиан.

– Да? – развеселился Федор Семенович. – А откуда ты его завозить будешь? Там его вообще много? А то, давай, я оптом все возьму.

– Это не так просто. Счастье – это психический эффект. Ваше, так сказать, субъективное состояние в конце определенной процедуры. Продать и купить можно только процедуру. То есть технологию достижения счастья.

БӘХЕТ РЕЦЕПТЫ, ЯКИ 90 НЧЫ ЕЛЛАРДАН БҮГЕНГЕГӘ КУЛЬБИТ

Һәм сез ничек уйлыйсыз? Ышаначакмы Федор әфәндебез Сколково тамгасы белән ачыктан-ачык манипуляция ясаучы бу гикка? (Әле дә ярый Стив Джобс сурәте төшкән футболкадан түгел, гәрчә бу хәзер бик нык трендта булса да). Риза булачакмы ул аның үтә затлы тәкъдименә? Җитмәсә, дусты һәм кайчандыр, төрмәдән чыккач, аны үз «түбәсе» астына алган һәм кеше иткән аркадашы Ринат Мусаевич та, әнә, инде кайсыдыр дәрәҗәдә бәхеткә юл ярып маташа ди анда... Ә аннан калышу килешмәячәк... Әлбәттә, риазалашачак!

Пелевин заманча дөнья моделен сүтеп җыярга ярата торган язучы. Әмма ул аны сүтеп җыйганда, 90 нчы еллар салган җәрәхәткә, безнең анда калган авырткан урыннарыбызга даими кайтып йөри. Аны үз заманының кутырларында казынырга әнә шул әсәрдә сурәтләнгән ике дөнья кисешендә калган имансызлык, идеологик бушлык та мәҗбүр итәдер, бәлки. Күз алдында һәм бизмән тәлинкәсендә ике дөнья бит: ишегалды шпаналарыннан, бандаларыннан «братвага» күчкән, кулын яшьтәшләренең канында юган, хәзер инде кагылгысыз, өстеннән яраннары тузан бөртеген дә өреп төшереп торган бер псевдоаксөяккә әверелгән Федялар мохитенә каршы – яңа яралган, нечкә-зәвыклы булып кыланган, асылында исә, кул көче белән эш итмичә, физик яктан пычранмыйча, имгәнмичә, психологик ысуллар белән эш йөртүче Дамиан-Демьяннар (нәрсәсе белән Британия аксөякләре чылбырын гәүдәләндергән Дориан Грей түгел ди, йә инкарь итеп карагыз!)..

Пелевин башта аларны кискен каршы куйса да, акрынлап аңлашыла: араларындагы аерма әллә ни зур түгел – һәр ике як та кулланган яки кулланмаган ысулларда гына. Дөресрәге, ысулларның заманча эстетик тышлыкка төреп тәкъдим ителүендә. Ә ым-

– Что с нами вообще произошло за последний век в культурном плане? – вопросил Юра. – Революция? Гагарин? Да нет. С ломаного французского перешли на ломаный английский. Потому что русская культура свои жизненные соки и смыслы не из себя производит, как Китай, Америка или Япония, а из других культур подсасывает. Вот как гриб на дереве. И за одобрением тоже за бугор бегает, как в Орду за ярлыком. Петя Первый, упокой его Господи, отрубил все корни – и пересадил. Серьезный был ботаник. С тех пор и прыгаем с ветки на ветку с бомбой в зубах...

– Есть такое, – согласился Ринат. – А все из-за либералов. Они уже два... Нет, три века делают вид, что они такие... культуртрегеры в мантиях. А на самом деле они простые челночники, которые тащат сюда всякое говно с западной барахолки и с безмерным понтом впаривают русскому человеку. И никакие басни Михалкова не помогают. Вот поэтому Дамиан свой стартап по-английски и называет.

– И не один, – влез я. – Они все латиницей записаны. Я тут список 50 лучших стартапов проглядывал, так по-русски только «Лесной дозор». И то потому, что кабаны в лесу иначе не поймут...

сыну объектлары барыбер шул бер үк – акча, дан, муллык, яхшы тормыш, «мин кәттәрәк» ярышындагы мәңгелек узыш... Менә Дамиан Федяның йокы бүлмәсенең дизайнына исе китеп йөри. Аңлашыла инде, бу «братва»га нечкә хисләрен дөньяга күрсәтергә ярамаган һәм хәзер дә ярамый. Шуңа да бирелдә бруталлек (нинди генә акчалар белән эш итмәсен, һаман да шул урамлык, ишегалдылык) хөкем сөрә. Әнә, аның ятагы өстендә «Голливуд триптихы» дип аталган картина эленеп тора. Бу – уңыш һәм алдынгылык билгесе. Ә картина авторы – алар яшендәгеләр арасында бик популяр һәм кыйммәтле йөри торган «модный» рәссам. Картинага шәрех тә бар – «Харви Вайнштайн насилует Николь Кидман, Уму Турман и Натали Портман». Аңлашыла ки, Дамианнар буыны инде үз йокы бүлмәләрен мондый затсызлык белән бизәмәячәк. Алар, аңлашыла, хайтекка йөз тотачаклар, абстракциягә, аутентиклыкка... Хәзер нәрсә модада йөри, шуңа. Аларга «малиновый» пиджаклар киеп берберсен суеп чыккан Федяларның тупас романтизмы чит, ул аларның гайрәтен чигерә. Тик алар өчен һава торышын әлегә нәкъ менә Федялар билгели, нәкъ менә Федяларда – «кормушка». Шуңа Дамианнар, эчтән генә мыскыллы елмаеп, тыштан бер карусыз, бу «дебил» олигарх абзыйлар өчен Таиландта, Һиндстанда, Балида 10 катлы притоннар арендалый. 10 катына да Азия илләреннән, Украина, Беларуссиядән «кызлар» китереп, шыплап бикләп, этажлар буйлап интим характердагы квестлар оештыра. «Күпчелек клиентларга шул кирәк», – ди бер сөйләшүдә Дамиан Федяга. Бу квесттан соң, аның әйтүенчә, абзыйлар яңадан тугандай булып кайта да, Мәскәүдәге финанс операцияләре, сделкалары шулай ук бөтенләй яңа дәрәҗәгә чыга. Әмма Федя белән Дамиан ялгыша. Бу төрмәләрдә утырып чыккан олигарх аны беренче очрашуларда ук: «Син әйткәннәрне мин үзем дә акча түләп ала алам, син миңа җан рәхәтлек кичерердәй берәр яңа нәрсә тәкъдим ит! – ди ул. – Аңлат миңа – ничек Моцартлар, Бахлар шундый музыка яза алганнар, ничек тоташканнар алар Рухияткә...» Шулай итеп, Дамианга Федя өчен «рухи чистарыну» дигән опциягә старт бирергә мәҗбүр була. Фуджи тавына күтәрелүче ике әкәм-төкәм турындагы притчадан башланган романның башыннан азагына кадәр әнә шул лейтмотив дәвам итә...

Пелевин бу яңа буын «эшлекле»ләренең ысулларын китапның башыннан азагына кадәр бик җентекләп сурәтли. Һәм – өч «братва»ныкын да. Мин бу әсәрне, беренче чиратта, чынбарлыкны идеалистик-альтруистик ноктадан кабул итүчеләргә җиргәрәк төшәр өчен укырга киңәш итәр идем. Шунысы бик тә кискен һәм аермачык күрсәтелгән: «яңалар» физик яктан әллә ни каһарманлыкка сәләтле түгел, дошманына да алар инде корал тотып ташланмаячак, ә аны психологик яктан юк итәчәк. Шул ук вакытта алар хисләргә дә сәләтле түгел – антифеминистик месседждан бигрәк, дөньяның унификация, андрогинлык, стерильлеккә баруына ишарә ясый

шикелле Пелевин. Бу романда инде хисләр юк, алар урынына ләззәт китерергә сәләтле психика белән эш итү генә – беренче урында. Һәм менә Дамиан белән аның командасы Федяны бәхетле итү юнәлешендә тулы бер команда белән эш башлап җибәрә – аның баш миен сканлап, иң башта «бәхет чылбырын» ачыклыйлар. Ягъни: нинди вакыйгалар/кичерешләр чылбыры аны бәхет тойгысы кичерүгә алып килә. Аннан бу бәхетне томалап торучы факторларга тукталалар. Шулай итеп, Дамиан Федорга беренче продуктын сата – ул «Помпейский поцелуй» дип атала. Үзенә күрә, үсмер чагында күңелендә калган үкенечләрне (чынга ашмаган хыял-өметләрне) тормышка ашыру һәм, шулай итеп, гештальтны ябу дип тә әйтергә була моны. Һәм шушы урында сәхнәдә Федорның яшьлек мәхәббәте – Танек, Танечка пәйда була…

БУДДА, КАСТАНЕДА, ЯКИ ИСКЕ ЭЛЕМЕНТЛАРДАН ЯҢАЧА КОКТЕЙЛЬ

Ирләрчә герметик дөньяны сурәтләүче оста буларак исәпләнсә дә, Танечка линиясендә Пелевин шактый нечкә моментларны тотып ала, ул хатын-кыз психологиясен шактый тулы спектрда ачып күрсәтә. Аның героинясы – әле үсмер чорда ук үзенең класстагы, ә бәлки, мәктәптәге дә бер гүзәле итеп тоеп алган һәм аннары бу матурлыкны гомере буена яхшы коммерциягә куйган типик постсовет продукты. 90 нчы еллардагы бандитларның берсеннән соң икенчесен, өченчесен алыштыргач, көннәрдән бер көнне ул айнып китә. Чираттагы дус кызы белән аның «папенька»сын машиналарында шартлаткач, Танечка клиентлар даирәсен үзгәртә. Әмма яше барган саен, аңа үзенең бәясен югары йөртү инде кыенлаша башлый. Чираттагы бик тә җайлы клиенты яшьрәк туташка китеп баргач, үзен икеләтә, өчләтә алданган, мыскыл ителгән кебек тойган бу ханым тормышында алга таба нинди юл сайларга икәнен уйлый башлый. Офисларда хуҗабикә булып утыру инде тәтемәс шул, моны алданрак уйларга кирәк иде, кемнеңдер хатыны булу… аныкына үзенең дә әллә ни йөрәге ятмый. Булган очракта да, ышанычлы ир затына тап булса гына…

Шундый көннәрнең берсендә ул мәктәптә үзенә гашыйк булып йөргән, тик ул аны кешегә дә санамаган Федяның фотографиясен бер глянец журнал битендә күреп ала. Аның «Форбс» исемлегенә кергән миллионер булуын ачыклый. Һәм… фотоларын кисеп алып җыя башлый, акрынлап үзен аның янәшәсендәге затлы ханым, бәлки, хатыны ук итеп тоярга омтылуын ваемлап ала. Ул бу визуализация ысулы белән шөгыльләнеп йөргән көннәрдә аңа… Дамиан шалтырата. «Федор Семенович сезне яшьлек хатирәсе буларак хәтерендә саклый. Очрашу билгеләде», – ди. «Кайда?» – дип тораташ булып катып кала ханым. «Сәер урын. Сез кайчандыр бәрәңге алган бер авылда. Баракта. Имеш, анда сезнең арагызда сәер бер вакыйга булган. Әнә шул вакыйганы онытмый минем заказчым».

Сез мәхәббәт линиясе төенләнеш алды, дип фаразларга ашыкмаячаксыз, шулай бит? Әллә ашыктыгызмы? Пелевинны белүчеләр – ашыкмагандыр. Ә аны үтә дә яхшы белүчеләр… бу тарихның икенче катламында барыбер дә романтизм ятуына төшенгәндер. Әмма баллы, төче романтизм түгел, тормышчан, ирониясе, сарказмлы. Шуны да онытмыйк, язучының героинясы китапның башында үзе дә автор аның белән ниләр майтарасын белми бит әле. Билгеле, хатын-кызларга хас дәрт, вәсвәсә белән ул Федяның үзенә һаман да гыйшык саклавына өметләнә, хыялында инде ак лимузинда туйга җилдерә… Юкса ник өйләнмәгән ул шушы еллар буена, дип үзен ышандыра. Ни өчен аны теге сәер урынга чакыра? Махсус хәстәрләнә…

Пелевин, виртуозларча, заман күзбуарларының (ә алар үзләрен хәзер бик трендлы, затлы исемнәр белән атый) ничек итеп абстракция сату белән шөгыльләнүләрен күрсәтә Танечка линиясендә дә. Моның өчен бер генә нәрсәдән дә тайчанмыйлар. Ысуллар, чаралар үзгәрә, максат һәм инстинктлар үзгәрми. Болар инде Урта Азиядән поезд вагоннарына тутырып келәмнәр, капчык-капчык ыштан-итәк-свитерлар алып кайтып сатмый. Болар – гедонистлар. Алар теге заманда этиләре, әниләре түккән һәм туфракка сеңгән корбан канында үсеп чыккан чәчәкләр. Алар абстракция сата. Миф сата.

Хатын-кызларны ятьмәгә алу, аулау мәсьәләсенә килгәндә, аңлашыла инде, шулай ук асылына – Башлангычыңа кайту кебек югары идеяга мөрәҗәгать ителә, юкса ул Федя линиясенә алып чыкмас иде. Монда Пелевинга ярдәмгә XX гасырның тагын бер грандиоз мифы – Кастанеда белән аның тирәсендәге туташханымнар – Тайша Абеляр, Флоринда Донерлар белән бәйле тарих килә. Танечканы алар бик матур һәм ымсындыргыч итеп Борынгы, әле дөнья белән Хатын-кызлар идарә иткән чорга дәшәләр, ир-атлар узурпаторлыгын юк итүче сайланган хатын-кыз икәнлегенә басым ясыйлар…

Ул арада көрәш ачарга, үчен алырга тиешле Федясы, джаналар серенә төшенер, медитацияләр аша Будда халәтенә якынаер өчен дуслары белән Һиндстанга, Изге тауга китеп бара. Анда алар өчен махсус вип-шартлар тудырыла, әлбәттә… Хәер, спойлерларны шушында туктатам. Укымыйча, барыбер тәмен тоеп булмый чөнки. Пелевинны һәрвакыт кызыксындырган хакимият, акча һәм ирек феноменнары биредә бик кызыклы бәйләнештә тәкъдим ителә. Ә чишелеш… чишелеш укучыны шулай ук көлдерәчәк.

Ә безнең ике сукыр әкәм-төкәмебез Фудзи тавына үрмәләүләрен дәвам итә. Хәер, сукыр булгач, алар бит белми. Бәлки, әле ул Фудзи да түгелдер… ▪

ТАТАР ДӨМ-ДӨМЕ: КЕЧКЕНӘ АВЫЛНЫҢ БӨЕК ДАНЫ

Алабуга районында татар авыллары берничә генә. Без аның иң танылганында булдык. Казан – Чаллы автоюлыннан барганда Татар Дөм-Дөменә махсус юл күрсәткече тора. Югыйсә анда дистәләгән башка авыллар да бар, тик Дөм-Дөмгә – аерым игътибар, аерым мөнәсәбәт. Ни өчен, дисезме? Язманы укыгач, белерсез.

Автор:
Руфия Фазылова

МӘКТӘП БИНАСЫ – БҮТӘН МАКСАТКА...

Татар Дөм-Дөме зур түгел: 260 кеше яши, туксанлап йорт бар. Элек тә ул әллә ни зур булмаган. (Ерак түгел Айталан авылы бар. Ул да Дөм-Дөм җирлегенә карый. Анда гомумән12 генә кеше гомер итә, 7 йорт бар. – Авт.) Дөм-Дөмдә мәктәп юк, дөресрәге, булган, әмма тугызъеллык белем үзәге 2011 елда ябылган. Балалар саны аз, дигәннәр. Ә балалар бакчасы эшли әле, 8 бала йөри икән. Гаҗәп тә, кызганыч та: яңа ике катлы мәктәп бинасын 1996 елда ачып, биш елдан ябып та куйганнар. Югыйсә утыздан артык бала укыган.

– Мәктәп ябылгач, авылдан сигез яшь гаилә чыгып китте, – диделәр Дөм-Дөмдә. Сәбәбе бик гади: укытучылар эшсез кала, мәктәптә эшләмәгәннәре дә читкә китү ягын карый.

– Балаларыбыз Шүрнәк урта мәктәбенә йөри, – дип сөйләде ата-аналар. – Иртәнге җиде тулганчы чыгып китәләр. Кичке дүрткә генә кайтып җитәләр. Туган авылларында укысалар, болай интекмәсләр иде.

Нәрсә дим? Ата-аналар үзләре активлык күрсәтмәгән. Югыйсә утыздан артык бала укыган белем үзәген (ә бу авыл өчен начар күрсәткеч түгел) ябып куймаслар иде. Район хакимиятенә, мәгариф бүлегенә кат-кат барырга, хатлар язарга кирәк булгандыр. Андый очраклар күп булды, район хакимиятләре, ата-ана сүзен тыңлап, бала саны аз булган шактый мәктәпләрне саклап калды.

Бүген исә мәктәп бинасы балалар бакчасын, авыл җирлеге идарәсен, фельдшер-акушерлык пунктын, китапханәне, музейны, элемтә бүлеген үзенә сыендырган. Кыскасы, авылның үзәге. Дөм-Дөм авыл җирлеге башлыгы Рафаэль Бәдретдинов безне башта шунда алып китте.

Китапханәче Венера Ибниева берничә авыл апасы белән газета-журналлар караштыра иде, шул исәптән – «Татарстан» журналын да. («Безне монда беләләр!» – дип күңел күтәрелеп китте. – Авт.)

– Газета-журналлар кыйммәт бит, элеккеге кебек берничә матбугат басмасы яздырырга кеше-

1. Китапханәче Венера Ибниева берничә авыл апасы белән газета-журналлар караштыра иде.

нең акчасы юк. Шуңа күрә китапханәдән алып укыйлар. Кулдан кулга йөри-йөри газета-журналлар таушалып бетә, – диде Венера апа.

Ачык, аралашучан халык яши Дөм-Дөмдә. Авылның якынча тарихы, үткәне турында сөйләштек. Айгөл Гатина, архивларда утырып, туган авылы турында мәгълүмат туплый икән. Киләчәктә китап чыгарырга ниятлиләр.

– Авылның тарихын тирәнтен өйрәнгән кеше юк әлегә, – диде Венера Ибниева. – Ләкин кызыксынучылар шактый. Шулай булгач, киләчәктә Дөм-Дөмнең тарихын бүгенгесен яктырткан китап пәйда булыр, дип ышанам.

Китапханәгә җыелган апалар авыл исеменең килеп чыгышын болайрак аңлатты:

– Явыз Иван Казанны алгач, халык бу якларга качып китеп, күченеп утырган. Ә биредә урман, караңгылык булган. Шуңа күрә Дөм-Дөм дип исем биргәннәр, – диделәр. Ләкин бу, аңлашыла, халык телендә йөргән риваять кенә, алга таба бу темага яңадан әйләнеп кайтырбыз әле.

«БЕЗНЕҢ НӘСЕЛ!»

– Дөм-Дөмгә килгәч, Галиевларга керми китмәгез, – диделәр безгә. Бактың исә, биредә бик атаклы, абруйлы гаилә яши икән. Беренчедән, гаилә башлыгы Фоат абый күп еллар авылда имам булып торган. Бүген әлеге изге эшне улы Илшат дәвам итә. Өч буын булып – дәү әти-дәү әни, әти-әни, балалар – бөтенесе бергә тату гомер итәләр. Икенчедән, Илшат хәзрәт КФХ булып теркәлгән. Үзләренең, туганнарының пай җирләрен алып эшкәртә. Техникалары бар. Шуңа өстәп йөзләп умарта оясы да бар. Берничә баш үгез, каз, тавык-чеби асрыйлар, кыскасы, нык хуҗалык. Өченчедән, Фоат абый – танылган хоккейчы Данис Зариповның әнисенең туганнан туган абыйсы. Илшат хәзрәт белән Данис Зарипов өченче буын туганнар булып чыга.

– Әле кичә генә Казаннан кайттык, Данисларның гаиләсенә кунакка бардык, – диде Илшат Галиев.

Танылган хоккейчы әнисенең туган авылы – Дөм-Дөмне онытмый икән. Авыл балалары өчен махсус хоккей мәйданчыгы ясаткан. 15 пар хоккей киеме бүләк иткән. Район үзәкләрендә дә мондый яхшы сыйфатлы костюмнар юк, ди. Данис Зарипов хәтта Гагарин кубогын да Дөм-Дөмгә алып кайткан. (Агымдагы елның 22 апрелендә «Ак Барс» хоккей командасы Казанда узган матчта ЦСКА командасын җиңеп, чираттагы Гагарин кубогына ия булды бит.) Авыл халкы, бигрәк тә ир балалар өчен бер бәйрәм, тамаша булган ул. Үсмерләр кубокны тотып та, кочып та караган.

Берничә тапкыр Дөм-Дөмдә Данис Зарипов кубогы өчен уеннар да үткәргәннәр. Республиканың төрле районнарыннан килгәннәр. Бүләкләрне танылган спортчы үзе алып кайткан. Казан–Чаллы трассасында Татар Дөм-Дөменә юл күрсәткече дә әлеге вакый-



3

4

2. Галиевлар өч буын булып – дәү әти-дәү әни, әти-әни, балалар – бөтенесе бергә тату гомер итәләр.

3. Галиевлар, мәш килеп, нәсел шәҗәрәсен төзиләр, архивларда утыралар.

4. Үзләренең, туганнарының пай җирләрен алып эшкәртәләр. Техникалары бар. Шуңа өстәп, йөзләп умарта оясы да тоталар.

галарга бәйле булган: тиз арада авылның даны еракларга таралган. Һәм, димәк, бирегә килүчеләр дә арткан.

– Авыл балаларына мөмкинлекләр аз, дип, Данис малайлар өчен шундый чаралар оештырды, – диде Илшат Галиев. – Дөрес, хоккей уйнаган үсмерләр хәзер мәктәпне тәмамлап, Дөм-Дөмнән китте инде. Яңа команда туплыйсы була. Боз мәйданында һәр көн шөгыльләнсәң генә, уңышка ирешеп була, хоккейда бигрәк тә.

Сигез дистәне тутырган Фоат абый да – хоккей җанатары. Энекәше уйнаган бер генә матчны да калдырмый икән. Танылган хоккейчы бабайга бик зур телевизор алып кайтып биргән. Фоат абый Данис Зарипов турында менә нәрсәләр сөйләде:

– Безнең нәсел дип горурланып, Данис өчен сөенеп утырам. Балачакта Дөм-Дөмгә ул еш кайта иде. Безнең балалар белән уйнап үсте. Кечкенә чагында татарча яхшы белә иде, хәзер оныткан. Энекәш белән рус телендә аралашабыз.

Фоат абый тормыш иптәше Рәхилә апа белән ике ул, бер кыз үстергән. Әйткәнемчә, төпчекләре Илшат төп йортта калган, олы уллары гаиләсе белән Күршедә гомер итә. Кызлары гаиләсе белән Алабуга шәһәрендә яши.

– Картлык көннәрендә ялгыз калган әби-бабайларны кызганам мин, – дип сүзгә кушылды Рәхилә апа. – Мин үзем дә каенана, каената белән яшәдем. Бергә тормыш итү күпкә җиңелрәк, шуны аңламыйлар. Оныкларга күз-колак булу, кайнар ризык пешереп тору, хайваннарны карау – хәлдән килгәнчә булышасың. Картларга да күңелле – моңаеп утырырга вакыт та, мөмкинлек тә юк. Бер баланы үз яныңнан җибәрергә кирәк түгел, бетте-китте.

– Алар бит әле әти-әнине тыңлап та тормый, – дигән булам.

– Ничек тыңламасын? Ата-ана сүзеннән чыккан бала рәхәт күрми ул! Тыңларга тиеш...

Галиевлар йортында ямь, җылылык бар. Алар акыллы, тыйнак, зыялы, өстәвенә бик тырышлар. Мәш килеп, нәсел шәҗәрәсен төзиләр, архивларда утыралар. Илшат хәзрәт авыл тарихы белән дә кызыксына икән.

– Дөм-Дөм исемле авыллар якын-тирәдә тагын бар. Безнең авыл чагыштырмача яшь, XVII гасырда гына оешкан. Менә халык шул борынгырак авыллардан күчеп утырмаганмы дигән фараз бар. Тикшереп, ныклап өйрәнеп бетерергә кирәк.

СЕЗОНГА – БЕР МАШИНАЛЫК АКЧА?!

Дөм-Дөмдә тагын бер кеше белән таныштык. Аны авылда тырыш кырмыскага тиңлиләр: бер дә тик тормый икән. Республиканың төрле авылларында йөреп, мондый кешене очратканым юк иде әле!

Гөлнур Сәгъдиева табигатьтә нәрсә үсә, шуны җыеп, эшкәртеп сата. Иртә яздан үләннәр киптерә, себерке бәйли, җиләккә бара, караңгы көзгә кадәр гөмбә җыя, маринадлый, салатлар, тагын әллә ниләр ясый. Алты ай эчендә яңа «Лада Гранта» машинасы алырлык акча эшләгән. Элек Яр Чаллы шәһәрендә яшәгән, Дөм-Дөмгә күченеп кайтканнарына сигез ел икән.

Гөлнур апаны быел ике тапкыр кара елан чаккан. Бәхетенә, аягында ирләр күн итеге булган. Гөмбәче куркыныч вакыйга турында болай дип сөйләде:

– Елан аяк киеменә теше белән ябышты, көчкә котылдым. Быел кара елан бик күп булды. Алардан болай да курка идем, шуннан соң урманга улымны ияртеп барырга тырышам. Янда кеше булгач, барыбер тынычрак.

– Кара елан ташлангач, берәү урманга бүтән борылып та карамас иде, – дим.

1. Гөлнур Сәгъдиева алты ай эчендә яңа «Лада Гранта» машинасы алырлык акча эшләгән.

2. Хуҗабикәнең ике як өйдәге идән астын күреп гаҗәпкә калдык: шыплап тулган.

– Ә нишлисең, яшәргә кирәк. Эшем шул бит. Улымны да аякка бастырасы бар әле.

Гөлнур апа җәй буена иртәнге дүрттә торган. Җиләккә шулай таң белән чыгып киткән. Көн эсселәнгәнче, чиләкләрен тутырып кайта торган булган. Җиләк сатып та хәйран акча эшләгән. Шулай да иң үтемле «бизнес» – гөмбә икән. Аңа сорау зур, ди. Бәясе төрлечә: эшкәртелгән ярты литрлы банка 200 сумнан башлана, аның да төренә карап, өч литрлысы 1500 сумга кадәр.

– Гөмбәгә Удмуртия урманнарына барабыз, – ди Гөлнур апа. – Ирем исән вакытта бергә йөри идек. Мин кечкенәдән гөмбәләрне яхшы аерам, әни белән алты яшемнән урманга йөрдем. Гомер буе гөмбә җыйдык, тик үзебез өчен генә. Кем уйлаган шулай акча да эшләп була дип…

Гөлнур апа үзе ак гөмбәгә өстенлек бирә. «Тавык шулпасына ак гөмбәне салып пешергән аштан да тәмле әйбер юк», – диде безгә. Хуҗабикәнең һәр гөмбәгә аерым рецепты бар. Мәсәлән, әтәч гөмбәсе (лисички) – кыздырырга, баллы гөмбә (опята) маринадларга яхшы икән.

Хуҗабикәнең ике як өйдәге идән астын күреп гаҗәпкә калдык: шыплап тулган. Анда ни генә юк: кыяр, помидор, кайнатмалардан башлап, гөмбә салатларына кадәр.

– Кайнатмаларны да сатасызмы? – дим.

– Әйе, – дип елмайды Гөлнур апа. – Кыш көне Алабуга базарыннан кайтып кергән юк. Мине анда белеп бетерделәр инде. Товарны сорап кына торалар. Әйтмәгәнем булсын, сигез ел эчендә гөмбә белән берәүнең дә агуланганы юк. Алдан заказ биреп китәләр. Берочтан машинага төяп базарга мунча себеркесе, дару үләннәре дә алып барам…

Тырышкан табар, диләрме әле. Табигать-ана биргән хәзинә белән дә шулкадәр акча эшләргә була икән. Әлбәттә, иренмәсәң. Ә без, эш юк, дип зарланабыз.

КОЛХОЗ – ҮЗЕБЕЗДӘ!

Биредә авыл халкы «колхозда эшлим» дип сөйләшә. Айталан белән Дөм-Дөм, икесе бер хуҗалык булып, элеккечә яшәп ята. Дөрес, исеме колхоз түгел, «Яшь көч» Агрофирмасы» ҖЧҖ дип атала. Ә эш системасы шул ук калган. Агрофирманың җитәкчесе – Рузилә Хәдиуллина. Колхоз системасы таралганнан бирле шул вазыйфада икән ул. Дөрес, башта ире белән эшләгәннәр. Ул кисәк кенә вафат булгач, агрофирманы үзе генә алып бара башлаган.

3. – Дөм-Дөмне бик якын күрәм, гомерем монда узды. Шуңа да авыл таралмасын, бетмәсен иде, – ди Рузилә Хәдиуллина.

– Ирем исән вакытта хуҗалык зур – дүрт авылны берләштерә иде, – дип сөйләде Рузилә ханым. – Аннан Дөм-Дөм белән Айталанны гына калдырдым. Хатын-кызга зур хуҗалыкны алып бару бик җиңел эш түгел. Яшь тә бар бит. Япяшь килеш шушы авылга килен булып төштем. Дөм-Дөмне бик якын күрәм, гомерем монда узды. Шуңа да авыл таралмасын, бетмәсен иде, дим. Эшлим дигән кешегә бөтен мөмкинлекләр дә бар бездә.

Язгы чәчү, урып-җыю вакытында агрофирмада – 70–80 кеше, ә ел дәвамында 40 кеше эшли икән. Хезмәт хакы белән тоткарлыклар юк, диделәр.

«Яшь көч» хуҗалыгы сөт җитештерү, иген үстерү буенча районда беренче урында исәпләнә. 1100 баш мөгезле эре терлек бар. Тәүлегенә бер сыердан уртача 18 литр сөт савалар (республика буенча бу күрсәткеч – 17,4%). Ләкин иң мөһиме бу түгел. Иң сөенечлесе – Рузилә ханым авыл халкын да кайгыртa. Сабантуй, башка бәйрәмнәр оештыра. Авыл мәдәният йортына (бина яңа, район көче белән 2014 елда салынган) читтән артистлар чакырып, концертлар куйдырта, юлларны карый. «Сабантуйда гел кыйммәтле бүләкләр: суыткыч, тузан суырткыч, башка кирәк-яраклар өләшенә», – дип сөйләде авыл апалары. Агрофирмада эшләүчеләргә, хезмәт хакыннан тыш, бәйрәмнәрдә бүләкләр дә була икән.

Мондый эш тәртибе элеккеге колхоз системасын хәтерләтте. Ул заманда да кумәкләшеп эшләү, яшәү тәртибе бар иде. Бәйрәм җитәме, берәр гаиләдә үлем-җитемме, авыру-сырхаумы, колхоз җитәкчесенә ярдәм сорап киләләр. Дөм-Дөмдә бүген дә шулай икән.

...Авылларга барган саен тырыш, гади кешеләрен күреп сөенәсең, ә буш йортларын күреп көенәсең. Татар Дөм-Дөмендә рәхәтләнеп яшәргә бөтен мөмкинлекләр бар: асфальт, таш түшәлгән юллар, өйләргә газы, суы кергән. Бирадә эш юк дип тә зарланып утырмыйлар, теләгән кешегә «Яшь көч»тә эш бар, хезмәт хакы да авыл җире өчен начар түгел. Ә барыбер яшьләр калмый, диләр. Ни кызганыч! Авыл җирлеге башлыгы: Рафаэль Бәдретдинов: «Дәүләт программалары, ягъни бу рәхәтлек нәкъ утыз елга соңга калды. Ул чакта авыл җирендә мондый шартлар булса, кешеләр шәһәргә китмәс иде. Ә хәзер соң инде, бер читкә киткән кеше яңадан әйләнеп кайтмый шул... Шәһәргә караганда да уңайлырак шартлар тудырылып, авыл тормышын тамырдан үзгәртү булса, бәлки бездә дә тормыш яңарыр әле», – диде. Бирсен Ходай…

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

«Татар энциклопедик сүзлегендә Дөм-Дөм турында мондый мәгълүмат бар: «Татар Дөм-Дөме Нократ елгасыннан – 5 чакрым, Алабуга шәһәреннән 35 чакрым ераклыкта урнашкан. 1989 елда 338 кеше (татарлар), 1997 елда 298 кеше яшәгән. Оешу вакыты – XVII гасырның беренче яртысыннан да соң түгел. Дөм-дөм авылы урынында башта мари авылы булганлыгы билгеле.

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
I яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
башлана

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 924 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 924 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

Реклама 16+

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

2018 ел. Яр Чаллы.

Фото: Гөлфирә Сомова

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

1973 ел. Яр Чаллы.

Фото Яр Чаллы шәһәре Тарих-туган якны өйрәнү музее экспозициясеннән.